ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 9 (344)
СЕНТЯБРЬ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ҖИДЕДӘ ТОРМЫШ БАШЛАНА ГЫНА.

Хәзер мин моны тәгаен беләм!

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Финзия Газизова, Илдус Заһидуллин, Мөршидә Кыямова, Луиза Шарова, Диләрә Шкурко
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Казан шәһәре 83 нче лицейның 1 сыйныф укучылары. Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 880 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-2330
Басарга кул куелды: 11.09.2020
Басмадан чыкты: 17.09.2020

КИРӘКЛЕСЕНЕҢ АСТЫНА СЫЗ

Атаклы фильмда яңгыраган: «Кырыкта әле тормыш башлана гына. Хәзер мин моны тәгаен беләм!» – дигән атаклы фраза бүген дә барлык яшьтәгеләр, үз тормышында ниндидер бер чикне атлап узган һәркем өчен актуаль. «Москва слезам не верит» фильмы героинясы өчен ул гомере буе көткән мәхәббәтен очратканга актуаль. Ә бүген исә 7 яшьтәгеләр – беренче сыйныф укучыларының тормышы башлана гына, чөнки аларның биографиясенә мәктәп килеп керә. 100 яшьлек Татарстан Республикасының да яңа тормышы башлана, чөнки ул үзенең яңа йөзьеллыгына аяк баса.

Яңа тормышның башлануына мисаллар күп. Күрәсезме: 40 яшь, 7, 100 яшь (кирәклесенең астына сыз, дип әйтәсе килә) – алга, яңа тормышка! Мәхәббәт, белем, яңа омтылышлар, казанышлар тулы тормышка! Барысы да әле башлана гына – без моны тәгаен беләбез!

Сезнең 100 яшьлек диярлек редакциягез.

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4230 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ
БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ

УЛ «ПАРОЛЬ»НЕ БЕЛӘ

«Пароль» дәүләт радиолокацион танып алуның гомумгаскәри системасы инде менә кырык елга якын хәрби сакта тора. Россиядә генә түгел, союздаш илләрдә дә. Бу аппарат-программалы комплекс хәрбиләргә ерактан торып үз коралыңны читнекеннән аерырга мөмкинлек бирә. Әлеге еллар эчендә аппаратураның дошман кулына эләккән чаклары күп була, ләкин аның серен ача алмыйлар. Хәзерге көнгә кадәр беркемнең дә беркайда да моңардан да яхшыракны уйлап тапканы юк. Хәрби оборонаның әлеге могҗизасы Казан галиме, генераль конструктор Илдус Мостюковның турыдан-туры җитәклегендә эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Күптән түгел генә безнең күренекле якташыбыз короновирус авыруын җиңде, без аны чын күңелдән котлыйбыз һәм сәламәтлек телибез!



© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. **Хыял ярымтуравы**
Шыксыз сәнгать зонасыннан ничек Әбу-Даби ясарга

12. **Мәскәү–Казан зур тизлекле трассасы**
Кемнәр өчен тормыш җиңеләер

16. **Өзлексез белем чылбыры**
Укучыларны өстәмә белем бирү кай ягы белән шатландырыр

28 **Татарстан тәҗрибәсе – бөтен ил өчен**
Россиянең башка төбәкләре республикадан нинди үрнәкләрне ала

игелекле эшләр

32. **Татарстан. Беренче гасыр**
Республика юбилейны нинди казанышлар белән каршылады

42. **Күңелне сагыш басканда...**
Татар җырлары ничек итеп Киев белән Казан арасын бәйли

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

мәңгелек кыйммәтләр

50. **Тарих сәхифәләре**
Кем ул Габдерәшит Ибраһимов

54. **Кече Ватан патриотлары**
Иң беренче археология докторы

60. **«Причал»дан ату җәзасына кадәр**
«Татарстан» журналы мөхәррирләренә нинди язмыш туры килгән

64. **Иң борынгы чорлардан – бүгенгегә**
ТР Милли музее запаснигыннан нинди раритетларны чыгарганнар

72. **Китап киштәсе**
Яңа китаплар белән танышу

82. **Татар авыллары**
Олы Мәтәскә: чәчәкле авыл

акыллы гамәлләр

29.08

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Президенты, – Республика көне уңаеннан Татарстан халкына мөрәҗәгатендә:

– Татарстанның йөз еллык юлының нәтиҗәләре безнең уңышларның нигезендә һәрвакыт һәркемнең иҗади хезмәте ятканлыгын һәм моның алга таба да шулай калачагын дәлилләп тора. Без туган республикабызны булдыру һәм үстерү өчен саллы өлеш керткән татарстанлыларның барлык буыннарына да рәхмәтле. Хезмәт сөючәнлек, үз-үзебезгә һәм куәтебезгә ышану безне көчле итә, иң кыю һәм перспективалы бурычларны тормышка ашырырга һәм киләчәккә өмет белән карарга мөмкинлек бирә!

30.08

Гурбангулы БЕРДЫМӨХӘММӘТОВ, Төрекмәнстан Президенты, – ТР Президенты исеменә җибәрелгән котлау телеграммасында:

– Тарихи дуслык һәм туганлык җепләренә нигезләнгән Төрекмәнстан–Татарстан бәйләнешләре хәзерге вакытта безнең Россия Федерациясе белән күппланлы һәм стратегик партнерлыгыбызның күркәм үрнәге булып тора.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

27.08

Рабит БАТУЛЛА, язучы, – Казанда Мостай Кәрим һәйкәле ачылышында:

– Мостай Кәрим – безнең бөркет, аның бер канаты – татар, икенчесе – башкорт, әгәр аның бер канатына зыян килсә, кош һәлак булачак. Ул очсын өчен, татарлар – аның башкорт канатын, ә башкортлар татар канатын сакларга тиеш.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

акыллы гамәлләр

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Киләчәгебезне **нинди** проектлар яхшыртырга тиеш

Шыксыз сәнәгать зонасыннан **ничек** Әбу-Даби ясарга

М-12 трассасы **кайчан** Казанны Мәскәүгә якынайтыр

Талантлы балаларны **ничек** Татарстанда калдырырга

Россиянең төбәкләре республикадан **нинди** үрнәкләрне ала

Фотолар: «Автодор» Дәүләт компаниясенең матбугат үзәгеннән

Тормыш сыйфаты турындагы сорауга кагылышлы

КИЛӘЧӘГЕБЕЗНЕ ЯХШЫРТЫРГА ТИЕШЛЕ ПРОЕКТЛАР

Консерваторлар цивилизацияне никадәр генә сүгеп, чабата-арбаларны кайтару яклы булмасыннар, тормышыбызны барыбер яңалык яхшырак, уңайлырак, тизрәк, матуррак итә. Без янәшәбездәге паркка чыгабыз, аның матурлыгына сокланып ял итәбез. Европадагыдай төзекләндерелгән елга яр буйларында хозурланып йөрибез. Кечкенә генә район үзәгендә яшәсәк тә, бассейн һәм боз спорт сарайларына йөрү безнең өчен гадәтигә әйләнеп бара, шул ук вакытта Россиянең башка, безнекеннән зуррак торак пунктларында боларның берсенең дә булмавына аптырыйбыз. Республикада яхшы юлларның булуын, социаль ипотекадан файдаланып, торак алу мөмкинлеген тиешле нәрсәләр кебек кабул итәбез.



Югары технологияле медицинаның чиксез мөмкинлекләреннән файдаланабыз һәм диспансерлашуны вакытында узабыз, хәтта ки ерак авылларда яшәсәк тә, чөнки безгә мобиль поликлиника үзе килә. Һәм бу 2020 елда, ә киләчәктә безнениләр көтә? Нинди проектлар ни рәвешле безнең тормышыбызны яхшыртачак? Бүген әкият тоелган нинди уңайлыклар дүрт елдан соң – чынбарлыкка, ә тагын ике елдан соң гадәтигә әвереләчәк? 2024 елга нинди проектлар безнең тормышыбызны сыйфатлырак итәчәк?

1 *Елга вокзалы*
ШЫКСЫЗ СӘНӘГАТЬ ЗОНАСЫННАН НИЧЕК ӘБУ-ДАБИ ЯСАРГА

2 *М-12 зур тизлекле магистраль*
РОССИЯНЕҢ ИҢ МАСШТАБЛЫ ЮЛ ПРОЕКТЫННАН ТАТАРСТАН НИНДИ ФАЙДА АЛАЧАК

3 *Өстәмә белем*
ТАЛАНТЛЫ БАЛАЛАРНЫ НИЧЕК АЧЫКЛАРГА ҺӘМ ҮСТЕРЕРГӘ

4 *Лагерьларны торгызу*
ТАТАРСТАН БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН ҖӘЙ НИЧЕК ҮЗГӘРӘЧӘК

«Хыял территориясе» – шәһәр мэры әле бүгенгә Казанның шыксыз сәнәгать зонасы саналган җирләрне әнә шулай дип атады. Ник алай дип уйлап куйдыгызмы? Без дә!

ИДЕЛ КИНӘРЛӘРЕНДӘ – УРБАНИСТИКА ШЕДЕВРЫ



Автор: Ольга Туманская

Фотолар Казан мэриясе матбугат хезмәтеннән алынды



ӘБУ-ДАБИ КӨНЛӘШЕРЛЕК!

Бу күпердән искиткеч манзара ачыла. Йомшак кына искән елга җиләнә йөз куеп, шәһәргә арка белән борылып басып, Иделгә сәгатьләр буе карап торырга була. Йөз сиксән градуска борылуга, тагын бер кочак хис-кичереш көтә. Бу ноктадан ачылган манзара үз матурлыгы һәм киңлеге ягыннан Гонконгтагы атаклы Цим Ша Цуй променады, Мумбайдагы Марин-драйв һәм хәтта... Әбу-Дабидагы Корниш яр буе белән дә ярыша ала! Хәер, узышырга кирәкме соң? Казанда күргәннәребезнең дә тиңе юк бит.

Тугыз чакрымга сузылган яр буе – меңьеллык калабызның чын визит карточкасы, аның тарих һәм хәзерге заманны берләштергән фасады. Арт-объектларга әйләндерелгән йөк краннары башкаланың сәнәгать өлкәсендәге даны турында искә төшерә. Яр буена туктаган зур көймәләрдә музейлар һәм кафелар урнашкан. Биредә туристлык теплоходлары һәм шәхси катерлар кую өчен үзенең тукталышы – маринасы да бар. Парклар табигый купшылыгы һәм билгеле бер стильдәге пөхтәлеге белән сокландыра. Ә бухтаның нәкъ үзәгендә, архитектура доминантасы буларак, Болгар мәдәнияте белән урбанистика үзәкләренең футуристик рухтагы

ансамбле урын ала. Сүз уңаеннан, мин басып торган күпер чын архитектура шедевры. Һавада эленеп торгандай җиңел корылма елганың ике як ярын тоташтыра...

Хәер, бу манзара – якты киләчәктән генә. Бүген исә монда игътибарга лаек бернәрсә дә юк: йөк суднолары өчен төяү-ремонтлау урыннары, гаражлар, ташландык складлар, таркалган предприятие хәрабәләре... Хәзерге Порт урамының чынбарлыгы әнә шундый күңелсез. Аны күргәч, «якты киләчәк»кә өметләнү шактый авыр.

– Бу территория Казанда иң кызыклы урыннарның берсе булачак, – дип ышандыра проектның координаторы Татьяна Прокофьева. – Өч яктан су әйләндереп алган бухтада яшәү, чыннан да, гаҗәп булачак! Без планлаштырганның барысы да тормышка ашар дип хыялланам – бу урында, соңгы тенденцияләрне исәпкә алып, иң заманча технологияләр буенча төзелгән алдынгы архитектура үрнәге барлыкка киләчәк. Әлбәттә, экология мәсьәләсе дә игътибар үзәгендә булачак. Территория мәдәни, мәгариф, спорт, күңел ачу функцияләрен башкара торган бик күп иҗтимагый киңлекләр белән тулыландырылачак. Иманым камил, биредә яшәү бик кызыклы булачак, бигрәк тә – яшьләргә.

Әйе, футуристик рухтагы иҗтимагый үзәкләрдән, парклардан һәм яр буеннан кала, бу зонада уртача биеклектәге, үз архитектура доминанталары булган 1 млн квадрат метрдан артык торак төзү күздә тотыла. Якын-тирә территорияләрдә мәктәпләр һәм балалар бакчалары төзү дә планлаштырылган. Һәм мондый ниятләр әлеге территорияне комплекслы үстерүгә яңа караш булып тора. Малайзиянең APUDG компаниясе эшләгән әүвәлге концепциядән шәһәр баш тартырга карар кылган.

Ул чакта, 2016 елда, Малайзия архитекторлары 656 гектар мәйдандагы яр буен үзләштерергә тәкъдим иткән иде. Аның зур өлешен бизнес үзәкләргә бирү күздә тотылды. Бизнеска тәгаенләнгән 7 млн кв. метр күчемсез милек әлеге территорияне монофункцияле урынга әйләндерәчәк иде. Ягъни, караңгы төшкәч, монда тормыш туктап калачак. Әмма шәһәр өчен көндезге һәм кичке активлык балансы мөһим. Өстәвенә, казанлыларга үзәктә яшәү ошый! Күрәсең, Малайзия архитекторлары йокы районнарында яшәргә яратучы европалыларны күздә тоткан. Хәзерге концепция 247 гектарга гына кагыла, шул ук вакытта ул күпкә функциональрәк һәм тереррәк.

– Заман үзгәреп тора, Казанда әлеге территориянең үсеш циклләрен билгели торган Генераль планның кайбер таләпләре дә үзгәрде. Элеккеге концепциянең шәһәр алдында торган бурычларга туры килмәве бүген инде ачык күренә. Без хәзер эшли торганы биналарның сирәгрәк урнашуын, йортларның тәбәнәгрәк булуын күздә тота, Яр буе сызыгына, аның шәһәр халкы һәм кунаклар өчен ачык булуына зур игътибар бирәбез. Миңа калса, бу вариант – әлеге территорияне үзләштерү мәсьәләсенә реальрәк караш, ул калабыз ихтыяҗларына күбрәк туры килә, – дип вазгыятькә аңлатма бирә Татьяна Прокофьева.

Тагын бер мөһим үзенчәлек – малайзиялеләр үз проектларына юдыртып өелгән шактый зур мәйданда территория булдыруны керткән иде. Бүген бу идеядән баш тартырга карар кылынды – юдыртып ясау ысулын кулланмыйча, яр сызыгын беразтышкы яктан матурлау гына планлаштырыла. Эш шунда ки: яр буе зонасы гаять төрле дәрәҗәдә үзләштерелгән – иске яр буе ныгытмасы төрле материаллардан эшләнгән, яр аркылыга-буйга шактый «кискәләнгән», хәтта причал диварлары да төрле биеклектә һәм формада. Яр сызыгын бу рәвештә калдырырга ярамый, дип саный Татьяна Прокофьева. Шуңа күрә яр буендагы үзгәрешләр күз уңында тотыла, әмма алар территория экологиясен дә, аның ландшафтын да бозмаячак.

“

– Бу территория Казанда иң кызыклы урыннарның берсе булачак, – дип ышандыра проектның координаторы **Татьяна Прокофьева**. – Өч яктан су әйләндереп алган бухтада яшәү, чыннан да, гаҗәп булачак! Без планлаштырганның барысы да тормышка ашар дип хыялланам – бу урында, соңгы тенденцияләрне исәпкә алып, иң заманча технологияләр буенча төзелгән алдынгы архитектура үрнәге барлыкка киләчәк.

ТАЛАНТ БӨРТЕКЛӘРЕ

...Хыялдагы ярымутрау. Әйе, бу урын миңа нәкъ әнә шулай булып күренә. Биредә матурлык һәм иҗадилык хөкем сөрә. Паркның пөхтә аллеялары арасында берөзлексез театр перфоманслары бара, үзеңнең талантыңны күрсәтү мәйданында заманча сәнгать фестивале төрле авазлар, җете төсләр белән кайнап тора. Ә янәшәдә – Витрувий трилогиясенә охшатып төзелгән һәм үзенә файда (бизнес), ныклык (фән) һәм матурлыкны (иҗат) берләштерә торган атаклы концептуаль архитектура комплексы. Бу – төрле бизнес-инкубаторлар һәм коворкинглар, тикшеренү лабораторияләре һәм институтлар, концерт заллары һәм лекторийлар, остаханәләр һәм иҗат студияләре, рестораннар һәм кунакханәләр булган тулы бер креатив индустрия дөньясы....

Минем әлеге виртуаль сәяхәтемнән соң бер елга якын вакыт узды! Порт элеваторының яшь архитекторлар – 2019 елда Иннополиста узган Икенче Россия яшьләр архитектура биенналесе финалистлары Илсөяр Габдрахманова һәм Ринат Гарипов уйлап тапкан һәм визуальләштергән киләчәк картинасы иде ул. Бәйгедә катнашучылар алдында катлаулы

бурыч торды: шыксыз һәм ташландык сәнәгать зонасын заманча районга әверелдерү. Бу урынга ничек җан өрергә икәнен дә уйлап табарга кирәк әле!

Әйе, урынның шәһәр халкын җәлеп итәрлек үзәк һәм Казанда туристларны сокландырырлык елга буе була алуы турындагы фикер архитекторларга, төзүчеләргә һәм шәһәр хакимиятенә күптәннән тынгы бирми. Бүген исә Порт урамы фаразда гына түгел, ә чынбарлыктагы реновация мәйданына әйләнгәндә, элеваторны, һич шаярусыз, зур киләчәк көтә дип әйтергә мөмкин. Чөнки бу бина – әлеге территориянең бай сәнәгать тарихын хәтерләтеп торган истәлекле объект. Яңартылганнан соң нинди булачак соң ул? Җәмәгать үзәгеме? Студентлар шәһәрчеге һәм заманча мәгариф кластерымы? Ә, бәлки, югарыда искә алынган «Витрувий трилогиясе»дер?

– Торак йорт түгел, әлегә шунысында гына шигебез юк, – дип җавап бирә Татьяна Прокофьева. – Һәр объект буенча халыкара архитектура конкурсы үткәреләчәк, дигән карар кабул ителде. Элеватор да искәрмә булмаячак, әлбәттә. Бу проектны эшләгән яшь архитекторлар, бәлки, безгә үз концепцияләрен тәкъдим итәр.

Ләкин башта территорияне үстерүнең гомуми концепциясе буенча эшне тәмамларга кирәк, әлегә ул асылда якынча план һәм күләмле-пространстволы күзаллау гына булып тора. Концепция биналарның тибын һәм биеклеген, урнашу тыгызлыгын, функциональ юнәлешен, машина кую урыннары һәм юлларны ачыклаячак. Әнә шул эш нәтиҗәләреннән чыгып кына, әһәмиятле объектлар исемлеге билгеләнәчәк. Элеватор да шунда керә.

– Казанда мондый сәнәгать территорияләре күп, һәм алар барысы да – безнең тарих. Шәһәр шушы хакыйкатьне нигез итеп алып, иске мәйданнарны яңа социаль ихтыяҗлар һәм таләпләр өчен җайлаштырырга тиеш, һәм бу шул исәптән шәһәрләрнең җәелү проблемасын да хәл итә, – дип үз фикерләре белән уртаклаша «Витрувий трилогиясе» автордашы Илсөяр Габдрахманова.

– Бүген бөтен архитектура диярлек тарихи мохит һәм аның урынында калкып чыккан яңа биналар, корылмалар арасында каршылыклар, бәхәсләр нәтиҗәсендә барлыкка килә, – диде сәнәгать зоналарын яңартуга багышланган биенналеда жюри рәисе, Россия һәм Германиянең танылган архитекторы Сергей Чобан. – Тик, беләсезме, архитектурада барлык формалар да инде табылган кебек тоела миңа, шуңа күрә бүген иң кызыгы – ниндидер көтелмәгән форма табу процессы түгел, ә әйләнәтирә мохит контекстына ниндидер яңалык кертү, халыкның төрле катламнары, төркемнәре өчен уңайлы тирәлек булдыру.

– Яңа Татар бистәсе Казанның үзенчәлекле бер почмагы, шәһәргә хас кабатланмас көнчыгыш мөселман ландшафтының аерылгысыз бер өлеше булып тора. Без матурлыйсы территориянең бистә белән янәшә булуы аның тарихи формалашу процессына йогынты ясамый калмаган. Һәм әлеге үзенчәлекне территорияне үстерү концепциясенә кертергә кирәк, – диде проектны тәкъдим иткәндә Казанның баш архитекторы Илсөяр Төхвәтуллина. – Нәкъ менә шуның өчен биредә Болгар мәдәнияте үзәге барлыкка килергә тиеш, аны безгә Яңа Татар



Роттердам порты.

Казанда «хыял территориясе» проекты эскизы.

бистәсенең тарихи урыннары белән бәйләп, шәһәрнең туристлык маршрутлары белән тоташтырырга кирәк булачак әле. Без сезнең белән бергә хыялланырга, уй-фикерләргә билгеле бер рәвеш бирергә һәм аны киләчәккә эшләтеп җибәрергә телибез!

Шәһәр мэры Илсур Метшинның хыяллары тагын да кыюрак. Ул әлеге зур проект кысаларында БМОның финанс үзәге өчен урын табарга тәкъдим итә. Бөтен дөнья илләренең хакимият органнары монә шушында үз утырышларын һәм киңәшмәләрен уздырсын!

– Идел буенда үз вәкиллекләрен ачарга ниятләгән иң мәшһүр дөньякүләм компанияләр моны кайсы шәһәрдә эшләргә икәнлеге турында уйлап торырга тиеш түгел. Сайлау нәтиҗәсе бер генә төрле булырга тиеш – Казан. Бу – безнең хыял! Теләсә нинди юлны беренче адымнан башлыйлар, шәһәребездә мондый мөмкинлекне тудыра алырга тиешбез. Хәзер безгә дөньяда башка калаларга әлеге юлны узарга булышкан иң яхшы белгечләрнең тәҗрибәсен кыенсынмый кулланырга кирәк. Шунысы да бар: һәрнәрсәдә үз айдентикабыз, күпмилләтле төбәк булуыбыз чагылырга тиеш. Моның Амстердам түгел, ә Казан икәнлеге күренеп торсын.

БАРЫСЫН ДА – ТӨЗЕЛЕШКӘМЕ?

Хыялланырга була, әлбәттә. Ә ул хыялларны тормышка ашыруга килгәндә, эшләр ничек тора? Казанның соңгы вакыттагы иң зур яңарту проекты җиңел булырга охшамый. Чыннан да, кыенлыклар хәттин ашкан, чөнки күз уңындагы территориядә 146 хуҗа бар. Барысы белән ничек килешеп бетәргә?

Берничә ел элек, реновация проекты уйланып кына ятканда, бу бик катлаулы мәсьәлә иде. Бүген исә бу процесс ул кадәр үк өметсез күренми – 373 нче Федераль закон шәһәр төзүчеләренә мондый проблеманы хәл итү өчен төгәл күрсәтмәләр бирә, процедураның барлык кагыйдәләрен билгели һәм җирле үзидарә органы инициативасы буенча шәһәр территорияләрен комплекслы яңарту өчен алшартлар тудыра. Димәк, милек ияләренә үз җирләрен киләчәктә дә, ләкин Генераль планга ярашлы рәвештә файдалану мөмкинлеге биреләчәк?

– Тулаем алганда шулай, – дип раслый Татьяна Прокофьева. – Порт урамы тирәсендә сыйфатлы юллар да, төзек яр буе да юк, инженерлык челтәрләре дә тузган, территорияне инженерлык таләпләре нигезендә ныгыту да кирәк, бу чыгымнарның бер өлешен инвесторларга күтәрергә туры киләчәк. Ягъни кишәрлек хуҗасы үз җирендә торак комплексы гына салып калмыйча, хосусый-дәүләт партнерлыгы нигезендә гомуми территорияне төзекләндерүдә катнашырга тиеш булачак. Бу иске территорияләргә җан кертүдә яңа алым түгел, тик калабызда ул беренче тапкыр кулланылачак.

«Хыял территориясе»нең бөтен матурлыгын күрә алыр көннәребез тиз генә килеп җитмәячәк әле. Әмма проектның этаплап тормышка ашырылачагы өмет уята: бу урында мәңгелек төзелеш барачак дигән уй калырга тиеш түгел. Татьяна Прокофьева сүзләренчә, барлык килешүләр имзаланып, рөхсәтләр алынгач, төзелеш мәйданчыгына чыгарга әзер инвесторлар – җир кишәрлекләренең хуҗалары инде бүген үк бар.

ЮЛГА – «ЯШЕЛ УТ»

Автор: Алсу Троицкая

Озакламый Мәскәү белән Казан арасын автомобильдә алты сәгать ярымда үтеп булачак. М-12 магистрален төзү өчен Россия хакимияте нәкъ дүрт ел вакыт билгеләгән. Бүген бу – Россиядә юл төзү буенча иң масштаблы проект. Безнең республикага аны гамәлгә ашырудан нинди файда киләчәк – «Татарстан» шуларны белеште.

ТАТАРСТАН «ТАРИХКА КЕРДЕ»

М-12 төзелешенә стартны Россиянең Премьер-министры Михаил Мишустин 10 июльдә «Алабуга» МИЗнда Европа–Көнбатыш Кытай транспорт коридоры проектын гамәлгә ашыру буенча киңәшмә вакытында бирде. Сүз уңаеннан, аның төзелешен элеккеге хөкүмәт билгеләгән сигез елдан дүрт елга кадәр кыскарттылар. Бу турыда 2020 елның май аенда РФ вице-премьеры Марат Хөснуллин белдерде, ул әлеге проектны шәхси контролендә тотачак.

Юл төзелешенә чынлап та «яшел ут» бирүләре турында Алабугадагы шул ук киңәшмә вакытында билгеле булды. Россия хөкүмәте башлыгы М-12 буенча конкурс процедураларының вакытлары расланган инде, дип хәбәр итте. 10 сентябрьгә подрядчылар арасында конкурслар төгәлләнергә, ә 10 ноябрьгә кадәр территорияләрне планлаштыру буенча документлар эшләнеп бетәргә тиеш. «Автодор» Дәүләт компаниясендә әлеге бурычларны башкарып чыгу мөмкин, дип саныйлар.

«Мәскәү–Казан» М-12 трассасының проекты Россиянең 2024 елга кадәр исәпләнгән Магистраль инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтүнең комплекслы планына кергән һәм 8,5 мең чакрым озынлыктагы Европа–Көнбатыш Кытай транспорт коридорының бер өлеше булып тора. Ул Кытайның Шанхай шәһәреннән Германиянең Гамбургына кадәр суза.

Мондый масштаблы проектлар – төрле хезмәт күрсәтүләр, эшче куллар һәм техникага ихтыяҗ тудыруы белән икътисадый кризисларны урап узу өчен менә дигән чара. Шулай ук бу юл уза торган төбәкләр өчен дә драйвер булачак ул. Татарстан мантыйк ягыннан да, географик яктан да әлеге схемага туры килә. Экспертлар раславынча, Европа–Көнбатыш Кытай транспорт магистрален гамәлгә ашыруның социаль-икътисадый яктан иң зур файдасы нәкъ менә безнең республикага, шулай ук Түбән Новгород һәм Самара өлкәләренә булачак.

ЮЛ НИНДИ БУЛАЧАК?

Проектны тормышка ашырачак «Автодор» Дәүләт компаниясенең матбугат үзәгендә хәбәр итүләренчә, трассага беренче техник категория биреләчәк. Димәк, М-12нең һәр юнәлешендә икедән дә ким булмаган полоса булачак, юл буеннан-буена яктыртылачак һәм монда сәгатенә 130 км тизлектә йөрү рөхсәт ителәчәк. Автомобильләрнең капма-каршы агымы аерым булачак, юл чатлары, борылышлар һәм җәяүлеләр өчен аркылы чыгу юллары бер яссылыкта ясалмаячак. Проект авторлары бу чаралар трассада юл-транспорт һәлакә-

Фотолар: «Автодор» Дәүләт компаниясенең матбугат үзәгеннән, автордан алынды

– М-12нең безнең район аша узган өлешендә менә дигән итеп туристик сервис оештыру мөмкинлеге бар.

тендә һәлак булучыларның санын 3,5 тапкырдан да күбрәккә киметәчәк, дип ышандыра.

«ТҮБӘН СТАРТТАН» БИЗНЕС

Зәкиулла Минһаҗев, Югары Ослан районы башлыгының архитектура һәм төзелеш мәсьәләләре буенча киңәшчесе, булачак проектны эшкуарларны җәлеп итәргә сәләтле, дип саный:

– М-12нең безнең район аша узган өлешендә менә дигән итеп туристик сервис оештыру мөмкинлеге бар.

– Халык арасында ризасызлык белдерүчеләр дә бар.

– Беләсезме, кемгәдер кояш та комачаулый. Ул кыздыра һәм тәнне пешерүе ихтимал. Билгеле, беркемне дә кузгатмый гына юл төзү мөмкин түгел. Халык трассировкага йогынты ясый алмый – законга ярашлы, федераль проектлар буенча халык фикерен тыңлаулар каралмаган. Шул ук вакытта аңларга да кирәк: әгәр проект кемнең дә булса мәнфәгатьләренә кагыла икән, алар тулысынча компенсацияләнә. Бу очракта җәмгыять, район, республика мәнфәгатьләре югарырак куелырга тиеш, дип саныйм. Югары Ослан районына килгәндә, М-12 төзелеше кемнеңдер шәхси мәнфәгатьләрен кысмый. Трассаның берничә варианты бар иде. Беренчесендә аны Кызыл Байрак аша салырга тәкъдим ителде. Бу очракта ул Ямбулат авылындагы эре яшелчә, җиләк-җимеш бакчасының нәкъ уртасы аша узарга тиеш иде. Төзәтмәләр керткәннән соң, соңгы вариантта трасса Гребени белән Нариман авыллары арасындагы участоктан узачак. Биредә республика ике як трассаны Идел аша күпер белән тоташтыра. Бу, мәсәлән, республиканың уң як ярында яшәүче халкына, Иннополиска, Ульяновск өлкәсе һәм Чувашия халкына М-12 трассасы буйлап Г. Тукай исемендәге аэропортка кадәр Казанга кереп тормыйча гына бару мөмкинлеге бирә. Әгәр шул ук кешеләргә республиканың көньяк-көнчыгышына, Казахстанга яки Оренбургка барырга туры килсә, М-12 магистраленә рәхим итсеннәр. Ничек уңайлы икәнен күз алдына китерәсезме? Моннан тыш, яңа күпер Иделнең Казан янәшәсендәге уң як ярын инфраструктура үсеше белән тәэмин итәчәк, шулай ук елга аша әлеге вакытта гамәлдә булган күпердә транспорт агымын киметәчәк.

Проект буенча М-12 трассасына ике урыннан керү күздә тотыла. Беренчесе – Кайбыч белән Ульяновск юллары аерылган урында, районның географик үзәгендә булачак. Икенчесе – Мулланур Вахитов исемендәге авыл янында. Биредә инде авыл зурлыгындагы мәйданда эре транспорт төене урнашачак. Билгеле, бу зона барлык юл буе сервисларын үз эченә алачак – автомобиль, заправка, ремонтлау һ.б. Биредә без транзитчыларны һәм туристларны, юлдан «чыгарып», берничә көнгә матур табигатьле районга җәлеп итә алабыз. Биредә һәрьяклап Идел манзаралары ачылып китә – Югары Осланнан башлап, Кама Тамагына кадәр. Һәм биредә инде калганы үзебездән тора – туристларга нәрсә тәкъдим итүебездән. Кемпинг, кунакханәләр, рестораннар, кафелар... Районда туристлык маршрутлары бар: «Кече Ослан божрасы», «Олы Ослан божрасы», «Республиканың энҗе муенсасы». Аларны кызыклы эчтәлек белән баету өчен вакыт та бар. Биредә бизнес корырга теләгән эшкуарларныкы кебек үк. Районда яңа объектлар барлыкка киләчәк һәм нәтиҗәдә – яңа эш урыннары да.

ТӨБӘКЛӘРГӘ ФАЙДАСЫ

Европа – Көнбатыш Кытай магистраленнән иң күп социаль-икътисадый файда алучы бенефициар төбәкләр:
Түбән Новгород өлкәсе – 156 млрд сум;
Татарстан Республикасы – 146 млрд сум;
Самара өлкәсе – 141 млрд сум.

ТӘГӘРМӘЧЛӘР КҮП, ЯХШЫ ЮЛЛАР АЗ

Проектны тормышка ашырудан транспортчылар ни рәвешле отачак? Менә **«1 нче Казан пассажирлар автотранспорты предприятиесе» Акционерлык җәмгыяте генераль директорының үсеш буенча киңәшчесе Леонид Наумовның** фикере:

– М-7 федераль трассасы үзенең үткәрүчәнлек сәләтен күптән үтәде инде. М-12 гамәлгә кергәч, безгә, транспортчыларга, уңай яклар күбрәк булачак. Ул коммерция нигезендә булган хәлдә дә. Әгәр, «Автодор» Дәүләт компаниясе вәгъдә иткәнчә, юл хакы артык зур булмаса, ягулык чыгымнары, амортизация һәм вакыт азрак сарыф ителү хисабына ул акланырга тиеш. Мисал өчен, безнең предприятие Казаннан Ярославльгә кадәрге маршрутны хезмәтләндерә. Бүген без Чебоксар, Түбән Новгород аша йөрибез. Ә яңа юл гамәлгә кергәч, маршрут якынча 200 чакрымга кыскарачак. Килешәсездер, шактый сизелерлек аерма.

Транспортчы буларак, минем өчен куркынычсызлык мөһимрәк. Мәскәү–Санкт-Петербург трассасындагы аварияләрнең кимүеннән генә дә статистиканы чамаларга була. 2019 елда Мәскәүдән Санкт-Петербурга кадәрге коридорда юл-транспорт һәлакәтләренең саны ике тапкырга кимегән, ә үлүчеләр саны, 2016 ел белән чагыштырганда, өч тапкырга диярлек азайган. Ә менә М-7нең Мәскәү–Казан аралыгында 2018 елда 809 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, шуның 188е – үлем очрагы белән. Яңа трасса гамәлгә кергәч, 2030 елга үлемгә китергән юл һәлакәтләренең саны 25кә кадәр кимер, дип фаразлана. Яңа трасса куркынычсыз булуы өчен генә дә кирәк. Яңа юл салу өчен төп аргумент була алмыймыни бу?

«ЧАБАЧАКБЫЗ!»

Республика халкы биргән иң төп сораулар да урынлы яңгырый: авылларга бара торган юллар нинди булыр, трассадан бару өчен күпме түләргә кирәк, гамәлдәге юллар белән хәлләр ничек торачак? Бу сорауларга җаваплар зур тизлекле магистраль узачак районнарда яшәүчеләр өчен аеруча актуаль. Алар арасында Татарстанның Кайбыч районында яшәүчеләр дә бар. Бу турыда августта Олы Кайбычта авыл җирлекләре башлыкларының чираттагы очрашуында сөйләштеләр. **Кайбыч районы башлыгы урынбасары – Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Рәмис Хәялиев** сөйли:

– Зур тизлекле магистральнең иң озын участогы Кайбыч районы аша уза. Бу җәһәттән без уңдык, чөнки теләсә кайсы юл – үсеш дигән сүз. Сәнәгать учаклары, туктап тору базалары, әгәр бездә завод төзергә телиләр икән – каршы килмибез. Халыкка эш дигән сүз бит ул. Гаиләне ташлап, акча эшләргә дип, читкә чыгып китәргә кирәкмәячәк. Завод булмаса, башкасы барлыкка килер. Ул барыбер булачак, чөнки юл буена җитештерү үзәге кору табышлы икәнен мәктәп баласы да белә.

М-12 төзелеше турында Казанга туганнарга баргач ишеттем. Миңа: «Рәмис, беләсеңме, безнең район аша зур тизлекле магистраль узачак?» – дигәч, ничек, нинди юл дип, тизрәк интернетка кереп чумдым. Шунда ук безнең район аша гына узса ярар иде дип тели дә башладым. Мин һәрвакытта да төзелеш яклы – чиновник буларак та, гади кеше буларак та. Мәскәүгә юл Кайбыч аша узарга тиеш дип саный идем, шулай килеп чыкты да. Картада барысы да күренә.

Авыл җыелышларында юл турында сөйләгәндә, халык җанланып китә. Күптән түгел: «Рәмис Рафисович, юл читләрен кемдер чабачакмы?» – дип сорадылар әле. Халык көлешә, ә сорау дөрес куелган иде бит. Әйтергә кирәк, үләнен генә чабасы түгел, карын да чистартасы, чүбен дә җыясы, авыл хуҗалыгы техникасы һәм мал куа торган урыннарны да хезмәтләндерәсе булачак әле. Аны Мәскәүдән килеп эшләмәячәкләр бит инде. Димәк, безгә эш дигән сүз...

Без автомагистральнең проектчылары белән тыгыз элемтәдә торып, аңлашып эшләдек. Бәхеткә, алар безнең бөтен теләкләребезне дә исәпкә алды. «Минем җиргә керделәр» диярлек булмады. Барысы да килешеп, дөрес итеп эшләнде.

Фото авторныкы; «Автодор» ДК матбугат хезмәтеннән алынды.

– Юк, без монда Кайбыч шәһәре пәйда булсын дип теләмибез! Безгә шушы авылыбыз бик тә кадерле. Әмма ул үссен, яңа юл ярдәмендә районның инвестицияләр климатын җанландырып җибәрсен. Безнең үсәр мөмкинлекләребез бар...

Район башлыгы урынбасарының сүзен **Моралы авыл җирлеге башлыгы Ринат Зиннәтуллин** да раслый:

– Беренче вариантта трасса безнең иске зират өстеннән уза иде. Без үзгәрешләр кертергә тәкъдим иттек. Хәзер инде юл 200 метрга көньяктанрак уза. Варварларча эшләмәделәр, безнең аргументларны да кабул иттеләр.

Иске Тәрбит авыл җирлеге башлыгы Виталий Тимофеев М-12нең иң зур файдасы аларга тиячәк дип саный:

– Безнең районда трасса нәкъ менә бездән башланып китә. Чувашия белән чиктә. Безнең авыл халкы канәгать: магистраль боҗрасы бездән 7 чакрымда гына. Мәскәүгә эшкә йөрүчеләр бик күп. «Автодор» Дәүләт компаниясе идарәсенең рәисе Вячеслав Петушенконың сүзләренә караганда, җиңел машиналар өчен юл хакы бер чакрымга 2,5 сум булачак. Алай ук кыйммәт түгел. Казанга да, аэропортка да тизрәк бару мөмкинлеге туачак. Иң мөһиме – эш булачак.

Очрашуны йомгаклап, Рәмис Хәялиев өстәп куя:

– Көнчыгышта булып кайтканнар: «Сәмәрканд нинди матур шәһәр! Бохара – искиткеч!» – дип соклана. Чүлдә төзелгән шәһәрләр бүген дә кешеләрне сокландыра. Ни өчен шундый матур соң алар? Сәбәбе бик гади: алар кайчандыр Бөек Ефәк юлының үзәгендә урнашкан булган, анда Һиндстан, Кытай, Иран сәүдәгәрләре тукталган... Юк, без монда Кайбыч шәһәре пәйда булсын дип теләмибез! Безгә шушы авылыбыз бик тә кадерле. Әмма ул үссен, яңа юл ярдәмендә районның инвестицияләр климатын җанландырып җибәрсен. Безнең үсәр мөмкинлекләребез бар... т

ЭВОЛЮЦИЯ ДНКдан* БАШЛАНА

Автор: Ксения Сёмина

Күз алдына китерегез: Татарстан белән Удмуртия чигендә урнашкан авыл мәктәбе. Ишегалдында күчмә лаборатория тора. Ә анда алтынчы сыйныф укучылары, өстәлгән чынбарлык күзлекләре киеп, чүгендерне автомат рәвештә җыеп алу өчен агрегат проектлаштыру белән мәш килә – виртуаль чынбарлыкта...

* ДНК – КФУның Алабуга институты каршындагы Фәнни коллаборация йортының русча кыскартылмасы.

Фото: vk.com/kvantorium116; КФУның Алабуга институты матбугат хезмәте, Талантлар Университеты медиалабораториясе

«Кванториум» мобиль технопаркларында дәресләр якынча шулай оештырылачак. Заманча белем бирү техникасы белән тутырылган 340 ка якын автомобиль якын араларда Татарстанның зур булмаган калаларына һәм салаларына юл тотачак. Республикада мәктәп укучыларына өстәмә белем бирү юнәлешендә июль аенда игълан ителгән өч проектның берсе бу.

Проектлар «Мәгариф» милли проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында гамәлгә ашырыла. Аларны финанслау күләме (федераль һәм республика бюджетларыннан) 370 млн сумнан артыкны тәшкил итә. Әгәр гомумән милли проектның максатын билгеләүне күздә тотабыз икән, глобаль максат – «балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачу, хуплау һәм үстерүнең гаделлек, гомумилек принципларына нигезләнгән һәм барлык укучыларның да үзбилгеләнүенә һәм һөнәри ориентациясенә юнәлдерелгән нәтиҗәле системасын формалаштыру». «Татарстан» проектларның формасы аларның эчтәлегенә никадәр туры килүен аңларга тырышып карады.

ИҢ ЯХШЫСЫ – БАЛАЛАРГА!

Укучыларны җәлеп итүнең колачлылыгы һәм салынган акчаларның күләме буенча иң масштаблысы – Сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм ярдәм итүнең республика үзәге, ул «Сириус» Белем бирү үзәге моделе буенча оештырылачак. Үзәк Казанда «Казан ачык Талантлар Университеты 2.0» АКБО һәм Республика олимпиада үзәге белән хезмәттәшлектә ачыла. «Сириус» – ул федераль белем бирү үзәге, Сочида урнашкан. Анда фән өлкәсендә, спортта, сәнгатьтә һәм әдәби иҗатта югары уңышка ирешкән балалар өчен профильле сменалар эшли, алар белән үз өлкәсендә эксперт булган кешеләр шөгыльләнә. «Сириус» каршында торган бурычларның берсе – сәләтле бала белән аның потенциаль эш бирүчесе арасында үзара элемтәне тәэмин итү.

Хәзер мондый үзәк Татарстанда да пәйда булачак. Ул 1 сентябрьдән Республика олимпиада үзәгенең «Дуслык» савыктыру-белем бирү үзәге базасында эшли башлады. Талантлар Университеты директоры Айдар Акмалов сөйләвенчә, һәр айның 1нче көнендә ике яисә өч атналык профильле программа башланачак. Ел дәвамында өч юнәлеш буенча 12 программаны эшләтү планлаштырылган. «Дуслык»ның бер сменасы 140 лап баланы кабул итәргә әзер. Проектта катнашу балалар өчен бушлай. Юл, яшәү чыгымнарын һәм көненә биш мәртәбә ашатуны үзәк үз өстенә ала. Аның базасында 18 фәнни-тикшеренү лабораториясе, фән, сәнгать, спортның төрле юнәлешләре буенча мәйданчыклар һәм уку кабинетлары эшләячәк. Үзәк өчен җиһазлар, кирәк-яраклар сатып алуга 349 млн сумга якын акча бүленгән.

– Татарстанда ачылган үзәктә робот техникасы, виртуаль чынбарлыкта, өстәлгән чынбарлыкта эшләү, яңа дару препаратлары синтезлау, яңа материаллар уйлап табу, технологик процессларны симуляцияләү, әйләнә-тирә мохитне пычратуга каршы көрәш буенча дәресләр үткәрү өчен уникаль җиһаз-җайланмалар паркы булдырылды, – дип сөйли КФУның әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, «Сириус» мәгариф үзәге педагогы, Республика үзәгенең химия буенча профильле программаларын эшләүче Игорь Седов. – Үзенең җиһазлану дәрәҗәсе буенча үзәк кайбер университетлардан да алдарак тора. Сменага килүчеләр вуз вәкилләре белән хезмәттәшлек итәчәк һәм фәнни бурычларны хәл итүдә катнашачак. Фәнни эшчәнлеккә шул рәвешле җәлеп итү талантлы балаларны Татарстанда калдырырга ярдәм итәр, дип уйлыйбыз.

Оештыручылар хәбәр иткәнчә, проект «ТРның барлык муниципалитетларындагы теләкләре булган, күпмедер дәрәҗәдә инде уңышка ирешкән 10–17 яшьлек мәктәп укучыларына исәпләнгән». Әлегә программада катнашу өчен сайлап алу критерийлары камилләштерелә, шуңа да карамастан, «Казан ачык Талантлар Университеты 2.0» АКБО сайтының махсус бүлегендә инде бүген үк гариза калдырырга мөмкин.

КИТЕРЕП БИРҮ ПЕРСПЕКТИВАСЫ БЕЛӘН

Язмабыз башында сөйләнгән мобиль «Кванториум»ның бурычы бераз үзгәрәк. Ул өстәмә белем бирүнең ерак районнарда яшәүче балалар өчен дә мөмкин булуын расларга, укучыларда фәнгә һәм техникага кызыксыну уятуны һәм нәтиҗәдә техник һөнәрләрнең абруен күтәрүне тәэмин итәргә тиеш. Инде 2020 елда ук «тәгәрмәчле технопарк» Татарстанның Әгерҗе, Актаныш, Сарман, Зәй, Минзәлә һәм Менделеевск районнарына килеп чыгарга тиеш.

Мобиль «Кванториум»ның эчендә тәҗрибәләр үткәрү, модельләштерү һәм конструкцияләү өчен каралган комплекс урнаштырылган, ул өстәлгән һәм виртуаль чынбарлыкта эшләү аппаратурасын, 3D-принтерларны, лазер граверын, җыю һәм эретеп-ябыштыру зонасын үз эченә ала. Шулай итеп, балалар (5–11 сыйныф укучылары) мәктәп һәм мобиль технопарк базасында «VR/IT», «ГЕО/АЭРО», «РОБО/ Промдизайн», «Hi-Tech» юнәлешләре буенча турыдан-туры дәресләрдә катнаша алачак. Бер базада укыту-өйрәтүнең озынлыгы – 12 көннән дә ким түгел. Һәр юнәлеш буенча эшләнгән белем бирү программасы 36 сәгатьне күз уңында тота.

Мобиль «Кванториум» – ул, әйтергә кирәк, Яр Чаллыда стационар проект эволюциясе, аңа «КАМАЗ» ГАҖ актив ярдәм күрсәтә. Шул рә-

Мобиль «Кванториум»ның эчендә тәҗрибәләр үткәрү, модельләштерү һәм конструкцияләү өчен каралган комплекс урнаштырылган, ул өстәлгән һәм виртуаль чынбарлыкта эшләү аппаратурасын, 3D-принтерларны, лазер граверын, җыю һәм эретеп-ябыштыру зонасын үз эченә ала.

вешле компания үз җитештерүләре өчен кадрларны үстерү һәм сайлап алу мөмкинлегенә ия.

– Мобиль «Кванториум» шулай ук һөнәри һәм югары белем бирү оешмаларына да файдалы була ала. Без инде КФУның Яр Чаллы институты һәм Кама дәүләт автомеханика техникумы белән хезмәттәшлек итәбез. Алар профориентация буенча мастер-класслар үткәрәчәк, – дип сөйли Яр Чаллыдагы «Кванториум» балалар технопаркы директоры Юлия Фукина. – Ә безнең мәктәпләр белән уртак эшебез алдынгы технологик юнәлешләр буенча өстәмә белем биреп кенә калмый, бәлки авыл җирендә туып-үскән балаларга эре төбәк, бөтенроссия һәм халыкара чараларда катнашу мөмкинлеге дә тудыра.

ӨЗЛЕКСЕЗ БЕЛЕМ БИРҮ ЧЫЛБЫРЫ

Өченче белем бирү «премьера»сы 1 сентябрьдә Алабугада үтте. Биредә КФУның Алабуга институты каршында Фәнни коллаборация йорты (русча кыскартылмасы – ДНК) ачылды. ДНК – 5 яшьтән алып 18 яшькәчә балалар өчен өстәмә белем бирү үзәге. Проектка Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы җитәкчелек итә. Ел дәвамында биредә даими рәвештә 400 укучы бушлай шөгыльләнә алачак, ә 1500 гә якын бала бер ел эчендә проектлы олимпиадаларда, хакатоннарда, конкурсларда, акцияләрдә, мастер-классларда катнаша алачак. 5–9 сыйныф укучылары өчен «Шахмат әлифбасы» (5 сыйныф), «Робот техникасы» (6 сыйныф), «3D-модельләштерү һәм инженер графикасы» (7 сыйныф), «Сәнәгать дизайны: скетчинг һәм модельләштерү» (8 сыйныф) юнәлешләре булган «Балалар университеты» ачыла. Өлкән сыйныфларда укучыларны «Кече академия» программалары буенча кабул итәчәкләр, бу – «Мехатроника һәм микроэлектроника нигезләре» (10 сыйныф), «1С Предприятие 8» дә кушымталар эшләү» (10–11 сыйныфлар).

– ДНК балаларга иң яңа җиһазларда башкарыла торган компетенцияләрне үстерергә мөмкинлек бирә. Дәресләрне вуз мөгаллимнәре алып бара. Мәктәпләр исә ДНК базасында физика, химия, биология дәресләрен оештыра ала, – ди КФУның Алабуга институты директоры Елена Мерзон. – Проект мәктәп һәм вуз белемен берләштерә, ул белем алуның өзлексезлеген тәэмин итә. Бүгенге мәгълүматицифрлы гасырда планлаштырылган һәм бербөтенне тәшкил иткән белем бик кыйммәтле.

ПРОТОТИП «ЛЕГО»ДАН БАШЛАНА

Барлык бу проектлар – моңарчы бөтенләй булмаган нәрсәләр. Үзеңне эзләү, үстерү һәм һөнәр сайлау буенча мондый мөмкинлекләрнең Татарстан балалары өчен булганы юк иде. Шулай да «Һәр баланың уңышы» проекты кысаларында алып барылган кайбер инициативаларга карата сораулар туа. Мәсәлән, программада катнашу өчен баланың әзерлегенә карата куелган таләпләр артык югары түгелме. Әйтик, Талантлар Университетының Республика үзәгендә уку өчен, республика вузлары җитәкчеләреннән һәм сәләтле яшьләр белән эшләүче белгечләрдән торган экспертлар тарафыннан үткәрелә торган билгеле бер сайлауны узарга кирәк. Дөрес, балаларга икенче форсат та бирелә: конкурстан узмаганнар программаны дистанцион рәвештә мөстәкыйль үтә ала, ә аннан соң тагын бер мәртәбә гариза язып карап була. ДНК программасы шулай ук мәктәп программасы өчен гадәти булмаган юнәлешләрне өйрәнүне күз уңында тота. Бу предметлар чыннан да никадәр кирәкле соң? Программада катнашучылар боларның барысын да тарта алырлармы?

– Бүген җитештерү процессларын автоматлаштыру турында күп сөйлиләр. Эре предприятиеләрдә ул мехатрон чаралар ярдәмендә башкарыла. Шул ук вакытта әлеге сфера өчен җиһазлар эшләү һәм булдыру ягыннан без дөньядан шактый артта калдык. Шуңа күрә мехатрониканы дәресләр

ДНК – 5 яшьтән алып 18 яшькәчә балалар өчен өстәмә белем бирү үзәге.



программасына кертергә уйладык, – ди КФУның Алабуга институтындагы математика һәм табигать фәннәре факультеты деканы һәм ДНКда мехатроника укытучысы Заһир Латыйпов. – Чынлыкта әлеге предметта бернинди дә гайре табигый нәрсә юк. Бүген күп кенә балаларның программалаштырып була торган лего-роботлары бар. Асылда, бу шулай ук мехатроника нигезләре. Без микроэлектроника нигезләрен өйрәнәчәкбез, төрле материаллар белән эшләячәкбез, аларны кисәчәкбез һәм игәүләячәкбез, боларның барысын да механика һәм электрика белән берләштерергә, прототипларны конструкцияләргә һәм әзер мохиттә программалаштырырга өйрәнәчәкбез. Курс бер елга исәпләнгән, 9–11 сыйныф укучылары шөгыльләнәчәк. Шөгыльләнә башлар өчен бары тик бераз гына кызыксыну һәм яңа әйбер уйлап табу теләге генә кирәк.

МОХИТ ЭЗЛӘП

ДНК проекты елына 400 баланы колачлаячак. Талантлар Университеты проекты – елына 5% Татарстан укучысын. Программада катнашучы балаларның составы үзгәреп (ике тапкырдан да артык катнашып булмый) торуга да карамастан, әлеге программалар колачлаган балалар саны алай ук зур түгел. Ә калганнарга нишләргә? Бу очракта JuniorSkills проекты ярдәмгә килә ала, анда 12 яшьтән катнашырга була, «Киләчәккә билет» профориентация платформасы да, 6 сыйныфтан башлап, һәр балага үзенең һөнәри киләчәген сайларга булышуны күз уңында тота, башка проектлар да бар.

«Һәр баланың уңышы» проекты паспортын өйрәнгәндә тагын бер сорау туа – алар күбрәк технологик юнәлешле. Фәнни коллаборация йорты да, «Кванториум» да, беренче чиратта, җитештерүгә, сәнәгатькә, техникага кагылышлы өлкәләрдә белем бирә. Ә гуманитар белемнәр һәм иҗат белән нишләргә?

– Әгәр балада иҗади сәләт бар икән, өстәмә белем гаять мөһим. Классик белем иҗади фикерләүне үстерми, ул процессның үзен түгел, нәтиҗәсен ятатырга өйрәтә. Мәктәптә бирелгән программа буенча гына үсеш тәҗрибәсе алган балалар үзләрен иҗади яктан бик авыр ача. Ә бит креативлык, мәсәлән, – беренче чиратта стандарт булмаган бурычларны чишү ул. Иҗади кешене мохит формалаштыра – фикердәшләр, остазлар, хезмәттәшлек. Һәм ул мәктәптәге классик белем бирүдән һәм социумнан аерылып торырга мөмкин, – ди «Архидети» шәхси мәгариф проектын оештыручысы Гүзәл Мәхмүтова.

Дөрес, дәресләр өчен түләүне бөтен ата-аналар да күтәрә алмый, бигрәк тә гаиләдә берничә бала тәрбияләнсә. Әмма бу очракта да күңелең теләгән түгәрәкне сайларга була. Республикада бюджет нигезендә эшләүче клуб һәм секцияләр дә шактый. Өстәвенә, алар Казан, Яр Чаллы, Әлмәт кебек зур шәһәрләрдә генә түгел, кечерәк торак пунктларда да бар.

ҖИҢҮЛӘРНЕҢ АЛДАВЫЧ ҖИҢЕЛЛЕГЕ

Балага һөнәри (һәм шәхси) үсешнең киң һәм тигез сукмагына чыгарга булыша торган өстәмә белемне ул кайда алырга тиеш дигән сорауга Татарстан шактый тулы җавап бирә булып чыга, сайлау мөмкинлеге тудырылган. «Кайчан?» дип сорыйсы килә. Чөнки өстәмә белем бирүнең барлык программалары өстәмә дәресләргә исәп тота. Өстәвенә, аларның максатчан аудиториясе – 5–11 сыйныф укучылары. Алар исә болай да 6–7 дәрес укый, әле өй эшләренә дә вакыт кирәк. Өлкән сыйныф укучыларының әле БДИга да әзерләнәселәре бар.

– Минем фикеремчә, бу теләк һәм мотивациягә карый. Әлбәттә, өстәмә дәресләрнең берничә төрле юнәлешен бергә алып бару, бигрәк тә өлкән сыйныфларда, бик катлаулы. Нәтиҗәдә берсен сайларга туры килә. Ә кайсысын? Мин киләчәк компетенцияләрендә тукталыр идем, – ди «Архидети» проектына нигез салучы.

Бөтендөнья икътисади форумы аналитиклары фикеренчә, бу катлаулы мәсьәләләрне чишә алу, критик фикерләү сәләте, креативлык, кешеләр белән идарә итү, хезмәттәшлек күнекмәләре, эмоциональ интеллект, карарларны тиз кабул итү, клиентларга ориентлашу, сөйләшүләрне алып бара белү, когнитив сыгылмалылык.

– Бүгенге яшүсмерләргә таләпләр гаять югары. Бөтенесе дә моны күтәрә алмый. Шунысын да аңларга кирәк: бүген профориентация һәм белем бирү проектлары беренче чиратта блогерлар, ютюберлар, тиктокерлар һәм башка медиа персонажларның йогынтысы белән көндәшлек итә. Әйе, талантларны, күнекмәләрне һәм белемнәрне үстерү өчен матди һәм педагогик базаны булдыруга зур акчалар салынырга мөмкин. Ләкин бу нәтиҗәле булырмы, әгәр яшүсмергә үзен һөнәри яктан үстерү өчен озак һәм тырыш хезмәт белән мизгел эчендә килә торган дан һәм җиңел акчалар арасында сайларга туры килсә һәм ул икенчесен сайласа? – дип сөйли Гүзәл Мәхмүтова. – Шуңа күрә әгәр без балага һөнәри һәм социаль мохиттә үзен табарга дәүләт ничек булыша ала дигән сорауны тикшерәбез икән, мин профориентация һәм башка проектларга балалар өчен психологик ярдәм һәм яклауның кертелүен дә теләр идем. Мондый психологик ярдәм яшүсмергә бүгенге катлаулы дөньяда югалып калмаска һәм үзен табарга ярдәм итәр иде. Т

www.protatarstan.ru
Поиск...
Подписка!
РУС / ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Мәчкәрәдәге борынгы ташлар ни сөйли
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
09 сентября 2020
08 сентября 2020
Кирмәнчек: аяныч тарихлы оҗмах почмагы
Күч урыннары
Мегаполистан качучылар авылы турында
Мегаполистан – еракка
Ризаэтдин Фәхретдин: чорларны тоташтырган гыйлем иясе
Тарих битләре

Реклама 16+





Фотолар ТР Яшьләр эшләре министрлыгы матбугат хезмәтеннән; автордан алынды

БАЛАЛАР ХАКЫНА ЯҢАРЫШ

Автор: Катерина Котова

Татарстанда лагерьларны яңарту буенча «Җәй – балаларга» дип исемләнгән президент программасы тормышка ашырыла. Биш ел эчендә ул республикада балаларны савыктыру лагерьларына булган ихтыяҗ мәсьәләсен тулысынча хәл итәргә тиеш. Планнар бик зурдан. Ә чынлыкта эш ни хәлдә?

«ЙОЛДЫЗЛЫ»НЫҢ ЙОЛДЫЗЛЫ МӘЛЕ

Мин балачагым юлыннан атлыйм. Сул яктагы беренче корпус эчендә караңгы да, кысан да. Тимер караватлар һәм сыерчык оясы кебек кечкенә тумбалар – бөтен җиһазы әнә шул. Уңайлыклар? Әлбәттә, урамда. «Тишек идәнле сарай»га төнлә йөгереп барып килү – квестның нәкъ үзе! Минем чордагы «Йолдызлы» әнә шундый – бераз шыксызрак иде, уңайлыклары да ташка үлчим. Тик нәкъ менә биредә 1987 елда мин беренче тапкыр «Аҗаган»да уйнадым, гитарада чиертергә өйрәндем, сәхнәдә чыгыш ясадым…

– Кирәк бит – ничә елдан соң нәкъ менә монда репортаж ясарга туры килсен әле – бик теләсәң дә, алай булмас! – дип, Лаеш районында урнашкан «Йолдызлы» балалар савыктыру лагере директоры Руслан Шәмсетдинов белән балачак хатирәләремне уртаклашам.

– Узган җәйгә кадәр биредә барысы да хатирәләрегездәге кебек иде, – ди ул. – Озак еллар дәвамында берни дә үзгәрмәде, агып интектермәсен өчен, 2014 елда түбәләрне яңартуны искә алсак кына… Беләсезме, лагерьның бер ел эчендә шулкадәр үзгәрә алачагына берәү дә ышанмады.

Әлеге урынның, тамырдан үзгәртеп корылуы (һич арттыру түгел) лагерьларны яңарту максатын күздә тоткан «Җәй – балаларга» президент программасы ярдәмендә мөмкин була. Биш елга исәпләнгән программа 2019 елда старт ала, бу вакыт эчендә Татарстанда 94 объект төзекләндерелергә яки юктан бар итеп төзелергә тиеш.

Сүз уңаеннан, 1996 елда республикада балалар савыктыру лагерьларын башка максатларда куллану өчен үзгәртеп коруга тыю кертелә. Шул тыю бәрабәренә балалар ялы учреждениеләре челтәре саклап калына. Бүген ул 150 дән артык объектны үз эченә ала, тик аларның күбесе искергән, таушалган яки бөтенләй җимерек хәлдә. Программа башланганнан бирле, 23е капиталь төзекләндерелгән. Быел республика бюджетыннан тагын 10 балалар савыктыру лагерен ремонтлау һәм төзү өчен миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Әйе, планнар, чыннан да, галәмәт зур. Әмма аларны тормышка ашыру инде алай буй җитмәс нәрсә булып күренми.

Руслан Шәмсетдинов мине экскурсиягә алып бара. Сүз уңаеннан, хәзер «Йолдызлы» гади лагерь гына түгел, ә «Сәләт» хәрәкәте базасы, талантлы яшьләрне үстерү мәйданчыгы булып тора. Смена башланыр алдыннан соңгы вак-төякләрне генә эшләп бетерәсе калган – тагын берничә көннән бирегә бөтен республикадан, хәтта Россиянең башка төбәкләреннән сәләтле балалар җыелачак.

– Иске корпуслардан диварлары гына калды, – ди директор, минем өчен тарихи булган бинага алып килгәч. – Хәзер исә барлык уңайлыклар үзендә. Лагерьда барлыгы 7 корпус бар, алар бер сменада 220 баланы кабул итәргә әзер. Шул исәптән, мөмкинлекләре чикле балаларны да. Алар өчен уңайлы мохит булдыруыбыз – безнең өчен аерым горурлык. Бу да бер яңалык.

Корпус эченә узабыз. Ни дисәң дә, космос темасы сүз өчен генә тормышка ашырылмаган. «Җир – безнең йортыбыз» – бизәлешләре дүрт вариантта башкарылган бүлмәләрне җиһазландыру концепциясен әнә шулай гомумиләштереп исемләргә мөмкин. Безнең алда су, урман, таулар һәм кыр стихияләре. Чамалавым буенча «үземнеке» дип уйлаган бүлмәгә керәм, ә анда – елга! Диварларда – зәңгәр дулкыннар, тәрәзәләрдә – үтә күренмәле «су»ны хәтерләткән пәрдәләр. Хәзер биредә якты да, иркен дә. Ике катлы караватлар җыйнак күренә, эчкә кертеп ясалган шкафлар һәм заманча тумбаларда футболка белән шортыга гына түгел, алмаш аяк киеме, курткалар һәм хәтта чемоданнар өчен дә урын табылачак. Матур да, уңайлы да.

Ясалма газонлы футбол кыры, баскетбол һәм волейбол мәйданчыклары, шулай ук воркаут зоналары һәм лагерьның бөтен территориясенә сибелгән тренажерлы һәм турниклы атлетика комплекслары – 1973 елда төзелгән «Йолдызлы» хәзер әнә шундый. Лагерьның реконструкциясе әле тәмамланмаган. Беренче этапта корпусларны, ашханәне һәм административ блокны төзекләндергәннәр, шулай ук яңа җылылык үзәге, трансформатор подстанциясен төзегәннәр, газ һәм җылылык китергәннәр – хәзер «Йолдызлы»да тормыш көннәр салкынайгач та туктап калмаячак. Димәк, биредә тагын да күбрәк талантлы «йолдызчыклар» кабыначак.

Фото «Татар-информ» ИА, «Бугульминская газета»дан алынды



ЯШЬЛӘРГӘ ЮЛ БИРЕГЕЗ!

Матур стильле җәмәгать киңлекләре, остаханә-павильон, скалодром, скай-парк, маҗаралар сукмагы һәм эко-сукмак, елга манзаралы күзәтү мәйданчыгы, шулай ук дистәләгән үзенчәлекле арт-объектлар. Һәм хәтта агачларда салынган йортлар! Боларның барысын да яшь архитекторлар уйлап тапкан, ә аннары – бик кызыклы һәм аңлаешлы концепция нигезендәге күркәм архитектура проектына әйләндереп, чынга ашырган. Шулай итеп, 1970 нче еллар башында Бөгелмәдән ун чакрым чамасы читтәрәк өзелгән Губин исемендәге балалар савыктыру лагерена җан өретелә.

«Акыл штурмы» яшь архитекторлар, урбанистлар, социологлар катнашкан «Марш-2018» архитектура воркшопы кысаларында уза. «Җәй – балаларга» программасы старт алыр алдыннан, ТР Яшьләр эшләре министрлыгы, яңа идеяләр эзләп, нәкъ менә шуларга мөрәҗәгать итә. Һәм бу – безнең республикада көчәеп барган менә дигән тренд.

– Архитектура – туктап калган музыка түгел, ә тере эшчәнлек, – диде проектны тәкъдим иткәндә «Сколково» фонды вице-президенты Елена Зеленцова. Һәм менә дигән мисал китерде – Мәскәүдәге Достоевский исемендәге китапханәгә модернизациядән соң килүчеләр саны унике тапкыр арткан. Кайчандыр ташландык һәм җимерек хәлдәге Губин лагере да реконструкциядән соң танымаслык булып үзгәрә һәм бүген сменага ике йөзләп бала кабул итәргә әзер, өстәвенә, ишекләре ел әйләнәсе ачык. Шул ук вакытта, архитекторлар фикеренчә, лагерь мәйданнары, төрле төркем кулланучыларның – балалармы ул, тулы бер гаиләләр яки спорт командаларымы – ихтыяҗларына туры китерелеп, бик җиңел үзгәртеп корыла ала. Бу урынның аерым горурлыгы – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен уңайлы мохит тудыру: лагерьда хәрәкәте чикле алтмыш кеше берьюлы ял итә ала. ТР яшьләр эшләре министры Дамир Фәттахов сүзләренә караганда, шул рәвешле республикада, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның бала чагын кызыклы үткәрү өчен, тиешле шартлар тудырыла.

Сүз уңаеннан, проектлауга бәйле барлык яклар катнашындагы ачык фикер алышулар – «Җәй – балаларга» программасы кысаларында бик актив кулланыла торган яңа ысул.

– Әйе, без яшьләр объектларын яңарту эшенә карашны үзгәрттек, – дип сөйли Дамир Фәттахов. – Иң беренче булып яшьләрдән сорау, аларга объект концепциясен һәм төзүчеләр өчен техник биремне формалаштыру мөмкинлеге бирү – бу принципиаль позиция шуннан гыйбарәт. Элек төзүчеләр килеп, үзләре матурлык төшенчәсен ничек күзаллый, барысын да шулай итеп эшләп куя һәм нәтиҗәдә яшьләрне бөтенләй җәлеп итми торган мәйдан килеп чыга иде. Хәзер бөтенләй башкача эшлибез...

Бүген министрлыкта Яшьләр мохитен реновацияләү институты эшли, анда азу ярган осталарның тәҗрибәсе яшь архитекторлар һәм Казан архитектура-төзелеш университеты студентларының яңача карашы белән тулыландырыла. Сүз уңаеннан, студентлар балалар лагерьларын яңарту белән бәйле фикер алышуда актив катнаша. Яңа проектларга караганда, егетләрдә идеяләр фонтандай ташып тора.

– Космонавтлардагы кебек, ризыкны тюбикларга салып бирү идеясе берәүнең дә башына килмәдеме? – дип шаяртып сорап куям Руслан Шәмсетдиновтан.

– Юк, «Йолдызлы»да һичнәрсәне тюбикларда бирү каралмаган. Биш тапкыр туклыклы итеп ашату булачак – барысы да нормаларга туры килерлек итеп, – дип көлә ул. – Былтыр без сменадагы балаларга яңартылган лагерь концепциясен тәкъдим иттек. «Юк инде! Сез монда ясаган бөтен нәрсә – уйдырма гына! Моны чынга ашырып буламыни?» – диде алар. Шул ук вакытта балалар архитектура белән бәйле мәсьәләләрне эшләп бетерүгә актив кушылды. Мәсәлән, ашханәдәге төрлечә үзгәртеп була торган алтыпочмаклы өстәлләр – аларның теләге. Андый идеяләр җитәрлек иде. Асылда, биредә ял итәргә тиешле балалар лагерь концепциясенең автордашлары булды.

Фото ТР президенты сайтынан

УҢАЙЛЫК КЫНА ТҮГЕЛ...

Шәхсән мине мондый яңа архитектура рухландыра гына. Төгәл линияләр һәм гади формалар, экологик чиста материаллар, аңлаешлы урнашу һәм шактый җиңел рухлы дизайн... Дөрес, күңел күбрәк яшеллек сорый – хәер, анысы акрынлап булдырыла торган эш. «Аргамак» балалар савыктыру лагере башка берсенә дә охшамаган. XXI гасырда «нуль» дән төзелгән беренче лагерь Кама Тамагы бәхетенә эләкте.

Биредә балалар өчен актив һәм уңайлы ял оештыруның барлык шартлары да тудырылган – җиһазландырылган күркәм йокы корпуслары, ашханә, клуб, волейбол, баскетбол һәм мини-футбол өчен өч спорт мәйданчыгы, шулай ук урам тренажерлары, ябык җәйге сәхнә, медпункт... Бер сменада «Аргамак» туксан баланы кабул итәргә әзер. Аны төзүгә барлыгы 230 миллион сумнан артык акча тотылган. Яңа лагерьның сынау проекты «Татинвестгражданпроект» белгечләре тарафыннан эшләнгән һәм киләчәктә тормышка ашыру өчен үрнәк булачак. Мондый инфраструктура булмаган сигез район – Аксубай, Арча, Югары Ослан, Кайбыч, Менделеевск, Балык Бистәсе, Сарман һәм Теләче районнарында шушы типтагы лагерь төзү планлаштырылган инде.

Тик, әлбәттә, яхшы балалар ялы өчен уңайлылык кына мөһим түгел. Бәхеткә, программада катнашучылар моны аңлап эш йөртә. Гадәттәгечә, республикабызда лагерьлар профильле сменалар форматында эшли. Яңалары да, кабат җан өретелгәннәре дә чыгарма булмаячак, киресенчә, үз юнәлешенең әйдәп баручыларына әверелерләр, шөт. Әйтик, «Аргамак» лагере этномилли туризмны үстерү мәйданчыгы итеп уйланылган, «Сәләт» хәрәкәтенең тагын бер базасы ул, димәк, яшьләрнең иҗади потенциалын үстерү үзәге дә булачак.

Татарстанның тагын бер горурлыгы – Түбән Каманың «Кама» лагере. «Кама Артегы» дигән дан яуларга өлгергән лагерьны реконструкцияләүнең беренче этабы быел төгәлләнде. «Кама Артегы» Россиянең иң эре лагерьларының берсе булыр, дип планлаштырыла. «Зәңгәр күл» лагере белән берләштерү хисабына ул бүгенге көндә 15 гектарга якын территорияне били. Реконструкциянең икенче этабыннан соң лагерьның сыйдырышлылыгы 1528 урынга җиткереләчәк.

– «Кама» бик матур урында иде, без проектның бер үзенчәлеге булырга тиеш дигән карарга килдек һәм бу үзенчәлекне Түбән Кама хакимияте белән бергә эзләдек. Барысы да «Артек» җитәкчелеге белән очрашуда ачыкланды, – дип сөйли Дамир Фәттахов. – Хезмәттәшлек инициативасы белән чыктык – бу алар тарафыннан хупланды. Нәтиҗәдә, килешүгә кул куеп, без «Губерна лагере» проектына кушылдык, икенче төрлерәк итеп әйткәндә, шул рәвешле «Артек»ның сыйфат билгесен алуга ирештек. Хәзер Татарстанда «Артек»ның үз филиалы бар. Мондый ышаныч белдерелгән, ягъни легендар лагерь программасы буенча эшләү мөмкинлеге бирелгән төбәкләр күп түгел.

Министр «Кама» илнең иң яхшы балалар лагерьларыннан берсенә әйләнер дип ышана. Моның өчен аның бөтен мөмкинлекләре дә бар – яңартудан соң лагерь территориясе шулкадәр заманчалаштырылды һәм уңайлыга әйләнде ки, ул төзекләндерү мәсьәләсендә барлык «губерна лагерьлары» арасында рекорд куя. Яңарыш дулкыны хәтта озак еллар бу урынның символы дип саналган, үзләренең кирәк булачагын алдан күрепме, могҗиза белән генә сакланып калган пионерлар сынына да кагыла.

«Артек»ның үзендә сменаларның профиленә бәйле сораулар тумаса да, башка лагерьлар өчен андый мәсьәләләр буа буарлык. Яңа лагерьлар өчен тематик программаларны кемнәр һәм ничек эшли? Теге яки бу юнәлештә танылган педагоглар һәм белгечләр җәлеп ителәме? Гомумән, теге яки бу тематик программаларга ихтыяҗ ничек бәяләнә? Әйтик, космик тема белән кызыксынучы табылмаячак, ә инглиз теленә өстенлек биргән лагерьга, киресенчә, борын тыгар урын калмаячак, ди?

ТР Яшьләр эшләре министрлыгында, тематик программаларны эшләү белән республика гына түгел, Россия дәрәҗәсендәге тәҗрибәле белгечләр шөгыльләнә, дип тынычландыралар. Тиешле өлкәләрдән практик белгечләр дә җәлеп ителә. Әйтик, киләсе елда, илебез кешенең галәмгә тәүге очышының 60 еллык юбилеен билгеләп үткән вакытта, Горбунов исемендәге Казан авиация заводы һәм Казан вертолет заводы космик тематика буенча эшләгән «Восток» лагере партнерлары булачак. Моннан тыш, «Роскосмос» дәүләт корпорациясе белән төрле уртак чаралар үткәрү планлаштырыла.

Галәм киңлекләрен яулаган елларда Аккош күленнән ерак түгел генә төзелгән «Восток» билгеләнгән темасына бүген үзенең килеш-кыяфәте белән тулысынча туры килә. Аның һәр корпусы безгә берәр легендар космонавт яки космик кораб турында мәгълүмат бирә. Лагерь космос һәм техника белән мавыккан берьюлы ике йөз баланы кабул итә ала. Яңа Гагариннар һәм Королевлар үстерүгә өмет итеп, лагерь сменаларын әзерләүче Казан федераль университеты һәм аның астрономия обсерваториясе галимнәре әлеге кызыксыну-мавыгуларны үстерүдә булышырга вәгъдә итә.

Теге яки бу профильле сменаларга ихтыяҗ мәсьәләсенә килгәндә исә, ул иҗтимагый тикшерү өлкәсенә карый, операторлар арасында эчке конкуренция мәсьәләсе, базарның үз-үзен җайга салуы белән бәйле, дип аңлаттылар безгә ТР Яшьләр эшләре министрлыгы белгечләре. Ә яңа программаларның сыйфатына килгәндә, анысы инде ачык презентацияләр конкурсыннан тора, анда һәр оператор экспертларга, һичшиксез, нәкъ менә аның идеясен тормышка ашырырга кирәклеген расларга тиеш.

Сүз уңаеннан, «Җәй – балаларга» президент программасын гамәлгә ашыру балалар юлламаларының бәясенә турыдан-туры йогынты ясамаячак – быел да, киләсе елда да хакларның кинәт артуы көтелми, дип ышандыралар министрлыкта. Димәк, Татарстан балалары һәм яшүсмерләренең үз туган якларында уңайлы һәм файдалы ял итү мөмкинлеге бар. Хәзер аларга ул Төркия дигәннәренең кирәге шул чама гына... Т

ТАТАРСТАН:

Соңгы берничә елда республикада яшәүчеләрнең тормышын тагын да уңайлырак һәм тотрыклырак итүне күздә тоткан күп кенә программалар һәм проектлар эшләнде һәм гамәлгә кертелде. Әлеге проектларның иң яхшылары Стратегик инициативалар агентлыгының «Смартека» төбәк тәҗрибәләре белән алмашу платформасына урнаштырылды. Россиянең 8 төбәге Татарстанда гамәлгә ашырылган үрнәкләрне һәм тәҗрибәләрне үзләрендә дә булдырырга карар кылды.

БӨТЕН ИЛ ӨЧЕН ИҢ ЯХШЫ ТӘҖРИБӘЛӘР

ЯКУТИЯ

- Ерак торак пунктлар өчен «Мобиль поликлиника»
- Авыл кешеләре өчен «Цифрлы Авыл» онлайн-сервис системасы

БУРЯТИЯ

- Талантлар Университеты

ЕВРЕЙ АВТОНОМ ОКРУГЫ

- «Өченче яшь университеты» өстәмә белем бирү программасы

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Республика көне

ничек үтте

Татар җырлары

ничек итеп Киев

белән Казан

арасын бәйли

Австралиядә нинди

һөнәрләр югары

бәяләнә



РЕСПУБЛИКА. БЕРЕНЧЕ ЙӨЗЬЕЛЛЫК

30 августта күптәнге традиция буенча Казан Республика көнен– 100 еллык юбилеен билгеләп үтте. Үзенең йөз яшенә Татарстан яшь, актив үсештәге, уңыш казанган республика буларак атлады. Аны беләләр, яраталар, биредә укырга, яшәргә һәм эшләргә, ял итәргә хыялланалар. Бәйрәм көнендә Татарстанның башкаласы үзенә бик күп кунакларны җыйды: төрле районнарда һәм авылларда яшәгән үз халкы – татарстанлыларны, юбиляр белән туган көн шатлыгын уртаклашырга теләгән башка төбәкләрдәге дусларын, кунакларны. Ә уртаклашыр нәрсәләр күп – күңел ачу чаралары, сый-хөрмәт бөтен кешегә дә җитте.

Фото: Александр Ефремов; ТР Президентының рәсми сайтыннан

Сыегайтылган табигый газда эшли торган беренче пассажир судносы – «Чайка» үзенең беренче рейсына китә.



Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов байкерлар – «Кызыл Кремльдән – Ак Кремльгә» дип аталган мотосәфәрдә катнашучылар колоннасын җитәкләде.

PRESSA

Байкерлар, брейк-дансерлар, җырчылар, биючеләр, чакырылган йолдызлар... Ярышлар, узышлар, монгол самоварыннан бушлай аш, гармунчыларның Кремльгә кадәр баруы, татар бәхете – «Хюгге по-татарстански» китабын тәкъдир итү... Күп катлы йорт диварларын бизәгән мураллар да тирә-яктагы бәйрәм рухын хуплыйлар кебек.



Яңа «Урам» экстрим-паркында Республика көнен бәйрәм итү.

Башкалабыз кунаклары үзләрен бәйрәм фонында, бәйрәмне үзләренең фоннарында фотога төшеп мәңгеләштерделәр. Бәхетле селфи-мизгелләр бик тиз арада дөньяның төрле кыйтгаларына таралып, аларны караучыларга яхшы кәеф бүләк итте.

Димәк, бәйрәмдә барысы да катнашты: кечкенәләр дә, олылар да, биредә яшәүчеләр дә, туган ватаннарыннан еракта көн күрүчеләр дә, кыскасы, Мәгъриптән Мәшрикъка кадәр.

ТАССР
С праздником!
Бәйрәм белән!

ИСӘНМЕСЕЗ, ГАЗИЗ ЭМИГРАНТЛАР!

Аларның паспортларында, «туган урыны» графасында: «Татарстан» дип язылган. Өлкән яшьтәгеләрнең документларында – «Татарстан АССР». Ераграк яшәүчеләрдә «Россия» диелгән. Заманында башка илләргә һәм шәһәрләргә күчеп киткән кешеләр, Республика көне уңаеннан, үз Ватаннарына мәхәббәтләрен проза, шигырь яки җыр аша белдерә алды. Ә безгә, Татарстанда яшәүчеләргә, аларның бу хис-кичерешләрен уртаклашу мөмкинлеге бирелде, булганның кадерен белергә кирәклеге искә төшерелде. Әнә бит ул ничек авыр икән туган җиреңне сагыну мизгелләре.

Фотолар «Татарстан» журналы архивыннан

1

ВАТАНЫҢНЫҢ ТӨТЕНЕ ДӘ ТӘМЛЕ..

Туган урыны: Чаллы шәһәре, ТАССР

Америкада яшәүче Максим Лукашов – продюсер. Голливуд белән уңышлы хезмәттәшлек итә, Американың танылган кино йолдызлары өйләренә барып йөри, инглиз телендә йөгерек сөйләшә, проза әсәрләрен дә җиңелдән укый. Тик кайчагында «барысын да ташлап, билет алып, иртәгә үк Чаллыга очарга» хыяллана...

– Мин Америкада бик күптәннән яшим, биредә балалар гына түгел, оныгым да туды инде. Әйе, монда безнең гаиләгә уңайлы, җитеш тормышта яшибез, ә балалар бу шәһәр һәм бу илне туган җирләре буларак якын күрә. Мин инглиз телендә туган телемдәге кебек иркен сөйләшәм – хәтта үземә үзем шаккатам. Рус теле онытылмый, хәтта кайбер татар сүзләрен дә хәтерлим, Чаллыга кайткач, аларны, мәсәлән, кибетләрнең элмә такталарында күреп, турыдан-туры тәрҗемә итеп йөрим. Монда кайчагында мине сагыну хисләре буып ала. Сулышым кысыла, йөрәк атылып чыгардай булып тибә... Сагышымның анатомиясе әнә шундый икән минем. Күз алдына балачак, үсмер вакытлар килеп баса. Еш кына хатирәләр дә бик үк күңеллеләрдән түгел – үзара сугышулар, кибеттә сатучы дорфа кызлар белән кычкырышулар... Ләкин күбесенчә безнең ишегалды, таганнар, мәктәп, Кама – еш кына велосипедларга утырып анда коенырга йөри идек, сыйныфыбыздагы сөйкемле кызлар, учак янында гитара белән җырлап утырулар, университет каршындагы таба-эскәмия, Бауман урамы ишегалдында беренче тапкыр үбешүләр... Бу искиткеч якты хатирәләр алдында Нью-Йорк үзенең барлык утлары, биек йортлары һәм цивилизация уңайлыклары белән ничектер тоныкланып кала. Рус шансонын ярата башладым әле, эмигрантлар турында иске җырлар тыңлыйм: «Ватаныңның төтене дә тәмлерәк була бара... » Әйе, минем тормышым монда, ә күңелем – туган якта. Алар арасында шулкадәр зур ара булмасын иде, дип хыялланам. Мин анда кайтырга телимме? Кайчагында теләгем шулкадәр көчле була: барысын да ташлап, билет алып, иртәгә үк Чаллыга очарга хыяллана башлыйм. «Бигеш» аэропортында төшәр идем дә туган як һавасын күкрәк тутырып сулар идем. Тик, аңлашыла инде, һәрбер акыллы өлкән кешене кебек үк, мине дә бик күп төрле «ләкин» туктатып кала. Бармакларымны бөгә-бөгә саный, үземне үгетли башлыйм. Монда мин тамыр җибәрдем – йортым, балаларым, эшем бар. Аларның барысын да үзең белән алып китеп булмый, алган очракта да минем гаилә әгъзаларының Нью-Йоркны, мин туган ягымны юксынган кебек үк, сагынып ятмаслар, дип кем ышандыра ала? Шуңа күрә бу хисләремне җиңеп, америкалыларга хас киң елмаеп, моңа кадәр яшәгән кебек үк, яшәвемне дәвам итәм.

Кайчагында без рус дусларыбыз белән очрашулар оештырабыз. Алар Татарстаннан түгел, Оренбургтан, әмма мондый вакыйкларга игътибар итмисең. Бергә кичке аш ашыйбыз, аклы-каралы фоторәсемнәребезне карыйбыз, кызыклы вакыйгаларны искә төшереп көлешәбез. Ул вакытларны инде кире кайтарып булмый, алар туган якта гына түгел, ә балачакта ук калды. Шулай да аларны яратырга мөмкин бит, һәм без шулай итәбез дә. Балачагыбызны, яшьлегебезне, Ватаныбызны ихлас яратабыз, кадерлибез, аны сүз белән дә үпкәләтергә юл куймыйбыз. Россияне сүгүләренә түзеп тора алмыйм – минем каршыда берәү дә алай эшләргә батырчылык итми. Балаларны да шулай ук тәрбиялибез – илебезгә, аның кануннарына һәм гореф-гадәтләренә карата хөрмәт белән. Ялгышмасам, Шевченконың әйткән сүзләре бар: «Туган илгә мәхәббәте булмаган кешеләр, йөрәкләре белән хәерче гариплар».

Фотолар Диләрә Шкурконың гаилә архивыннан

2

ТАТАР ҖЫРЛАРЫ МИНЕ ТУГАН ИЛЕМ БЕЛӘН БӘЙЛИ

Туган урыны: Лениногорск шәһәре, ТАССР

Киев шәһәрендә яшәүче Диләрә Шкурко, сценарист, ‹‹СтарЛайтМедиа›› медиатөркеменең сериал департаменты мөхәррире, тумышы белән Лениногорскидан. Ул безнең журнал белән хезмәттәшлек итә, Украинадагы татар ансамбленең уңышлары, татарлар үткәрә торган милли бәйрәмнәр турында яза... Аның текстларыннан һәрвакыт туган җирен сагыну хисләре сизелеп тора.

– Бу хәл моннан 30 ел элек булды – Мәскәү–Киев поездыннан төшкәндә бу шәһәр минем өчен икенче ватанга әйләнер дип күз алдына да китермәдем... Чөнки ул чакта Украина – зур илебез булган СССРның бер өлеше иде, һәм мин аны берничек тә чит ил буларак кабул итә алмадым! Әдәбият буенча факультативта укыган Шевченко шигырьләре, София Ротару башкаруында бөтенхалык мәхәббәтен яулаган «Червона рута» җыры, мин укырга керергә теләгән Казан югары уку йортының Киев дәүләт университеты абривиатурасы белән туры килүе – болар барысы да ерак һәм шундый якын Киев белән туганлык хисләре уятты.

Башта сагынуым түзә алмаслык көчле иде... Уянганда үземне Казанда, Гвардия урамында әле дип уйлап, күп тапкырлар алдандым! Менә хәзер дөбердәп 12 нче трамвай туктар да мине университетка алып китәр! Ә радиодан Зөһрә Сәхәбиева бөдрә таллар турында җыр сузар... (Казанда яшәгәндә, татар эстрадасына әллә ни исем китми иде – Киевка килгәннән соң моңа шулкадәр үкендем!) Әйе, тирә-юньдә барысы да бик матур, кызыклы, «чит илдәгечә» иде, тик... нәрсәдер җитми. Пицца, мәсәлән. Биредәге пицца пиццамыни инде ул?! Ә менә Черек күл янындагы пиццериядә сыр һәм тавык итеннән әзерләнгән пицца бөтенләй башка! Ә Идел? Аның иксез-чиксез киңлекләре белән шундый ук зур, ләкин күңелгә ят булган Днепрны чагыштырып та буламы соң?.. Бервакыт җирле каштан һәм юкә агачлары арасында сирәк очрый торган каенны күреп елап җибәрә яздым! Чөнки шул ук мизгелдә Лениногорскидагы туган йортым ишегалдында үсеп утырган каен күз алдыма килеп басты. Еллар буе мин аның янәшәсеннән мәктәпкә үтеп йөрдем – ул йә үзенең көзге алтын киеменнән, йә апрельдәге сагызлы бөреләре белән, йә карлы авырлыгы белән мине һәр көн озатып торды, минем белән бергә үсте... Хәзер синең янәшәңнән кемнәр уза икән, туган каеным, дип уйладым мин, битләрем белән аның ефәк кәүсәсенә сыенып... Сүз уңаеннан, туган ягыма кайтуларымның берсендә мин каен-чибәркәйне тапмадым – аның урынында хәзер панель йорт үсеп чыккан. Балалар уйный, эскәмияләрдә пенсионер әбиләр утыра, кояшта песиләр кызынып ята... Рәхәт. Вакыт узган...

Киевта минем дә вакыт тик тормады. Кызыклы эшкә урнаштым, кыз балам туды, ирем белән гаиләбез оясын кору белән мәшгуль булдык – сагыну хисләре акрынлап сүрелде, әмма һәрвакыт минем белән калды. Бер үк мәктәптә укыган якташ кызның Киевта яшәве турында белү тормышымда зур борылыш булды. Төрле сыйныфларда укыганбыз, әмма бу мөһиммени соң?! Лениногорскидагы әниләребез элемтәләр белән алмашкан, һәм бер көнне миңа Гүзәл, шалтыратып, үзе җырлый торган «Талир» ансамбле чыгышына чакырды. Концерт дәвамында күз яшьләремне тыя алмый утырдым... Зәңгәр күлмәкле, ак алъяпкычлы кызларның тавышлары миңа шулкадәр чиста, назлы һәм якын тоелды. Бу концерттан соң бер ел да узмады, мин үзем дә шундый ук күлмәк киеп, яңа дусларым белән бергә сәхнәгә чыктым! Иң яраткан җырыбыз «Казан кичләре» иде һәм шулай булып кала да. «Кил әле, Иделнең җиләс җиле, юлларга чәчәкләр сип әле. Ак булып, саф булып истә калсын, Казанның кадерле кичләре...» дигән сүзләргә без никадәр моң-сагыш, сагыну һәм өмет хисләре салганыбызны тыңлаучылар арасында аңлаучылар бардыр дип уйлыйм...

Татар җырлары минем өчен эчкерсез шатлык чыганагы да, юаныч та, Ватан белән мине бәйләп торучы да. (Мин еш кына Киевта сәхнәдән тыш та калфак һәм читекләр киеп йөрим – үз милләтеңнең вәкиле булу билгесе бу). Мәсәлән, безнең ансамбль зур энтузиазм белән Татарстан Республикасының 100 еллыгына багышланган Халыкара вокал флешмобында катнашты – без, 20 ил җырчылары белән бергә, «Мин яратам сине, Татарстан!» җырын башкардык. Мин яратам. Сагынам. Туган ягыма кайту өметен йөрәгемдә саклыйм...

3 ТУГАН ЯК ИСТӘН ЧЫКМЫЙ

Туган урыны: Балтач районы, ТАССР

Финзия Газизова, ТНВның элеккеге журналисты, бүген Австралиядә яши, блогерлык эшен алып бара, 20 меңнән артык язылучысы бар...

– Австралиядә яши башлавыма ике ел була. Һич онытасым юк: бүгенге кебек табигатьтә яз иде. (Россиядә көз булганда монда яз). Ирем аэропорттан каршы алды да, без үзебез яши торган бистәгә юл тоттык. Казанда калган яңгырлы салкын көннәрдән соң, монда бөтен җирнең шау чәчәктә утыруын күреп, күңел сөенде. Бер елга ике тапкыр язны очраттым бит, менә бәхет, дип уйладым шул чакта. Юл кырыенда үскән күз күрмәгән чәчәкләр, агачларга карап, үземнең бөтенәй икенче дөньяга килеп эләгүемне аңладым.

Эвкалипт агачларынының исе миңа уңай тәэсир итте. Сулышларым ачылып китте. Эвкалипт дигәннән, монда ул һәр йорт каршында үсә. Әлеге агач Австралиянең символы булып санала, шуңа да хөкүмәт рөхсәтеннән башка аны кисәргә ярамый.

Ирем Рифкать Австралиядә 20 ел яши. Тамырлары Кукмара белән Балтач якларына барып тоташа. Безне Казанда уртак дуслар таныштырган иде. Никах укытсак та, баштагы 3 елда бергә яшәп булмады. Австралиягә китәргә җыенгач кына әтием үлем китте, аннан виза белән проблемалар килеп чыкты

Австралиядә яши башлагач, иң авыры тел белмәү һәм эсселек булгандыр. Монда нигездә инглиз телендә аралашалар. Мәктәптә, университетта да инглизчә укымаганлыктан, миңа аны үзлектән өйрәнергә туры килде. Хәер, әле хәзер дә өйрәнәм.

Балаларның миңа караганда инглизчәләре яхшырак, алар телевизор карый, яшьтәшләре белән аралашалар. Без өйдә бары татарча сөйләшәбез. Ә эсселек дигәннән, җәен биредә 50 градуска кадәр җитә. Урамга чыкканда махсус гель, кремнар сөртмәсәң, янасың.

Урамнарда җәяү йөрүчеләр бик сирәк. Хәтта 80–90 яшьлек әби-бабайларның барысы да диярлек машина йөртә. Әбиләрнең өйләреннән таяк белән чыгып, машинасын кабызып китеп баруы башта бик кызык тоела иде.

Тагын бер истә калган очрак: Австралиягә килеп, ике көн торгач, безне бер юбилейга чакырдылар. Хатын-кызлар аерым, ирләр аерым утырды. Өстәлгә пылау, башка ризыклар чыкты. Ашаганнан соң, ризыкларны җыеп алдылар. Өстәл буп-буш калды. Һәм... көнбагыш чыгардылар. Бер заман бөтен кеше алдына кәгазь куеп, көнбагыш чиертә башлады. Шул вакытта шаккаттым дию генә аз! (Соңыннан белдем, бу шундый гадәт икән).

Чисталыкка игътибар иттем – урамнан барганда берниндәи кәгазь, чүп күрмисең. Яшеллек, чәчәкләр... Машина йөрткәндә дә берниндәи кычкыртучы, бездәге кебек кистереп китүчеләр юк. Юлда йөрү тәртипләре бөтенләй башка – кешеләрнең сабырлыклары сизелеп тора.

Тагын бер үзенчәлек: кибетләр янына зур савытлар куелган. Җирле халык, кими торган киемнәрен шунда алып барып сала. Соңыннан аны махсус кибетләрдә арзан бәядән саталар. Аз керемле кешеләр шуннан киенә. Шулай ук юл кырыйларына хуҗалар үзләре кулланмый торган телевизор, шкафлар, күн диваннарны чыгарып куя. Әгәр ул юл кырыенда ике-өч атналап торса, хуҗасы махсус хезмәткә шалтыратып әйтә. Һәм әйберләрне килеп алалар.

Медицинага килгәндә, монда сырхауханәләрдә бер чират та юк. Алдан язылган вакытыңа киләсең дә табиб янына керәсең. Татарстандагы кебек, шәхси дәвалау үзәкләре бар, дәүләтнекеләр бар. Ә менә теш табиблары кыйммәт. Бер теш ямату миңа Россия акчасы белән 25 мең сумга чыкты. Узган ел, туган ягыма кайткач, тешләрне яматып килдем – бездә арзан бит.

Биредә табиблар балаларга дару бирү яклы түгел. Күптән түгел балам суык тиеп авырды, температурасы

Фотолар автордан алынды

38 булса да, табиб дару язмады. Антибиотикны бөтенләй сирәк бирәләр. Йөткергәндә дә сөт кайнатып эчәргә, диләр. Гаҗәп, әмма дарусыз да дәваланып була икән.

Сәламәтлек темасын дәвам итсәм, монда тәмәке тартучыларга авырга туры килә. Тәмәкенең бер кабы Россия акчасы белән 2 мең сум тора. Австралиядә бездәге кебек гел көйрәтеп йөрүчеләр юк диярлек.

Халык яхшы яши дияр идем. Эшсезләр саны 5 процент чамасы гына. Ә эш таба алмаучыларга хөкүмәт компенсация түли. Ашау, яшәү өчен ул акча җитә. Күп балалы гаиләләргә, үз нормалары буенча керемнәре булмаганнарга да, дәүләт тормыш итәрлек акча түли. Мисал өчен, бер күп балалы гаиләне белəм, йортны арендалап торалар. Һәм аренда акчасын аларга дәүләт түли. Ә машина – байлык билгесе түгел.

Әйткәнемчә, монда 90 яшьлекләр дә машина йөртә. Йортлар, җирләр бик кыйммәт. Россия акчасы белән 20 миллион сум тирәсе.

Хезмәт хакларына килгәндә, иң зур хезмәт хакы алучылар электрик, инженер, укытучылар, юристлар, табиблар, полиция хезмәткәрләре, программистлар, сантехниклар санала. Бездә дә бит сантехник кара хезмәт булып исәпләнә. Ә биредә аларга караш башка. Еллык керемнәре – австралия доллары белән 100–150 мең. Ә менә кафеларда эшләүчеләрнең хезмәт хакы чагыштырмача аз.

Австралияне күпләр көнгерәләр иле дип белә. Һәм бу шулай да. Биредә аларның 69 төре бар, диләр. Ярты килолыдан башлап, 90 килога кадәр җиткәннәре бар икән. Көнгерәләр һәр җирдә дә юк. Без Аделаида шәһәре үзәгеннән 7 чакрым еракльıкта яшибез. Зур булмаган мәхәллә ул. Халык шәхси йортлар белән яши. Йортлар янында көнгерәләр юк. Әмма паркларда, плантацияләр ягына барганда, көнгерә очрый.

Көнгерәләр белән берничә тапкыр очрашырга туры килде. Беренче тапкыр аны инҗир җыярга баргач күрдем. Агач арасыннан чыкты ул, шундый зур иде. Куркудан тиз генә машинага йөгердем. Күрми калып, шоферлар көнгерәләрне бәрдергән очраклар да күп. Шуңа юлларга билгеләр куялар. Мондый җирдән барганда, тизлек зур булырга тиеш түгел.

Австралиягә күченеп килгәч тә, ирем иң беренче чүп белән дөрес эш итәргә өйрәтте. Чүпләрне өч төргә бүләләр. Пластик савытлар, йогурт стаканнарын, консерва банкаларын чайкап, ишек алдындагы сары контейнерга ташлыйбыз. Полиэтилен, кәгазь, катыргы, пыяланы да шунда салабыз. Азык-төлек калдыкларын яки икенче мәртәбә эшкәртеп булмый торган чүпләрне кызыл капкачлы контейнерга тутырабыз. Тагын яшел капкачлысы бар, анысына яфрак, агач атыла. Чүп контейнерларын атнага бер тапкыр – сишәмбе алып китәләр. Чүп савытларыннан җыелган 70 процент калдыкны эшкәртеп, яңадан файдаланалар.

Эссе булгач, халык суны күп эчә. Шуны истә тотып булса кирәк, су шешәләрендә дә язылган: буш шешә тапшырсаң, 10 цент акча бирелә. Бик күпләр судан бушаган ул шешәләрне җыеп тапшырып, акча да эшли.

Мине хәзер күпләр «Австралиядә яшәүче татар блогеры» дип атый. 20 меңнән артык язылучым бар. Көн саен диярлек Австралиянең тормышын күрсәтәм. «И кызым, җәннәтнең бер почмагы икән бит, рәхмәт. Шундый җирләр барын каян белер идек», – таныш булмаган апалар, әбиләр көн саен шулай дип язалар. Бу миңа зур көч бирә. Ни өчен дигәндә, көн саен татарча аралашырга форсат бар. Һәм тагын – милләттәшләрем өчен бер файдалы эш эшләгән итеп тоям. Бу минем өчен бик мөһим – ике дистә елга якын журналист булып эшләгән кеше бит.

Сагынуга килгәндә, әлбәттә, туган як истән чыкмый. Әнине, әбине, кыз туганнарымны бик күрәсем килә. Дөрес, без көн саен интернет аша аралашабыз. Җәй башында балалар белән кайтырга тиеш идек, юллар ябык булу сәбәпле, билетлар янды. Кышка кайтырга ният бар, Аллаһы Тәгалә насыйп итсен...

«ТҮБӘН КАМА НЕФТЕХИМ» ГАҖ: БАРЫСЫН ДА КАДРЛАР ХӘЛ ИТӘ

Татарстан үз сәнәгатенең югары үсеше белән танылган. Әлеге үсеш нефть химиясе комплексын камилләштерү эшенә фидакарьләрчә бирелгән хезмәт коллективлары тырышлыгы белән чынга аша. Әлеге язмабызда без республикадагы иң зур предприятиеләрнең берсе – «Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыятендә социаль һәм кадрлар программаларының төп принципларын тикшерәбез.

Хәзерге вакытта предприятиедә 15 меңгә якын хезмәткәр эшли, аның бүлендек җәмгыятьләрдә – тагын 5 мең тирәсе. Гаиләләрне һәм ветераннарны да күз уңында тотканда, бу – социаль яктан лаеклы тәэмин ителгән һәм анык перспективаларга ия булган 30 меңнән артык түбәнкамалы дигән сүз. Компаниянең төп корпоратив кыйммәтләре – профессиональлек, ышанычлылык һәм даими тотрыклы үсеш. Татарстан нефть химиясе тармагының мөһим предприятиесе, үз алдында торган бурычларны хәл итү өчен, кадрлар сәясәтен колачлы һәм комплекслы рәвештә алып бара, чөнки компаниянең квалификацияле кадрларга ихтыяҗы көн кебек ачык: 2020-2023 елларда яңа җитештерү объектларын файдалануга тапшыру өчен, этаплап 1474 эш урыны булдыру планлаштырыла. Татарстанның нефть һәм газ химиясе гигантына слесарьлар, электромонтерлар, аппаратчылар, машинистлар һ. б. кирәк. Кадрларны үзең үстерә аласыңмы һәм аларны каян алырга? Бу сорауга җавап булачак белгечләрне һөнәри әзерләү эшен этаплап интеграцияләү системасы ярдәмендә табыла. Предприятиене яшь белгечләр һәм эшчеләр белән тәэмин итүнең төп чыганагы – шәһәрнең һөнәри уку йортлары – «КМТТУ» Югары һөнәри белем бирүнең Федераль дәүләт бюджет белем бирү учреждениесенең Түбән Кама химия-технология институты (филиалы) һәм Н.В. Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте.

Хәзерге заманда нәтиҗәле җитештерүне тәэмин итүче төп фактор – хезмәткәрләрне уку-укыту эше белән оешмада персонал әзерләү буенча корпоратив укыту үзәге шөгыльләнә. Ул йөздән артык юнәлеш һәм эшче һөнәрләр буенча белем бирүгә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының чикләнмәгән вакытлы лицензиясенә ия. Җитәкчеләрне һәм белгечләрне укытуның төп юнәлешләре арасында – хезмәтне саклау, сәнәгать һәм энергетика куркынычсызлыгы, менеджмент системалары, энергетика, автоматлаштыру, метрология, механика һәм технология, транспорт куркынычсызлыгы, икътисад һәм башкалар. Компания «Демография» милли проектының – «Өлкән буын», «Мәгариф» милли проектының «Һәркем өчен яңа мөмкинлекләр» һ. б. федераль проектларында катнаша.

> “
> – Ел саен «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ бүлекчәләрендә 1500 гә якын кеше җитештерү һәм диплом алды практикасы уза. Студентлар һәм стажерларга белем бирүнең уйлап эшләнгән анык системасы ярдәмендә яшьләрнең теоретик белемнәре җитештерү практикасы белән бәйләнә, студентларның белем бирү һәм җитештерү эшчәнлеген интеграцияләү бара, уку йортын тәмамлап килүчеләрнең билгеле бер җитештерү шартларына яраклашу вакыты кыскара һәм аларның эшкә урнашу мәсьәләсе уңышлы хәл ителә, – дип хәбәр итте генераль директорның персонал һәм социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Родион Александрович Булашов.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә эшләүчеләрнең 43% ын 35 яшькә кадәрге кешеләр тәшкил иткәнен, хезмәткәрләрнең уртача яше 38 яшь икәнен дә билгеләп үтик. Оешманың яшьләр сәясәте төрле ысулчараларның киң спектрын үз эченә ала. Боларга төрле ташламалардан файдалану да, һөнәри конкурсларда катнашу һәм карьера баскычында үсү мөмкинлеге дә, көч-дәрт ташып торган егет-кызларны иҗатка җәлеп итү дә, уртак кичә-бәйрәмнәр уздыру да керә. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ 2005 елдан бирле, элек түләнгән квота кысаларында, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды белән берлектә, социаль ипотека программасына да булышлык күрсәтә.

Иң мөһим юнәлешләрнең берсе – хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклау: «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ үз эшчеләрен шифаханә-курортларда дәвалау һәм савыктыру мәсьәләсенә зур игътибар бирә. Шул максаттан ел саен компаниянең 4250 хезмәткәре, аларның гаилә әгъзалары, ветераннар «Корабельная роща» профилакториенә юллама ала. 2019 елда сәнәгать зонасы территориясендә урнашкан, Түбән Кама Нефтехим ветераннарына да хезмәт күрсәтә торган 1 нче поликлиниканы капиталь ремонтлау һәм яңарту эше тәмамланды.

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү мәсьәләсен аерым игътибарда тота. Химик җитештерү эше белән турыдан-туры таныштыру һәм эшче һөнәрләрне популярлаштыру максатыннан, мәктәп укучылары өчен ел саен «Һөнәрләр дөньясы» һәм «Турникетсыз атна» экскурсия программалары оештырыла, бу вакытта алар сәнәгать зоналарында һәм җитештерү объектларында кунак була. 2018 елдан компания халыкара химия турниры партнеры булып тора. Татарстанда туып-үскән студентлар белән «Ватандашлар форумы» кысаларында очрашулар предприятие өчен традициягә әйләнде. Мондый кү-

Фотолар «Түбән Кама Нефтехим» ГАЖ матбугат хезмәтеннән алынды



“

– Предприятие хезмәткәрләренең хокукларын илнең нефть һәм газ химиясе комплексының иң эре профсоюз оешмасы яклый. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ профсоюзында 30 меңнән артык кеше исәпләнә. Коллектив шартнамә нигезендә нефть химиясе тармагының яшь белгечләре өчен төрле ташламалар каралган. Армия сафларында хезмәт итеп кайткан хезмәткәрләргә матди ярдәм күрсәтелә, ә яшь гаиләләргә беренче чиратта кирәкле көнкүреш товарларын сатып алу өчен ссудалар бирелә, беренче тапкыр гаилә корганда, бала туганда, хезмәткәрләргә өстәмә акча түләнә, – дип сөйләде Родион Александрович. – Уку йортларын тәмамлап килүчеләр эш процессына тагын да җиңелрәк җайлашсын өчен, предприятиедә остазлык тәҗрибәсе актив кулланыла. Остазлар база уку йортлары студентлары белән дә эш алып бара. Оешмада дәвамчанлыкны тәэмин итү, персоналның кызыксынуын арттыру, хезмәткәрләрнең эш нәтиҗәлелеген үстерү өчен, «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖндә «карьера лифты» программасы гамәлгә кертелгән.

решүләр нефтехимиклар коллективын сәләтле яшьләр белән тулыландыру өчен шәп мөмкинлек санала. Абруйлы эш урыны буларак, компаниянең исемен таныту өчен, 2020 елның 28 февраленнән 1 мартына кадәр «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең «Юность» балалар савыктыру лагере базасында «Киләчәк безнең кулда» яшьләр форумы узды, анда Түбән Кама, Казан, Яр Чаллы, Чиләбе, Түбән Новгород, Уфа, Самара, Йошкар-Ола һәм Мәскәүдән 200 гә якын студент катнашты. Соңгы 5 ел дәвамында «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ WorldSkills хәрәкәтенә актив булыша. Предприятие хезмәткәрләре һөнәри осталык буенча сайлап алу ярышларының, төбәк, илкүләм, дөньякүләм бәйгеләрнең барсында диярлек катнаша.

Предприятиедә яшьләрнең социаль адаптациясе өчен ел дәвамында 150 дән артык төрле юнәлештәге чара: хәрби-техник эстафета, Эшләүче яшьләр форумы, онлайн-форматтагы интеллектуаль уеннар, Instagram челтәрендәге #молодежьнкнх сәхифәсендә онлайн бәйгеләр, челленджлар сериясе, шулай ук һөнәри осталык конкурслары үткәрелә. Ярыш нәтиҗәләре нигезендә, җиңүчеләр разрядны арттыру, компаниянең кадрлар резервына керү мөмкинлеге ала.

Нефть химиясе тармагының яшь белгечләре шулай ук волонтерлар сыйфатында да хезмәт куя. «Химиклар проспекты» КВН командасы Халыкара КВН берлегенең «Республика» төбәк лигасында чыгыш ясау һәм КВН командаларының «КиВиН-2019» 30 нчы Халыкара фестивалендә катнашу хокукына ия булды. «Наше время – Безнең заман» эшче яшьләр иҗаты республика телевизион фестиваленең барлык конкурслары нәтиҗәсе буенча «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ командасы 1 урынны яулады. «Форпост» яшьләр оешмасы, «Нефтехимик» эзтабарлык отряды даими эшләп килә. «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы», «Без бергә» һәм башка проектлар тормышка ашырыла. Массакүләм спортны һәм физкультура-сәламәтләндерү эшен үстерү өчен, компаниядә уңайлы шартлар тудырылган. «Нефтехимик» спорт комплексы, ике боз спорт сарае (6000 һәм 2000 урынлык), «Дуслык» спорт-сәламәтләндерү комплексы, «Факел» спорт залы, «Алмаш» укыту-тренировка базасы, «Олимпиец» спорт-сәламәтләндерү лагереннан гыйбарәт колачлы спорт базасы бар. «Нефтехимик» стадионы кергән спорт комплексын реконструкцияләү эшләре дә тәмамланган.

НИЖНЕКАМСКНЕФТЕХИМ

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
WWW.PROTATARSTAN.RU
Реклама 16+

Мәңгелек кыйммәтләр /

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Кем ул Габдерәшит Ибраһимов

«Татарстан» журналы мөхәрриләренә **нинди** язмыш туры килгән

Альбина Шаһиморатованың күлмәге **ничек** ТР Милли музеена эләккән

Олы Мәтәскәдә безне **нинди** матурлык каршы алды

МИЛЛӘТНЕҢ БЕРЕНЧЕ СӘЯСӘТЧЕ-ПУБЛИЦИСТЫ

Автор: Илдус Заһидуллин

XIX гасырның икенче яртысы кешелек җәмгыятенә йогынты ясаган яңа теорияләр барлыкка килү белән тарихка кереп кала. Интеллектуаллар, цивилизацияләрнең, сыйныфларның киләчәген күзаллап, төрле концепцияләр яза. Әйтик, Карл Маркс хезмәтләре коммунизм җәмгыяте идеологиясен формалаштыру өчен нигез була. Ислам фәлсәфәчесе Җамалетдин әл-Әфгани, Европаның алга киткән капиталистик илләре колониаль изүе астында яшәгән дин кардәшләренә ирек алып, бер мөселман дәүләтенә берләштерү турында шулай ук тормышка ашмас панисламизм концепциясен төзи.

Фотолар автордан алынды

Татарлар арасында сәяси хәрәкәтләр русларныкыннан соңрак – Беренче инкыйлаб елларында, мондый эшчәнлек өчен тиешле шартлар тугач башлана. Сәяси кузаллау һәм төркемнәр оешу, нигездә, рус либераллары, эсерлар һәм социал-демократлары йогынтысында, аларга ияреп формалаша.

Чынлыкта татарлар арасында сәяси эшчәнлекнең беренче чаткылары XIX гасыр ахырында ук күренә. Һәм бу Габдерәшит Ибраһим исеме белән бәйле була.

Габдулла Тукай бу шәхесне «фазыйл», ягъни галим, өстен кеше дип бәяләгән. Габдулла Буби «хөрмәтле галим кеше» дип атаган, Муса Бигиев исә аны үзенең рухи остазы санаган. Замандашы Җамал Вәлиди тагын да төгәлрәк характеристика биргән: «Габдерәшит – фән кешесе түгел, ә хәрәкәттә – бәрәкәт дип, сенсация артыннан куып, җәмгыятьтә дулкынлану тудырырга тырышучы, кылган эш-гамәлләрендә һәрвакытта да дәвамчан булмаган пропагандист».

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ ЮЛЫНДА

Габдерәшит Ибраһим 1857 елның 23 апрелендә Тубыл (Тобольск) губернасының Тара шәһәрендә Урта Азиядән Себергә күченеп килгән һәм Россиядә «бохаралылар» дип йөртелгән этник төркем вәкиле гаиләсендә дөньяга килә.

Аның тормышы кызыклы вакыйгаларга бай була. Гаиләсе, балалык һәм үсмер еллары, яшьли ятим калып, күп михнәтләр күрүе, Мәдинәдә биш ел (1880–1884 еллар) укуы хакында ул үзенең «Тәрҗемәи хәлем» исемле китабында бәян итә.

Тара шәһәренең хәрәкәтчән характерга ия имамхатыйбы һәм мөдәррисе илдәге иҗтимагый тормыш белән гел кызыксынып тора. Исмәгыйль Гаспринский, Ризаэтдин Фәхретдин белән хатлар алыша, 1891 елда Уфа һәм Казанны урап кайта һәм, беренче мөмкинлек туу белән, Тараны калдыра. Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов ахун дәрәҗәсе алган шәхесне 1892 елның апрелендә Мәхкамәи шәргыягә казый итеп эшкә ала.

Мөхәммәдьяр Солтанов 1893 елда хаҗ сәфәре вакытында җиде ай дәвамында вакытлыча мөфти вазыйфаларын башкарганнан соң, 46 яшьлек Габдерәшит Ибраһим Уфадан китә. Мәхкамәи шәргыядә аралашу, мөселманнардан һәм руханилардан килгән мәгълүмат һәм шикаятьләрдә язылган проблемаларны хәл итә алмаудан туган чарасызлык, үзенең, өстәл янында каләм тотып утырудан битәр, хәрәкәт кешесе икәнен аңлау аны иҗтимагый эшчәнлеккә этәрә. «Казый» исеме, Мәхкамәи шәргыядән китсә дә, Габдерәшиткә «ябышып» кала.

Төркиягә китеп, Истанбулда яшәгәндә ул өч ярым ел дәвамында ислам фәлсәфәчесе Җамалетдин әл-Әфгани белән даими аралаша, аның панисламистик карашларын кабул итә.

XIX гасыр ахырында Җир шары империалистик илләр арасында бүленеп бетү сәбәпле, кайбер соңарып көчәйгән дәүләтләр Европа илләре хакимияте астында калган мөселманнарны үз максатларында файдалануны тышкы сәясәт доктриналарына кертә. Әйтик, Япония императоры Мэйдзи, госманлы солтаны Габделгазизгә хат язып, иленә миссионерлар җибәрүне үтенә, шул рәвешле мөселман дөньясы белән хезмәттәшлекне яңа яссылыкта башларга тели. Әфгани Ибраһимны халыкара эшчәнлек башлау һәм танышу өчен, Япониягә һәм Ерак Көнчыгышка сәяхәт ясарга өнди. Бу Япония белән берләшеп, Көнбатыш колонизаторларына каршы көрәш башлау максатында эшләнгәндер дигән фикер тудыра. XX гасыр башында замандашлары Габдерәшитнең даими рәвештә сәяхәттә йөрүләренә, Япониядә ислам динен тарату проектына сәерсенеп, көлү катыш гаҗәпләнеп карасалар да, чынлыкта бу эшләр махсус максат белән башкарыла, һәм аның иҗтимагый эшчәнлеге артында сәяси көчләр дә торган. Гомумән, 1890 нчы елларның икенче яртысыннан Габдерәшит казыйның мәгърифәтчелек, иҗтимагый эшчәнлеген шушы яссылыкта карау аның күп кенә, беренче карашка, сәер, каршылыклы гамәлләрен аңларга ярдәм итә.

1895 елда Габдерәшит Ибраһимның «Чулпан йолдызы» исемле публицистик әсәре дөнья күрә. Галимҗан Ибраһимов, татарлар тарафыннан язылган беренче сәяси хезмәткә бәя биреп, «бу 1905 ел революциясенә чаклы татарлар арасында, полиция ишетмәсен дип, колактан колакка сөйләнеп, яшереп, бер-беренә биреп укылган бердәнбер әсәрдер», ди. Әсәр «реформа хәрәкәтен куәтли, мөфтиләрне сүгә, биш мөфти булды, араларында адәм рәтлесе булмады, ди. Мәдрәсәләрнең исляхын, Европа мәдәниятен кирәксенә. Ләкин һәммә Европа хөкүмәтләрен исламны талаган өчен сүгә, рус самодержавиесенә каты бәйләнә. Чукындыру, руслаштыру сәясәтләрен тәнкыйть кыйла».

Габдерәшит Ибраһимов туган иленә кайткач, 1896–1897 елларда мөселманнар яшәгән төбәкләргә сәяхәт кыла, төбәк лидерлары белән таныша. Аннары Истанбул аша өч елга сузылган сәяхәткә чыгып китә. Мисыр, Хиҗаз, Палестинадан соң, Европа илләрендә була. Одесса, Кавказ аркылы Каспий диңгезе буйлап Бохарага юл ала, Төркестан, Җидесу төбәген иңләп, Тарага кайта.

Санкт-Петербургка килеп, газета чыгарырга рөхсәт ала алмагач, 1900–1903 (22 сан), 1907–1909 (4 сан) елларда «Миръат, яхуд Көзге» исемле альманах бастыра, максатын дин кардәшләренә соңгы елларда булган кайбер вакыйгаларны аңлату, файдалы киңәшләр һәм үсеш өчен дөрес юнәлеш билгеләү, дип атый. Альманах беренче инкыйлаб елларында татар шәкертләренең «өстәл китабы» булып тора.

1904 елда Габдерәшит казый Истанбулга китә, биредә Россиядән килгән дин кардәшләреннән түгәрәк оештырып, аларның туган илләрендә гражданлык хокукларын руслар белән тигезләү, ислам институтларының хокукларын һәм дини идарәләрнең мөстәкыйльлеген арттыру турында прокламация әзерли, текстын халыкара мөселман җәмәгатьчелегенә, шулай ук Истанбулда урнашкан Англия һәм Германия илчелекләренә җибәрә.

ПРОПАГАНДИСТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Габдерәшит Ибраһим кебек шәхесләрнең милләтне мобилизацияләү буенча искиткеч зур оештыру потенциалы җәмгыятьтә социал тетрәнүләр елларында бик калку күренә. 1906 елгы бер мәкаләсендә Ибраһим мөселманнарның киләчәккә үсеш перспективасын формалаштыруны үз максаты итеп билгели. Бу аны милләт киләчәге өчен олы җаваплылык тойган, үзенә милләтнең әйдаманы миссиясен йөкләгән, өлгергән җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче буларак күрсәтә.

Рус разведкасы Ибраһимны, Төркиядә Россиягә каршы эшчәнлек алып баруда гаепләп, кулга алдыра

«Өлфәт» газетасы редакторы Габдерәшит Ибраһим (сулдан бишенче) Төркестаннан килгән җәмәгать эшлеклеләре, шул исәптән 2 нче Дәүләт думасы депутатлары А.Р. Кариев (сулдан икенче), С.А. Мөхәммәдиев (сулдан дүртенче) белән. Санкт-Петербург, 1907 елның язы.

Токио мәчете. Габдерәшит Ибраһимов уртада.

һәм Одессага кайтарта. Ул 1904 елның 21 августында Одесса төрмәсеннән чыга, Санкт-Петербургка һәм Мәскәүгә юл ала. Ибраһим рус либераллары белән ныклап аралаша, аларның барлык халыклар тигез хокуклы булырга тиеш, илдә реформалар кирәк дигән фикерләрен ишетә. Империя хакимиятенең «җәмәгатьчелеккә ышаныч» сәясәтен игълан иткән эчке эшләр министры, либерал фикерле Петр Святополк-Мирский аңа мөселманнарның таләпләре белән үзәк хакимияткә мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә.

Шушы киңәшне тотып, Ибраһим төбәкләргә сәяхәт кыла. 1905 елның 23 гыйнварында Казанда Ибраһим рәислегендә Әхмәт бай Хөсәенов йортында узган мәҗлес шул юнәлештәге бер адым була. Анда хөкүмәт исеменә мөселманнарның ихтыяҗлары турында петиция бирү хакында карар кабул ителә. Мөселманнарның илкүләм петиция бирү хәрәкәте башланып китә. Икенче көнне Габдерәшит Ибраһим, Йосыф Акчура һ.б. кайбер фикердәшләр, җыелып, 1905 елның март аенда Санкт-Петербургта Россия мөселманнары съездын ясау өчен, Кырым, Кавказ, Казахстан, Төркестан мөселманнарын чакыру карарына киләләр. Ләкин башкалага петицияләр тапшыру өчен депутацияләр төрле вакытта килү сәбәпле, оештыру съездын уздырырга мөмкинлек табылмый. Апрель аенда Ибраһимның кечкенә фатирында азәрбайҗанлылар белән Идел буе татар җәмәгать эшлелекләренең киңәш мәҗлесе үткәрелә. Анда мөселман халыкларының фиркасен дини якынлык нигезендә корырга һәм оештыру съездын август аенда Мәкәрҗә ярминкәсендә уздырырга дигән карар кабул ителә. Ибраһим 1 нче, 2 нче, 3 нче Бөтенроссия мөселман съездларын оештыруда һәм аларның эшендә актив катнаша. Ул 1905–1907 елларда атналык «Өлфәт» (Дуслык) исемле газета бастыра, аның эчтәлегенә мәгърифәтчелек идеологиясе салына, мөселман руханилары темасы күтәрелә, нигездә, татарлар турында сүз алып барыла. Ибраһимның бетмәс-төкәнмәс энергиясе һәм искиткеч тәэсирле харизмасы Дагыстан студентларына атап атналык «Әл-тилмиз» («Укучы») исемле журнал нәшер итәргә дә җитә. Бу басма Санкт-Петербургта гарәп телендә 1906 елның ахырыннан 1907 елда аның 30 нчы саны полиция тарафыннан кулга алынганчы кадәр чыга. Ел ярымнан полиция «гомум ислам агитациясе өчен» «Өлфәт»нең 85 нче санын кулга ала, басманы бөтенләй яба. Аннан соң Ибраһим «Нәҗат» («Коткару») исемле альманах бастыра, ике саны чыккач, тиражын кулга алып, полиция аны да ябып куя. Июнь аенда ул казах телендә «Сиркә» («Лидер») исемле атналык журнал чыгара. Бер саны басылгач, журнал «гомум төрки агитация алып барган өчен» шулай ук ябыла. Шуның белән Габдерәшит Ибраһимның илдәге вакытлы матбугатта нәширлек эшчәнлеге тәмам була.

ТАТАР АВТОНОМИЯСЕ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ

«Өлфәт» газетасының редакторы буларак, ул 1905 елның 19 ноябрендә ачылган «Автономистлар һәм федералистлар берлеге»нең съездында катнаша.

Мөселман интеллектуаллары арасында беренче булып, 1905 елда татар автономиясе турында теоретик фикерләре белән уртаклаша, «Автономия, яки Идарә мохтарияте» исемле китап яза. Россиядә гражданлык хокуклары кертүдән тыш, автономиягә ирешү юлында бик мөһим шарт дип, төбәктәге башка кавемнәр белән килешүләр төзүне атый. Моның өчен «Иттифак әл-Мөслимин» партиясенә теркәү уздыра, партиянең губерна һәм өяз бүлекчәләре ачыла.

Ибраһим татарларга туры килә торган милли автономияне түбәндәгечә тасвирлый. Беренчедән, рус халкы белән тигез хокуклы булу, икенчедән, мөселман өлкәләрендә идарә итүне аерым башкару, өченчедән, ислам кануннары (шәригать) нигезендә һәр хәрби корпуста имам булдыру, дүртенчедән, сугыш вакытында солдатларның үз йортлары янәшәсендә яисә үз губерналарында хезмәт итүе, бишенчедән, теге яки бу сәбәп белән әлегәчә армиягә алынмаган мөселманны киләчәктә дә алмау, ә армиягә алынган мөселманга, әгәр дә хезмәт итәргә теләмәсә, акча түләп котылу мөмкинлеген бирү. Диния нәзарәте бөтенләй бәйсез булып, без үзебезнең мөфтиләрне һәм казыйларны үзебез сайларга, мөселманнар мәнфәгатьләрендә дини идарә системасын реформалау хокукыннан файдалану мөмкинлегенә ия булырга тиеш. Мәктәп һәм мәдрәсә бисналары безнеке һәм бу биналардан файдалануга рөхсәт бирү безнең мөселман закон чыгару органныкы булырга тиеш, һәм берничек тә дәүләт чиновниклары җирле идарәгә һәм эшләрне хәл итүгә тыкшынырга

тиеш түгел, әгәр идарә өчен кирәкле акчаны халыктан җыярга туры килсә дә, үзәк хөкүмәт тарафыннан киртәләр булдырылырга тиеш түгел.

Яулаган уңышларны ныгыткач, игътибарны сәяси автономия мәсьәләсенә юнәлтү кирәклеген ассызыклый. Моңа ирешү юллары дип, 10–20 ел дәвамында демократик җәмгыятьтә милли мәгариф һәм тәрбиягә аерым игътибар бирү, милли үзаңны башка халыкларныкы дәрәҗәсенә күтәрү, туган телгә, әхлакка һәм гореф-гадәтләргә тугрылыкны тәэмин итү һәм рус мәктәбеннән мөмкин кадәр саклану, дәүләт телен өйрәтү өчен үзебезгә махсус мәктәпләр ачуны күрсәтә.

Аның тагын бер яңа фикере татар зыялыларын, хокук белгечләрен Россияне киләчәктә федерация итеп кору мөмкинлеге мәсьәләсен ныклап өйрәнергә чакырудан гыйбарәт.

Токиода татар җәмгыяте төзегән мәчет ачуга багышланган чарада. Габдерәшит Ибраһимов уңнан икенче. 1938 елның май ае.

ДӨНЬЯ БУЙЛАП СӘЯХӘТЛӘРЕ ҺӘМ ЧИТ ИЛДӘГЕ ТОРМЫШЫ

Габдерәшит казый, үзенә карата җинаять эше кузгатылгач, матбагасын сатып, 1907 елның 11 апрелендә башкаладан качып китә һәм Тарага кайта. Гаиләсен Казанга китереп урнаштыра.

Ул 1908 елның сентябрендә Көнчыгышка юнәлә. Сәяхәтче юлда (пароходта, Себер тимер юлында поездда) барганда, шәһәр-авылларда туктап торганда танышкан яки үзе махсус барып күрешкән, сөйләшкән төрле социаль катлам һәм кавем вәкилләренең фикерләрен теркәп бара. Уфа, Чиләбе, Кызылъяр, Томск, Ачинск, Красноярск, Омск, Югары Удин, Чита, Харбин татар мәхәлләләрендә милли проблемаларын хәл итү юлларын тасвирлый, бу эштә төбәк байларының, руханиларның, җәмәгать эшлеклеләренең исемнәрен әйтеп, аларны үрнәк итеп куеп, иҗтимагый эшчәнлекләренә югары бәя бирә. Тискәре һәм уңай заман геройлары мисалында дин кардәшләрен йокыдан уяныргa, иҗтимагый активлыкка өнди. Көндәлек язмаларын «Бәянелхак» газетасында (Казан) бастыра, 1909 елда алар «Дәүре галәм» («Дөньяны әйләнеп») исеме белән китап буларак дөнья күрә. Татар җәмәгатьчелегенә сәяхәтче күзәтүләре тәэсире шулкадәр көчле була ки, Галимҗан Ибраһимов авторны хәтта үзләренә «дәрес бирүче» дип атый.

Ул сәяхәтен Манчьжурия аша Владивостокка барып, диңгез кичеп, 1909 елда Япониядә тәгәлли һәм бу илдә 4 ай яши. Япония хөкүмәт даирәләре сәяхәтчене бик югары дәрәҗәдә кабул итәләр, Ибраһим алар белән якыная, үзенең төп максаты Япониядә ислам динен тарату дип белдерә.

Сәяхәтче 1909 елның июнендә тагын сәфәргә кузгала: Япониядән Кореяга, Манчьжуриягә, Кытайга юнәлә, аннан Сингапурны, Һиндстанны, Шәрык илләрен гизә. Сәяхәтен Истанбулда тәмамлый. Юл язмаларын соңрак ике томда «Галәми ислам» («Ислам дөньясы») исеме белән бастыра, шулай итеп, татарларда сәяхәтнамәләр җанрын Ибраһим да үз әсәрләре белән баета.

Ул Истанбулда яшәгәндә дә матбагачылык һәм журналистлык хезмәтен дәвам итә, 1910 елның 12 апреленнән «Тәгаруфи мөслимин» («Мөселманнар белән танышу») исемле журнал чыгара. 1913 елның 15 мартында аның урынына «Ислам дөнья»сын бастыра башлый (24 саны дөнья күрә). Шулай ук Йосыф Акчура һәм башка татар интеллектуаллары белән бергә «Төрк Йорду»н (1911 елда нәшер итәлә башлый), «Төрк сүзе»н (1912 елның 12 апрелендә бастырыла башлый) чыгаруда катнаша.

Габдерәшит Ибраһим 1913 елны Төркия гражданлыгы ала һәм Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, 1915 елны госманлы яшерен оешма агенты булып эшкә урнаша, бер үк вакытта Германия тышкы эшләр министрлыгына хезмәткә керә. Германиядә әсирлеккә төшкән татар сугышчылары өчен «Ислам диненең изге сугышы» исемле газета бастыра башлый. Әсирләрдән «Азия батальоны» оештырып, аны төрек гаскәре составына җибәрә.

1921 елны Россиягә, Тара каласына кайта, большевиклар белән хезмәттәшлеккә омтылып һәм милли-азатлык көрәшенә чакырып, пропаганда алып бара. Кулга алына, гаебе расланмыйча иреккә чыккач, Кытай аша Көнчыгыш Төркестанга китә, бередә яшәгән казахларны, уйгырларны һәм татарларны милли-азатлык көрәшенә өнди.

Габдерәшит гаиләсе белән 1925 елдан Төркиядә яши, Ататөрек хөкүмәте панисламизм идеологиясен эзәрлекләү сәбәпле, Конья каласы янындагы бер авылда көн күрә.

Бу вакытта Япониянең халыкара эшчәнлеге активлаша, Паназия доктринасы йогынтылыга әверелә, шуның бер чагылышы булып 1929 елны Габдерәшит янына Әнкарадан япон хәрби атташелары килеп, үз илләренә күченергә чакыру тора. 1933 елны чакыру хөкүмәтара дәрәҗәдә ясала. Шул елны, Төркия Республикасы президенты Ататөрек чакырып сөйләшүеннән соң, Габдерәшит Ибраһим Япониягә күченә һәм кабат халыкара сәясәт өлкәсенә килеп керә. Татар җәмәгатьчелеге көче белән 1938 елда төзелгән һәм тантаналы рәвештә ачылган Токио мәчетенә имам-хатыйб итеп сайлана. Шушы вазыйфада 1944 елның 17 августында вафат була. Гаиләсе Төркиядә кала.

Галимҗан Ибраһимов 1922 елны язылган мәкаләсендә Габдерәшит казыйны тарихи дәвернең үткән баскычының бер көрәшчесе – кадимнән җәдиткә чыгуда алга өстерәүче дип бәяли. Без аны хаклы рәвештә XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар милләтенең иҗтимагый мәсьәләләрен максатчан рәвештә хәл итәргә алынган беренче сәясәтче-публицист дип атыйбыз.

PRESSA



Автор: Мөршидә Кыямова

«ТАРИХ ӨЧЕН ҖАНЫ ФИДА ИДЕ»

Космонавтлар белән футурологлар безгә хыялланырга, археологлар исә үткәнне белергә мөмкинлек бирә. Язмабыз данлыклы археолог Альфред Хәсән улы Халиков истәлегенә багышлана.

Фотолар гаилә архивыннан

Студент Альфред Халиков үзенең укытучысы Николай Калинин белән.

КАЛЫН КҮЗЛЕКЛЕ ӨМЕТЛЕ ЕГЕТ

Замандашлары Альфред Халиков хакында фикер йөрткәндә, еш кына: «Археолог булып туган инде ул», – диләр. Мәктәптә укыганда ук, аны серле тарих дөньясы кызыксындыра, әле моңарчы беркем белмәгән, үткәннәрнең калын тузанында күмелеп калган вакыйгаларны, серләрне ачарга омтыла ул. Тарих дәресләрендә укытучыны йотлыгып тыңлый торган була. Олыларның да башына килеп карамаган фактларның төбенә төшәргә омтыла. Казанның Альфред Халиков укыган 2 нче мәктәбендә сугыштан соңгы елларда туган якны өйрәнүче зур галим Николай Калинин эшләгән, бирердә ул тарих фәнен дә укыткан. Халиков мәктәптә укыганда ук атаклы археолог белән таныша, ул оештырган туган якны өйрәнү түгәрәгенә йөри. География, әдәбият фәннәрен тиз үзләштергән егет чит ил әдәбиятына да мөкиббән була. Чит ил язучыларына хөрмәтен ул гомер буена җуймый, әдәбият укудан беркайчан да туктамый. Киң эрудицияле зыялы булуы да шуннан килә, күрәсең. Республиканың Туган як музеенда эшләгән вакытта Николай Калинин мәктәп укучылары өчен «Туган як» түгәрәге оештыра һәм еш кына укучыларын Казан Кремленә, шәһәрнең тарихи урыннарына сәяхәтләр, экспедицияләргә алып чыга. Ул вакытта ук инде кызыксынучан егет археологик казу эшләрендә катнаша башлый. Сорауларына җавап эзли, тик җавапларга караганда, сораулар күбрәк туып тора...

Мәктәпне тәмамлап, университетның тарих-филология факультетына укырга кергәч, узган гасырларда булган вакыйгалар чолганышы аны тагын да күбрәк җәлеп итә. Университетта ул профессор Николай Калинин җитәкчелегендә җитди рәвештә тарих, археология белән шөгыльләнә башлый. Мөгаллим калын пыялалы күзлек киеп йөрүче актив егеттә өмет барын мәктәптә укытканда ук сизеп алган була. Күп укырга яратучы, тарих белән төптән кызыксынучы егет, чыннан да, башкалардан аерылып торган. Матди юклык заманы булса да, ул үҗәтләнеп белем ала, тормыш-көнкүреш авырлыкларына бирешми. Университетта укый башлаган елны әтисе – физика-математика фәннәре кандидаты, педагог Хәсән Халиков 43 яшендә үлеп китә. Альфред университетта тырышып укый, актив студентлар рәтендә санала. Беренче Сталин стипендиясенә ул костюм сатып ала һәм шуны укуын тәмамлаганчы киеп йөри. Хезмәт сөючәнлеге, тапкырлыгы, тырышлыгы аны гомере буена озата бара.

Замандашлары искә алганча, Альфред Халиков теләсә кайда: вокзалда, самолетта, юлда, кешеләр арасында да эшли алган, уңайлы шартлар эзләп йөрмичә генә, кульязмаларын төзәткән, материалларын язган. Аның беренче иң зур фәнни хезмәте Казан университетының тарих-филология факультетында укыганда языла. СССР Мәгариф министрлыгының беренче премиясенә лаек дип табыла. Альфред Халиков 27 яшендә кандидатлык диссертациясен яклый. Ә 37 яшендә Татарстанда беренче булып археология докторы дәрәҗәсенә ирешә.

1969 елда «Наука» нәшриятында (Мәскәү) галимнең «Урта Идел буеның борынгы тарихы» («Древняя история Среднего Поволжья») дигән монографиясе басылып чыга. Әлеге хезмәт аның докторлык диссертациясе нигезендә башкарыла. Монография Россиядә генә түгел, ә чит ил тарихчылары арасында да танылу ала. Галимнәр фикеренчә, әлеге хезмәт төньяк-көнчыгыш Европаның борынгы чорын өйрәнүче галимнәрнең өстәл китабы булып саналырга лаек.

ГАДИЛЕКТӘ – БӨЕКЛЕК

Альфред Халиков археологиягә генә табынып яшәгән икән дип уйлаучылар ялгыша. Ул тормышны яратып, һәр мизгелдән тәм табып гомер иткән. Беренче хатыны Алиса Алексеевна белән студент елларында ук өйләнешәләр. Ике балалары – Наил һәм Елена туа. Беренче хатыны белән галим озак яшәми, ләкин һәрвакыт балалары янында була, аларны кайгыртып тора. Киләчәк язмышларын хәл иткәндә дә төпле киңәшләрен бирә. Наил Халиков – әтисе кебек үк танылган галим, озак еллар этнография өлкәсендә хезмәт куйган белгеч. «Әти безне яратып үстерде, аерым яшәсәк тә, һәрвакыт үз тирәсендә йөртте, безнең туган көннәребез

СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантлары Альфред Халиков белән Владимир Генинг.

Студентлар белән экскурсиядә. 1980 нче еллар.

җиткәч, чит төбәкләрдә булса да, элемтәгә кереп, котларга онытмый торган иде. Мин өч яшьлек чагымнан ук аңа ияреп, экспедицияләргә чыга идем», – дип искә ала Наил Халиков.

Галимнең икенче хатыны – Елена Александровна – шулай ук археолог. Алар еш кына экспедицияләргә дә бергә йөргәннәр. Елена Александровна – фәндә билгеле шәхес. Әмма ул 50 яшендә, вакытыннан алда, бакыйлыкка күчә. Галим тормыш иптәшен, фикердәшен югалтуны авыр кичерә, әмма өченче тормыш иптәше Маргарита Кузьминична белән берләшү галимне кабат тулы канлы тормышка кайтара. Маргарита ханым, археологиядән ераграк торса да, атаклы иренең тормыш принципларына, яшәү рәвешенә тиз иялəшә. Алар бик бәхетле гомер кичерәләр.

Башка милләт вәкилләре белән тормыш корган, нигездә, рус телендә аралашкан булса да, танылган археолог татарның озын, моңлы көйләрен яраткан, аларны үзе дә оста башкарган. Халиковның күңеленә хуш килгән «Урман кызы» (Һ.Такташ сүзләре, Җ.Фәйзи музыкасы) әсәрен аңа галим Сәяр Айдаров өйрәткән. 15 август – Археологлар көнен билгеләп узганда, Альфред Хәсәнович вокал мөмкинлекләрен бик теләп коллегаларына күрсәтә торган була. Машина кузовына төяләп кырга, казу эшләренә чыгып киткәндә дә ачык һавада куе бас тавышы белән җырлап җибәргәнен укучылары бүген дә сагынып искә ала. Күңеле сөйгән эшенә кузгалган чакта җаны җыр сорагандыр, күрәсең…

Тормышта мәшһүр археолог үзен бик гади тота, теләсә кем белән яратып аралаша. «Ул академик белән дә, авыл тракторчысы белән дә бик тиз уртак тел таба белә иде», – ди коллегалары. Беркайчан да гозер яки сорау белән килгән кешеләрне кире бормый. Гомеренең күп өлеше кырда, археологик эзләнүләрдә узгангамы, еш кына аңа аш-су остасы да буларга да туры килә. Ашарга пешерү, табын коруны аеруча зәвыклы итеп башкаруын искә алалар.

Аның хезмәттәшләре белән мөнәсәбәтендәге тыйнаклыгы күпләрне сокландыра. Кайчак, кабынып китеп бәхәскә кергәләсә дә, әңгәмәдәшләрен, оппонентларын беркайчан да рәнҗетми ул. Студентларын да шәхес буларак хөрмәт итә, үзен алар белән тиң куеп, һаваланмый гына сөйләшә, шуның өчен аны яшьләр ярата да. Фәнни кадрлар әзерләүне нык кайгырта, бу мәсьәләгә җитди карый. Асылда, аны Казан археологларының атасы дип әйтергә дә мөмкиндер, чөнки йөзгә якын кандидат һәм дистәдән артык фән докторы нәкъ менә аңарда укып, җиргә яшеренгән тарих дөньясына атлый.

«АРХЕОЛОГ ЗАМАНДАШЛАРЫНЫҢ ФИКЕРЛӘҮ ДӘРӘҖӘСЕН КҮТӘРӘ»

Археолог тормышы романтикадан гына тора диючеләр дә очрый, әмма башка галимнәрдән аермалы буларак, аның эзләнүләре кулга көрәк тотып җир казудан, ягъни авыр физик хезмәттән башлана. Гомеренең соңгы елларына кадәр Альфред Хәсәнович экспедицияләрдә катнаша. Остазы Николай Калинин башлаган зур эшне Халиков тәмамлый: «Татарстанның археологик картасын» (1981–1990, 1-6 томнар) төзеп тәгәлли. Бу саллы хезмәтне эшләүдә катнашуы өчен талантлы тарихчыга Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт пре-

Биләр шәһәрлеге. 1970 нче еллар.

миясе тапшырыла. Татарстан – Идел буе һәм Урал алды төбәкләре арасында археологик һәйкәлләргә иң бай республика. Үткен күзле галим башкалар күрә алмаган эзләрне таба алуы белән дә безгә бик кадерле.

«Археолог – бик кызыклы һәм катлаулы профессия,» – дия торган була галим үзе. Бу һөнәр аның яшәү рәвеше, хәтта холкының бер өлеше дә булып тора. Ул үз ачышлары аша замандашларының фикерләү, аң дәрәҗәсен югарырак күтәрергә омтыла. Халиков, шул фикеренә тугры хәлдә, тарихи байлыкларны барлау, аларны саклау, киләчәк буыннарга тапшыру мәсьәләләрен кайгырта. Аның Куйбышев ГЭС зонасында тарихи һәйкәлләрне саклап калу, Имәнкискә шәһәрлеген казып чыгарудагы тырышлыгы фәндә аерым бер чорны тәшкил итә.

Күренекле археолог шулай ук Олы Тархан каберлегендә, Биләр шәһәрлегендә, Казанда, Алабугада археологик казу эшләре алып бара. XII йөз гарәп географы әл-Идриси картасы буенча мәгълүм борынгы Болгар – Киев сәүдә юлларын тарихи-археологик яктан тикшеренүләр Украина галимнәре белән берлектә уздырыла. Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары йогынтысында җимерелүче археологик истәлекләрне саклап калу буенча да системалы эшләр оештыра.

Ул – урта гасырлардагы Биләр шәһәре һәм аның тирә-ягы, Казан Кремле территорияләрендә музейтыюлыкларны оештыруга башлангыч бирүчеләрнең берсе. Болгар истәлекләрен беренче тапкыр аэрофотога төшерү дә Халиков җитәкчелегендә гамәлгә ашырыла.

Хезмәтләре Көнчыгыш Европаның төрки телле һәм фин-угор халыкларының археологиясенә, борынгы һәм урта гасырлар тарихына, шул исәптән татарларның килеп чыгышына, Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда тарихына карый.

КАЗАН ТАРИХЫНА ЯҢА КАРАШ

Студент елларыннан ук Халиковны Казанга нигез салу тарихы да кызыксындыра. Ул калада тикшеренү эшләренә яшьтән үк ымсына, тик шәһәрдә казырга рөхсәт алу гына авыррак була. Шунысын да өстик: Казанның тарихын барлаганда галимгә зур сынаулар аша да узарга туры килә.

Казан тарихы күп галимнәрне, шул исәптән революциягә кадәргеләрне дә ымсындырган. Билгеле булганча, башкалабызның барлыкка килүен борынгы рус елъязмаларында Казанның беренче телгә алынуы белән генә бәйлиләр. Беренче булып Казан тарихын өйрәнүне нәкъ менә Альфред Халиковның остазы Николай Калинин башлап җибәрә, тик ул үз тикшеренүләрен тәмамларга өлгерми. Халиков укытучысының эшен дәвам итеп,

Экспедициядә вакытта.

узган гасырның 70 нче елларында, хезмәттәшләре һәм укучылары белән бергә, Казанның билгеләнгән яшеннән өлкәнрәк булуына дәлил таба. Җәмәгате Елена Халикова белән берлектә, Казан яңы культурасын аерып чыгара. Кремльдәге казылмалар һәм Казан елъязмасындагы мәгълүматлар галимне 1976 елда Казанга 800 ел дигән фикергә килергә этәрә. Әлбәттә, башта бу яңалыкны сөенеп кабул итәләр. 1977 елда Казан зур юбилеен да каршы алырга әзерләнә. Әмма ул чактагы фән әле бу яңалыкны кабул итәргә әзер булмый: галимгә хаталанасың, дип ишарә ясыйлар. Аның профессиональлеген шик астына куючылар да табыла. Шул вакытта икенче хатыны вакытсыз дөнья куя да. Галим депрессиягә бирелә, хәтта Казаннан күчеп китәргә микән әллә дип тә уйлана башлый. Әмма аны данлыклы Биләр көткән булган икән! Биләргә ул гомеренең 25 елын багышлый. Яңа тикшерену ысулы Биләрне галимнәргә башка яктан, монголларга кадәр яшәгән болгарларның беренче һәм бердәнбер башкаласы буларак ачарга мөмкинлек бирә.

«Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе» хезмәте киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. «Бу мәсьәлә белән байтак тикшеренүчеләр шөгыльләнгән. Шулар арасында Степан Веселовский үзенең «Ономастикон. Борынгы рус исемнәре, кушаматлары һәм фамилияләре» (М. 1974); Н.А.Баскаков күрсәтеп үтелгән «Төрки чыгышлы рус фамилияләре» (М. 1979) исемле китапларында бу мәсьәләләрне җентекләп өйрәнәләр. Ләкин алар моңа төрле фәннәр күзлегеннән карый: беренчесе тарихчы буларак, икенчесе – филолог. Җитмәсә, бер-берсенең хезмәтләрен дә белмиләр. Алар башка авторларның хезмәтләрен дә, шул исәптән XV–XVII йөзләрдәге Писцовый кенәгәләрне, бигрәк тә Казан, Казан өязе буенча язылганнарны файдаланмыйлар. «Без төрки чыгышлы рус фамилияләре тупланмасының тулырагын тәкъдим итәбез һәм Болгар, Казан, татар-мишәр фамилияләренә игътибарны мөмкин кадәр күбрәк юнәлтәбез», – ди Халиков үзе.

«Альфред Хәсәнович монда күбрәк популярлаштыручы буларак күренде дияргә мөмкин. Ул язган китаплар киң җәмәгатьчелеккә адреслана, һәм алар үтемле тел белән язылган» – дип белдерә аның эшен дәвам итүчеләр.

Бу хезмәткә карата да фикерләр бертөрле генә түгел. Фамилияләрнең кайберләре тупланмага дөрес кертелмәгән, диючеләр бар. Берәүләр фамилияләрнең мәшһүрлегенә, танылганлыгына исе китеп, горурлык кичерсә, кемнәрдер: «Милләтеннән йөз чөергән шәхесләр нәфрәт хисе генә уята ала, шуңа күрә мондый китап чыгарга тиеш түгел иде!» – дип тә әйтәләр. Ни генә булмасын, без бу фамилияләрне белергә тиешбез. Алар рус тарихының да, татар тарихының да бер өлешен тәшкил итә. Күпмедер дәрәҗәдә алар татар кавеменең генетик егәр кимәлен дә чагылдырадыр әле.

Язылганнарга нәтиҗә ясап шуны әйтик: чын дөреслекне Кремль тавында эзли башлыйлар. Галимнең шәкертләре остазларының эшен дәвам итә. Ниһаять, күптән көтелгән сер пәрдәсе дә ачыла. Казаныбыз тагын да борынгырак тарихка ия булып чыга: аңа 800 ел гына түгел, ә 1000 ел икән!



ШУЛАЙ БЕР ВАКЫТ...

БЕЛЕШМӘ:

Альфред Халиков 1929 елның 30 маенда ТАССРның Нурлат районы Кизләү авылында укытучылар гаиләсендә туа. Әтисе Хәсән Халиков, чыгышы белән Тәтеш районы, Олы Туарма авылыннан. Әнисе Газизә Әхмәтова – Казан кызы. Кизләү авылына комсомол оешмасы тарафыннан халыкны агарту программасы буенча җибәрелгән булалар. Гаилә, икенче балалары – Альфред тугач, Казанга күченә. Альфред Халиков 1947 елда урта мәктәпне тәмамлый. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. 1952 елда аны кызыл диплом белән тәмамлый.

1951 елда ук ул СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә урнаша. Анда ул гади фәнни хезмәткәрдән башлап, фән докторына һәм профессорга кадәр юл үтә. 1951–1994 елларда әлеге институтында: директор урынбасары (1962 елдан), археология бүлеге мөдире (1965–1988), баш гыйльми хезмәткәр (1990–1994). Бер үк вакытта Казан университеты профессоры. 500 дән күбрәк фәнни хезмәт, 30 дан артык китап авторы. Археология фәннәре докторы. Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы. ТАССРның атказанган фән эшлеклесе. ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт премиясе лауреаты (вафатыннан соң).

Казанның бер урамы Альфред Халиков исемен йөртә. 2014 елда ачылган Археология институты шулай ук Альфред Халиков хөрмәтенә аталды. Нурлат районы Кизләү мәктәбендә Альфред Халиковка багышланган музей почмагы бар.

Фаяз Хуҗин, шәкерте, тарих фәннәре докторы:

1969 елның 1 июлен мин бик ачык хәтерлим әле. Без, бер төркем пединститут студентлары, борынгы Болгар хәрабәләрен казырга дип, Биләргә археологик практика үтәргә килдек. Экспедиция җитәкчесе Альфред Хәсәнович – әле ул чакта 40 яшен яңа гына тутырган яшь галим. Бер айга якын барган экспедиция чорында студентларны шаккатырган нәрсәләр күп булды булуын. Барысы да яңа иде бит безнең өчен. Әкренләп күнектек тагын. Альфред Хәсәновичның профессорлыгына гына күнегә алмадык. Бер карасаң, коеп куйган галим инде үзе: ак чалбар белән күлмәктән, башында эшләпә, муенына фотоаппарат аскан. Калын пыялалы күзлек кигән. Әмма профессор өчен яшьрәк кебек. Кешеләр белән чамадан тыш гади, егетләребез белән дә кул биреп исәнләшә, барыбызның да исемнәрен белә. Машинада барганда җыр башлап җибәрүче дә, кирәк вакытта мәзәк сөйләп, күңелләребезне күтәрүче дә ул. Искиткеч ярдәмчел, һәрвакыт көләч йөзле, тәкәбберлек, мин-минлек дигән нәрсәнең эзе дә юк. Кыскасы, без күреп гадәтләнгән профессор халкына бөтенләй охшамаган. Кулына көрәк тотып, әле бер, әле икенче студент янына ашыга: аңлашылып җитмәгән урыннарын үзе казып карый, яхшылап кабат-кабат чистарта, тузанга батып бетә, һаман безнең арада кайнаша иде. Иң беренче чиратта шушы сыйфатлары Казан дәүләт университеты профессоры Альфред Халиковны студент яшьләренең кумиры иткәндер. Биләрнең символына әверелеп киткән профессорыбыз безне барыбызны да магнит кебек үзенә тартып тора иде.

Археолог галимнең бихисап укучысы бар. Бүген алар данлыклы остазларының эшен уңышлы дәвам итә. 40 тан артык китап һәм фәнни җыентыкларның җаваплы мөхәррире булып исәпләнә. Төрле халыкара конференцияләрдә чыгыш ясаганнарын санап та тормыйм…

Елена Халикова, кызы:

– Әти һәрвакыт эш белән мәшгуль иде. Җәй айларында – археологик экспедицияләрдә, кышын Фәннәр академиясе филиалында, төрле ил һәм шәһәрләргә командировкаларга да еш йөрде. Әти Казанда булган чакта без аның белән еш очраша идек. Эше тыгыз булса да, Наил белән миңа вакыт таба торган иде. Әти белән без йөзәргә, чаңгыда йөрергә, гөмбә җыярга өйрәндек. Аның белән һәрвакыт күңелле була торган иде. Әти бөтен нәрсәне белә, һәр сорауга җавап таба торган кеше буларак күңелемә кереп калган. Казан тарихы, Идел Болгарстаны турында сөйли башласа, авызны ачып тыңлап тора идек. Ул безне шәһәрнең төрле кызыклы урыннарына алып бара, шунда йөргәндә әллә нинди борынгы әйберләр казып чыгара торган иде. Безнең мәктәптәге тормыш та аны кызыксындыра иде. Мин аның беркайчан да балаларына тавыш күтәргәнен хәтерләмим. Нәрсәгә булса да ачуланганда ул миңа «Лена» дип дәшә, ә инде күңеле булганда «Аленушка, кызым» дия торган иде.

Наил Халиков, улы:

– Әти үзендәге белемен башкалар, бигрәк тә яшьләр белән бүлешергә кирәк, дип санады, һәрвакыт фикер алышуны яратты. Бәхәсле мәкаләләр язудан курыкмады. Казан, Мәскәү матбугаты өчен дә төн утырып җитди, саллы дәлилләргә бай, нигезле материаллар әзерли торган иде. Борынгы һәйкәлләрне саклап, бернинчә тапкыр бәхәскә кергәнен яхшы хәтерлим. Әйтик, Горький урамында Боратынскийлар утарын җимерүгә каршы төшкән иде. Идел буе-Урал татарлары барлыкка килүнең Болгар нигезе теориясен яклап чыкты. Тарих өчен җанын фида кылырга әзер иде инде! Дәреслекне яклап, һәр нәрсәнең фәнни асылына төшәргә омтылып, үз-үзен аямыйча эшләде. Бәлкем шуңа да ул бик иртә киткәндер…

100

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ

Беренче йөзьеллык дәвамында, 1920 елдан 2020 елга кадәр, ‹‹Татарстан›› иҗтимагый-сәяси журналы белән 20 баш редактор җитәкчелек иткән. Һәрбер баш редактор алдына (әлеге вазыйфа башта җаваплы редактор дип аталган) республика җитәкчелеге тарафыннан махсус максатлар һәм бурычлар куелган. Һәр редакторның әлеге бурычларны тормышка ашыруга үз карашы булган. Һәм үзенең журналистлар һәм штаттан тыш хәбәрчеләр командасы. Алар, куелган максатларга һәм бурычларга ярашлы рәвештә, журналны кызыклы да, укылышлы да итеп чыгарганнар. Кайчагында, бигрәк тә сугышка кадәрге чорда, алай килеп чыкмаган һәм баш редакторларны репрессияләгәннәр, хәтта җәзага да тартканнар.

1977 елда журнал Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә. Юкка түгел. Журнал еллар буена халыклар дуслыгын үз сәхифәләрендә яктыртып кына калмый, үзе дә – коллективы мисалында – ныклы дуслык үрнәге булып тора. Журналда һәрвакыт Татарстанда яшәүче барлык милләт вәкилләре дә эшләгән һәм эшли.

ИҢ *әдәби*

Гомеренең беренче биш елында киләчәктә ‹‹Татарстан›› буларак танылачак журнал биш коммунистик исем алыштырган: ‹‹Вестник Татобласткома РКП (б) ››, ‹‹Спутник агитатора››, ‹‹Коммунистический путь››, ‹‹Путь Ильича››, һәм 1925 елда ‹‹укучылар соравы буенча›› әдәби-иҗтимагый ‹‹Причал››га әверелгән. ‹‹Журналыбызны укучыларның теләкләрен искә алып, без аны ‹‹Причал›› дип исемләп, 5 нче санын чыгарабыз һәм алга таба да булачак саннарны шушы теләкләргә ярашлы итеп чыгарачакбыз. ‹‹Путь Ильича››га язылган кешеләрнең барысы да, шул рәвешчә, ‹‹Причал››ны алачак››, – дип яза ‹‹Причал››ның җаваплы (ягъни баш) редакторы Григорий Цыпин ‹‹Редакциядән›› дигән сәламләү сүзендә.

КОНТРРЕВОЛЮЦИЯ ЙОКЛАМЫЙ

Григорий Цыпинны «Вечерняя Москва» журналистлары яхшы белә һәм бүгенге көнгәчә ярата. Нәкъ менә ул килгәннән соң «Вечерняя Москва» иң беренче битенә көн кадагына туры килгән тексты булган зур фоторәсемле, кызыклы иллюстрацияле газетага әверелә – хезмәткәрләр ул битне «фотофельетон» дип исемли. Хәбәрләргә бер карауга җәлеп итә торган баш исемнәр уйлап табыла – хәтта партиягә кандидатлар турында язганда да: «Зур стажлы кандидатлар. Кандидатлыкта йөрибез һәм берни эшләмибез». Ягъни: «Безне бармак белән ашарга мәҗбүр итмәгез. Агач кашыклар бирегез» (ашханәләрдә приборлар җитмәү турында), «Тычканнар букварь укый. Балаларга мондый мөмкинлек юк» (дәреслекләрнең складларда озак ятуы турында).

«Вечерка» стиленең бердәйлеге кырыс ысуллар ярдәмендә булдырылган. Цыпин «хезмәткәрләргә үз язмаларына баш исем куюны тыйган, моның өчен штраф салыначак, дип игълан иткән. Баш исемнәрне редакторларның махсус «өчлеге» уйлап чыгара торган булган.

«Цыпиннан» дип исемләнгән яңа табышлар шактый күп булган – ул чакта ул Мәскәүдәге иң яшь баш редактор саналган. Ә башкалага кадәр, тагын да яшьрәк чакта, ул периферияда – Курскида, Әстерханда, Харьковта редакторлык эшен алып барган. Үзенең редакторлык юлын Григорий Евгеньевич Казанда башлаган. Башта «Красная Татария» газетасында эшләгән, дөрес, ул чакта әле үзенең креативлыгы белән бик алдырмаган. Аның каравы, 1925 елның маенда «Причал»да «рәхәтләнгән» инде!

«Почмаклардан чыгарырга!» – Цыпинның фотографлар өчен уйлап тапкан бу шигаре соңыннан үзе белән Мәскәүгә дә күчә. «Фоторепортёрны фактларны җыючы гына түгел, фактлар белән дә эшләүче журналист итәргә. Фоторепортёр, журналист кебек үк, газетада үз исемен күрергә хаклы. Без фоторепортёрны почмактан чыгарырга... һәм аны газета лабораториясенең органик өлеше итәргә телибез».

ТР Милли китапханәсенең вакытлы басмалар бүлегендә сакланган «Причал» төпләмәсе бүгенгә кадәр үз заманына кызыктыргыч сәяхәт үрнәге булып тора. Аны һәркем сокланып та, йотлыгып та укый: зур фоторәсемнәр, чәнечкеле баш исемнәр – Цыпинның «Вечерняя Москва»сы менә каян башланган икән. «Причал»ның элеккеге баш редакторына газетаны тагын да җанлырак һәм популяррак итү бурычын йөкләгәндә, аны нәкъ шулай, Казанның «Причал»ына охшатып күзаллаганнардыр.

«ЦЫПИН АЛТЫНЫ»

«Вечерняя Москва»га Цыпин озак җитәкчелек итмәгән – нибары ярты ел гына. 1935 елда аны Детиздат мөдире итеп билгелиләр. Аның әдәби талантына монда киң юл ачыла – ул бастырып чыгарган әсәрләр соңыннан совет классикасына әверелә: алар затлы, алтын тышлыклар белән. Мәскәүдә хәтта шундый шаян гыйбарә дә йөри – «Цыпин алтыны». Ул хәтта Ильф һәм Петровның «Язучы язарга тиеш» дигән фельетонында да очрый – анда әйбәт укыган балаларга «алтын цыпин тышлыклы китап» бүләк итәләр.

ЦЫПИН САМОВАРЫ

Күп язучыларны Цыпин мәңгелек дан, мактау һәм әйбәт гонорарлар белән тәэмин итә. Яхшылардан да яхшыларны эзләгәндә, ул шундый ысул уйлап таба – нәшрият коридорына кайнап торган самоварлы һәм крендельләр вазасы булган өстәл куйдыра, шул рәвешле Детиздатны язучылар клубына әверелдерә: әдәбиятчылар анда бер-берсе белән аралашырга да килә башлый. Кайчакта ул үзе дә алар янына чыгып утыра һәм, кем әйтмешли, «колакларын торгызып» тыңлый. Аннары сүз уңаеннан: «Ә менә мондый китапка, бәлки, без сезнең белән килешү төзер идек...», – дип куя. Шул ук вакытта бу бәхетле кешегә аванс та бирелә. Кайбер талантларны Цыпин аталарча кайгырта. Аркадий Гайдарның, мәсәлән, акчасы бармак аша аккан ком кебек юкка чыга торган була. Һәм Цыпин аңа, акчасын берьюлы бетермәсен өчен, гонорарны өлешләп, ай саен биреп бара. Ә Корней Чуковскийны Ленинградтан Мәскәүгә күчәргә күндерә. Вәгъдәсен рәсми бланкка яза: киләсе елдан да калмыйча, балалар язучысына 1нче Мещан урамыннан биш бүлмәле фатир бирергә. Тик өй туе, Цыпин кулга алыну сәбәпле, булмый кала. Әмма Чуковский күчеп китәргә инде әзер була, шуңа да комсомол ҮКның генераль секретарена мөрәҗәгать итеп, Переделкинода арендага дача алуга ирешә.

КУЛГА АЛЫНУ ҺӘМ АТЫЛУ

Григорий Цыпинны 1937 елда кулга алалар.

Әле генә Детиздаттан «чистартылган» Григорий Евгеньевич бер интервьюсында, кулга алынганчыга кадәр, бу хәлнең булачагына әллә ышанмыйча, әллә мондый язмыш үзенә тимәячәгенә өметләнүен менә болай тасвирлый:

– «Менә уйлап карагыз: без Кызыл профессура институтында курста унбер кеше идек – тугызыбызны алдылар, миңа тимәделәр.

– Без Кагановичта алты ярдәмче идек – бишебезне алдылар, ә мине чакырмадылар да!

– «Известия» редакторы Бухаринда без биш урынбасар идек, Бухарин белән бергә дүртне алдылар, ә миңа тимәделәр. Димәк, барысын да алмыйлар! Ә? Сез ничек уйлыйсыз?»

Шулай да аны нәкъ Яңа ел алдыннан кулга алалар – 1937 елның декабре ахырында. 1 гыйнварда, Яңа ел белән котларга дип, аңа дусты Лев Разгон шалтырата. Телефон җавап бирми. Аның кулга алынуына ике көн була инде. 1938 елның 29 августында Цыпинны «контрреволюцион террористик оешмада катнашкан өчен» атарга хөкем итәләр. Карар шул көнне үк тормышка ашырыла. Аңа 39 яшь була. Григорий Евгеньевич үлеменнән соң – 1956 елның 8 декабрендә аклана.



ИҢ кыю

1926 елның март аенда «Причал»ның исеме тагын алышына. Бу юлы «Спутник партийного активиста» дигән исемгә. ВКП (б) өлкә комитетының айлык теоретик һәм сәяси органы рус телендә төгәл ун тапкыр чыга. Әлеге тынычсыз кыска гына вакыт аралыгында журналга «Татарстан» тарихына иң кыю редактор булып кереп калган Мендель Хатаевич җитәкчелек итә.

РЕСПУБЛИКА БУЕНЧА БАШ – ЖУРНАЛ БУЕНЧА БАШ

Мендель Хатаевич журналның җаваплы – баш дип укы! – редакторы гына түгел, бер үк вакытта ВКП (б) Татар өлкә комитетының җаваплы – баш дип укы! – секретаре да булган (мөгаен, бу вазыйфа аңа кураторлык рәвешендә өстәмә эш итеп бирелгәндер). Әлеге яшь, тынгысыз большевикны яшь Татар республикасы белән командалык итәргә Самарадан җибәргәннәр. Нәкъ менә шунда, Валериан Куйбышев белән иңгә-иң торып революция өчен көрәшкәндә, ул матбугатта, җыелышларда, партия конференцияләрендә кыю чыгышлары белән танылa, партия эшенең таркалуын, салмаклануын, бюрократизмны, пропаганда һәм агитация эшенең алып барылмавын, башкача фикерләүче коммунистларга карата террор очракларын кискен тәнкыйтьли. Моның өчен Мендель Хатаевичның оппонентлары аны «сәяси тактсызлыкта һәм карьеризмда» гаепли.

Замандашлары хәтерләвенчә, кыяфәте белән Маяковскийга охшаган була. Һәм җаваплы редактор үзенең редакторлык вазыйфасын калдырганнан соң, журналда Маяковский шигырьләре басылып чыккач, кайберәүләр аларны, псевдоним артына яшеренеп, Мендель яза, дип тә уйлаганнар. Бәлки әле, аның Маяковский кебек өзеп, кычкырып, яңгыратып сөйләве һәм төп-төз итеп кирәкле ноктага «тидерә» белүе дә сәбәпче булгандыр.

ПРОФЕССИОНАЛИСТ ТҮГЕЛ

Мөгаен, «эшче оппозиция»гә каршы үзенең төп сугышын ярлы яһүд гаиләсеннән чыккан, профессиясе буенча теш техникы, ул чакта әле 30 яше дә тулмаган Мендель Хатаевич 1921 елның 2 февралендә Самарада гомумшәһәр партия җыелышында ачкандыр. Ленинның профсоюзлар турындагы тезисларын яклап сүз алган һәм бу чыгышының үзе тарафыннан кыюлык һәм әрсезлек булуын тыйнак кына таныл: «Мин профессионалист түгел һәм монда чыгыш ясаучы Троцкий һәм карт профессионалист Милонов кебек мәсьәләне алай ук яхшы белмим», – дип, бу вакытларда Самарага килеп йөргән танылган полемист һәм оратор Лев Троцкийны искиткеч оста итеп «юкка чыгара».

«БЕРЕНЧЕ ПРИКАЗ БЕЛӘН ҮК ГОМЕРЕМНЕ БИРӘМ»

Газета-журнал эшчәнлегенә омтылышны Мендель Маркович университетларның ул заманда башка да килмәгән журналистика факультетларында сеңдермәгән һәм, гомумән, ул нибары башлангыч яһүд мәктәбен генә тәмамлаган – аның тикшерү эшләрендәге карточкасына да «Образование низшее» дип язылган. Туган шәһәре Гомельдә ул 13 яшеннән газеталар таратып йөрергә мәҗбүр була, ә 1911 елда хәтта үз киоскын да ача, большевиклар белән танышканда ул аңа бик ярап куя – ул иптәшләренә яшерен «Правда», «Звезда» газеталарын таратырга булыша. Революцион тормыш Мендельне чыныктыра. Кулга алулар, сорау алулар, кыйналулар, Себергә сөрелү, «үлем поезды»ннан могҗиза белән качып исән калу... Кичергәннәренең нәтиҗәсе – карьера баскычы буйлап тиз арада күтәрелү, монысына күпләр көнләшерлек.

1925 елда ТАССРга ул шундый характеристика белән килә: «Үзен алдан күрүчән һәм зирәк җитәкче итеп күрсәтте». Һәм, Татарстан өлкә комитеты секретаре буларак, үзенең талантлы оештыручы булуын да раслый. Яшь илдә һәм яшь Татар республикасында көчле сәяси һәм икътисадый процесслар бара – күмәкләштерү, индустриальләштерү, НЭПның чәчәк атуы һәм тыелуы... Тормыш һәрьяклап чишмә кебек тибә, һәм яшь коммунист боларның барысы белән дә җиңел эш итә. Барысы да аның кайнап торган энергиясен һәм партиянең генераль линиясен яклагандагы принципиальлеген таный. Хатаевич чын коммунист була. Аның 1931 елның апрель аенда Сталинга язган хаты сакланып калган: «Нервлар хисабына, бернинди көчне дә кызганмыйча, бик киеренке эшләргә туры килә. Мин партия мәнфәгатьләрендә һәм аның беренче приказы нигезендә һәр мизгелдә үземнең гомеремне һәм бөтен көчемне тулысынча бирергә әзер торуымны шәхсән үземнең үткәннәрем белән расладым һәм һәрвакыт раслый алам».

КОНТРРЕВОЛЮЦИОН ТЕРРОРИСТИК ОЕШМАДА КАТНАШУ

Үзенең гомерен ул партия приказы белән 44 яшендә корбан итә. Мендель Хатаевич НКВД хезмәткәрләре тарафыннан 1937 елның 9 июлендә кулга алына. Аны «контрреволюцион террористик оешмада катнашу» формулировкасы белән гаеплиләр. «Өчлек»нең 1937 ел 27 октябрьдәге карары белән ул үлем җәзасына хөкем ителә һәм шул төндә үк атып үтерелә.

1956 елның февралендә аклана һәм партия сафларында торгызыла. Үлгәннән соң, әлбәттә.



ИҢ популяр

Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы җимереклек елларында журналны чыгару тукталып тора. Ә 1958 елның гыйнварыннан «Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарии») исеме белән татар һәм рус телләрендә кабат чыга башлый. «Матбугат – һәр партиянең үткен идея коралы... «Татарстан коммунисты» журналының чыгуы безнең илдә ленинчыл милли сәясәт тантана итүенең бер билгесе...», – дип яза яңартылган журналның сәламләү сүзендә җаваплы редактор Шәмси Хамматов.

УКЫТУЧЫЛЫКТАН – АВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕНӘ

Белеме буенча Шәмси Хамматов – мәктәп укытучысы. Мәктәп җитәкчелеге авыл укытучысы Шәмси Хамматовка: «Ике чирек дәвамында аның классында өлгереш чирек тапкырдан күбрәккә күтәрелде, укучыларның 91,3 проценты 4 һәм 5 кә укый», – дип характеристика язганда, ул әле яраткан профессиясен тагын да ныграк яратачак икенче профессиягә алыштырачагын һәм егерме елдан артык Татарстан Журналистлар союзын җитәкләячәген, күренекле журналистлар плеядасын тәрбияләячәген һәм республиканың төп журналы «Татарстан коммунисты»н, аннары «Советская Татария» һәм «Социалистик Татарстан» газеталарын җитәкләячәген белми.

Шәмси 19 яшендә туган авылындагы мәктәпнең директоры була. Аннары – комсомол райкомы секретаре, соңыннан партия райкомы аппаратына күчә, берничә тапкыр ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайлана. Партия эше аны журналистикага «китереп җиткерә» дә инде. Үзе әйтүенчә, ул «актив авыл хәбәрчесе була».

ТАТАРСТАН ЖУРНАЛИСТИКАСЫ БРЕНДЫ

Шәмси Хамматовның абруе Татарстанда да һәм аннан читтә дә искиткеч югары була. Хамматов чирек гасыр буена диярлек Татарстан журналистикасының бренды булып тора. Ул журналистларны халыкны «тормышның төрле өлкәләрендәге җанлы, конкрет мисалларда һәм үрнәкләрдә» тәрбияләргә чакыра. Коллегаларын ул еш кына материалларындагы пропагандистлык штамплары өчен тәнкыйтьли. «Менә шундый факт күзгә ташлана: кайбер яшь журналистларның проблемалы материаллар язарга теләмәве. Психологик яктан аңлап була, үзең яшәгән район, шәһәрдән тәнкыйть мәкаләләре язу бик уңайлы түгел. Әмма урында хәл ителә алмаган мәсьәләләрне гомуми эш мәнфәгатьләрендә республика, үзәк матбугатта күтәрү өчен тәвәккәлрәк булырга кирәк», – дип сөйли ул журналистлар семинарларының берсендә.

ЖУРНАЛИСТЛЫГЫ – ХОДАЙДАН

Гаиләсе белән ял иткән чакларда да Шәмси Хамматов эше турында онытмый.

Һәрвакыт кем беләндер полосаларны, материалларны, вёрстканы тикшерә... КПСС өлкә комитеты бюросы әгъзасы буларак, ул хакимият һәм гади журналистлар арасында конструктив диалоглар төзи ала. Әле тагын Казан дәүләт университетында журналистика кафедрасы булдыру идеясе дә – аныкы.

ТЕЛ ЮК ИКӘН – ХАЛЫК ТА ЮК

Журналист туган татар телен саклау өчен көрәшне үзенең төп вазыйфаларыннан берсе дип саный. Ул еш кына: «Тел юк икән – халык та юк», – дип кабатлый. Шул ук вакытта Шәмси Хәбибуллович рус телен дә яхшы белә торган була. Шуңа да партия җитәкчелеге «Советская Татария» һәм «Социалистик Татарстан» газеталары редакцияләрен берләштерергә карар иткәч, берләштерелгән редакция белән җитәкчелек итүне Шәмси Хәбибулловичка тапшыра – ул ике тел белән дә бердәй эш итә.

«МӘСКӘҮГӘ ИШЕК»

Аны бөтен җирдә – Мәскәүдә һәм Кыргызстанда, Үзбәкстан һәм Казахстанда беләләр иде, дип сөйлиләр. Ә инде ул Мәскәүгә төрле җыелышларга килгән чакта бары тик аның өчен генә вокзалга авто җибәрә торган булганнар. Ул чор журналистлары: «Шәмси Мәскәүгә ишек кебек иде. Анда баргач: «Без Шәмси Хамматовтан», – дип әйтү җитә, безгә бөтен юллар ачыла иде», – дип искә алалар.

ТР МИЛЛИ МУЗЕЕ

ИҢ ТӨРЛЕ

Автор: Татьяна Вафина

Татарстан Республикасының 125 яшьлек Милли музее йөзьяшәр «Татарстан» журналын һәм аның укучыларын ни белән генә гаҗәпләндермәде инде! Раритет чыршы уенчыклары белән дә, җанлана торган экспозицияләр белән дә, шәһәр читенә гадәти булмаган экскурсияләре белән дә... Мультимедиа лекцияләре һәм интерактив музей-педагогика дәресләре, квест-уеннар һәм сугыш чаралары инсталляцияләре...



Инде бөтен нәрсә уйлап табылган, музейның озын гомерендә булмаган нәрсә калмаган кебек, әмма музейчыларның яңа идеяләре безне һаман саен әлеге үткәннәр патшалыгына кызыктырып чакырып алып керә. Бу юлы да шулай булды. Сәгать ярымга. Шул вакыт эчендә без иске әйберләрдән һәм татарстанлыларның шәхси хатирәләреннән тупланып, Татарстанның зур тарихын хасил иткән сәхифә белән таныштык – «Борынгы гасырлардан бүгенгә кадәр Татарстан тарихы» мавыктыргыч экскурсиясен хозур кылдык.

Фото: Александр Ефремов

– Миңа хәзерге заман җитми, – ди ТР Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова. – Безнең Татарстаныбызның мәнә хәзер – бүген, бу мизгелдә нинди булуын күрсәтәсе килә.

Нәкъ менә шуңа күрә без башта таш, бронза һәм тимер чорларының археологик табылдыклары белән танышабыз. Безнең эрага кадәр 100–35 мең ел элеккеге чын нуклеус һәм кремний балталарга карап хозурланабыз. Безнең эрага кадәр V–IV гасырларга караган бронза айбалталарга. Танкеев борынгы каберлегендә табылган IX–X гасырлар көмеш битлегенә... Һәм тагын әле боларның барысын да табучы, предметларның яшен билгеләүче, аларның ничек кулланылуын ачыклаучы, моның белән XIX гасырдан бирле шөгыльләнүче кешеләр – Казан университеты профессурасы, бигрәк тә тупланмасы нигезендә әлеге музей оештырылган безнең атаклы Андрей Фёдорович Лихачёв белән «танышабыз».

Без музейга экспозиция әзерләнеп яткан вакытта килеп эләктек: зур һәм кечкенә экспонатлар запасниклардан чыгарыла, легендар шәхесләрнең бәһасез әйберләре пыяла киштәләргә тезелә, диварларга борынгы фотосурәтләр эленә, һәр раритетның кая урнаштырылачагы уйланыла, электрон «визиткаларга» кирәкле материал кертелә, күргәзмәнең һәр почмагы җиренә җиткерелә...

МАВЫГУЧАН ҺӘМ МАВЫКТЫРУЧАН

Һәр чор өчен музейда аерым гыйльми хезмәткәр җаваплы, ул үз участогының авторы һәм шунда экскурсияләр үткәрү – аның карамагында. Әмма ТР Милли музееның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова экспозициянең теләсә кайсы залында үзен бик иркен тота. Шунлыктан безгә экскурсия үткәрүчеләр кирәк булмады, чөнки директор Татарстанның борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр тарихын яттан белә! Барлык даталары һәм цитаталары белән! Һәм бу, әлбәттә инде, сокландыра. Студент чакта тарихтан имтихан биргәндә шундый әйтеп торучы булсын иде ул...

– Татарстан тарихы, территорияләр тарихы – ул бит 1920 елдан гына башланмый, – дип экскурсиянең башыннан ук игътибарыбызны җәлеп итә Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы. – Безнең экспозициябез кебек үк, ул да хронологик яктан 40 мең елдан артыграк вакытны һәм таш гасырдан алып безнең эраның I меңьеллыгы азагына кадәрге археология ядкәрләрен колачлый. Җөмһүриятебез борынгы дәүләтчелек тарихына ия.

ИДЕЛ БОЛГАРЫНЫҢ АКСЫЛ ЧӘЧЛЕ КЕШЕЛӘРЕ

Татарстанның урта гасырлардагы тарихына күчкәндә, зәңгәр күзле, аксыл чәчле кешеләрнең бөек болгарлар варисы булуын күреп горурланабыз – тарихчылар ышандыруынча, алар 922 елда да нәкъ шундый булган, ул чакта алга киткән, күпмилләтле, күпдинле, алдынгы мәгариф системасы – мәктәп-мәдрәсәләре булган Идел Болгары дөньядагы иң куәтле ислам дәүләте саналган... Идел Болгары, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларының археологик тупланмасы X–XIII гасырлар табылдыклары, зәркән эшләнмәләре, бакыр, бронза һәм көмеш бизәнү әйберләре белән таң калдыра. XII гасырга караган үрдәкле алтын чигә асылмасы аеруча матур...

Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы безнең игътибарыбызны Әбүбәкер останың 1146–1147 еллардагы гарәп язулы йозагына һәм Казан ханлыгы чорыннан сакланып калган бердәнбер документка – Казан ханы Сәхибгәрәйнең 1523 елгы ярлыгына юнәлтә.

МӘРҖАНИ БАЛДАГЫ

Казан губернасы чорына, әлбәттә инде, Екатерина II нең атаклы каретасына «утырып» барып керәбез. Бу чорда сәяхәт иткәндә без атаклы якташыбыз, шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның бүлмәсенә дә күз сала алабыз. Дворян йортында һәм гадәти татар өендә кунак булабыз. Казан университеты лабораторияләрендә дә «йөреп чыгабыз» – атаклы галимнәр эшчәнлеге белән танышабыз, алар файдаланган химия һәм астрономия әсбаплары, геология, археология һәм этнография тупланмаларын күрәбез.

Биредә татар галимнәре, мәгърифәтчеләре, язучылары – Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Фатих Әмирханның басмаларын һәм шәхси әйберләрен, шулай ук данлыклы Шиһабетдин Мәрҗани балдагын күрергә була...

Көнкүрештә кулланылган күп әйберләр бүгенге көнгә кадәр зур үзгәреш кичергән – бу бигрәк тә телефон аппаратлары эволюциясе аша яхшы күренә. Ә телеграф? Бүгенге балалар аның нигә кирәклеген аңлар микән?

ТАССРның беренче гербы. Авторы – Бакый Урманче.

Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең эш кабинеты.

Беренче совет телевизорлары.

«Яңалиф» шрифты булган беренче басу машинасы.

Беренче совет компьютеры.

САМОДЕРЖАВИЕ ЮККА ЧЫКСЫН!

Уникаль экспонат – Алафузов фабрикасындагы механик туку станогының бормалары һәм функционалы белән гомумән сәгатьләр буе хозурланырга була... Әмма моңа вакыт юк. Революция якынлаша. Ул инде борылышта ук, киләсе залда гына.

Листовкалар һәм агитация плакатлары. Кораллар һәм кинохрониканың аклы-каралы кадрлары. Англиядә җитештерелгән чын гаубица. «Берләшү» металлистлар һөнәри берлеге байрагы. Революцион вакыйгаларда турыдан-туры катнашучыларның – Ершов, Максуди һ.б. – шәхси әйберләре, чын документлары һәм фотосурәтләре. Һәм менә ниһаять ул – республика башланган нәрсә! Уникаль экспонатлар арасында – «Идел-Урал Штаты» картасы, Татар республикасы картасы, герб эскизы (1920 елгы проект, авторы – Бакый Урманче), республика игълан ителүгә бәйле чаралардан фотосурәтләр, 1920 нче елларның беренче флагы.

НАДАНЛЫККА КАРШЫ КӨРӘШКӘ КҮТӘРЕЛИК!

Һәм инде Совет Татарстаны башлана! Наданлыкка һәм ачлыкка каршы көрәш сәхифәләренә чумабыз. Яңа предприятиеләр һәм сәнәгать тармаклары пәйда булуны, авыл хуҗалыгы, мәдәният, татар теле һәм әдәбиятының үзгәртеп корылуын күрәбез.

Пыяла астында 1920–1930 нчы еллардагы кебек үк җете булып завод-фабрикаларның байраклары аллана. Совет машина төзелешенең беренче үрнәге – «Фордзон-Путиловец» тракторы да Екатерина каретасыннан бер дә ким түгел, аны тартып йөрү өчен атлар да кирәкми. Диварларда яңа спектакль һәм концертларның чуар афишаларын күреп була.

Хәрби Татарстан Бөек Ватан сугышының героик вакыйгалары белән чын әйберләр аша таныштыра. ТР Милли музееның кареталар, тракторлар һәм гаубицалар гына түгел, сәнәгать предприятиеләренең иң зур үрнәге – По-2 самолетын да күрсәтеп мактанырлыгы бар. «Төнге убырлар» кушаматы тагылган очучы кызларыбыз һәм безнең данлыклы Мәгубә Сыртланова фрицларны нәкъ менә шундый очкычлардан бомбага тоткан. Сугышта катнашучыларның бүләкләре, фронтовик язучыларның мемориаль комплекслары аерым бер урынны алып тора, алар арасында – Муса Җәлилнең Моабит дәфтәрләре һәм Фатих Кәримнең фронт блокнотлары. Капма-каршы диварлардан, зурайтылган фотосурәтләрдән, Татарстан язучылары бер-берсенә карап тора: җыелышып сугышка кадәр һәм сугыштан соң төшкәннәр. Аермалык эзли башлаучылар аны киемнәреннән генә түгел, җитешмәгән йөзләрдән дә табачак – алар барысы да сугышкан, әмма күбесе яу кырында ятып калган, кире кайтмаган.

БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТНЫҢ ЭШ ӨСТӘЛЕ

Сугыштан соңгы чордагы Татарстан АССРның нефть химиясендәге, машина төзелешендәге казанышлары, мәдәният үсеше һәм республиканы СССРның иң алдынгы төбәкләреннән берсенә әйләндергән зур фән мәктәпләре оешу белән горурланып, тагын мөһим вакыйгаларга якынлашабыз. Алар узган гасырның 90 нчы елларында булган һәм инде хәзер шулай ук тарихка әйләнгән.

Татарстан Совет Социалистик Республикасының Дәүләт суверенлыгы турында декларация кабул итү, Президентлык институтын кертү, Татарстан Республикасы Конституциясен булдыру – болар барысы да республика тормышының барлык тармакларында тотрыклы үсеше өчен нигез булып тора. Туп-туры «Беренче Президент Минтимер Шәймиев кабинетына» килеп керәбез. Аның яшел постау җәелгән эш өстәле, идәндәге келәме, глобусы... Әлеге өстәл артында суверенитет язмышы хәл ителгән.

ҮТЕП БАРУЧЫ ЗАМАН

Безнең көннәргә дә ерак калмый: туксанынчы еллардан ике меңенче елларга аяк басабыз. Татарстан Россиянең спорт башкаласына әверелә – экспозициядә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасының Ут касәсен һәм факелын, спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатының бүләкләрен, Универсиада һәм 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты волонтерлары формаларын күрергә була – әлеге вакыйгалар әле кичә генә булган кебек, ә инде күпме вакыт үткән...

– Миңа хәзерге заман җитми, – ди экскурсия үткәрүче директорыбыз. – Безнең Татарстаныбызның менә хәзер – бүген, бу мизгелдә нинди булуын күрсәтәсе килә. Хәзерге заманны документлаштыру бик кыен. Чөнки һәр көн бик тиз арада тарихка – бер көн тарихына әйләнә, шундый көннәр тиземе инде аннары безнең «Татарстаныбызның борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр тарихын» тәшкил итә.

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар язучылары.

Бүген инде музейда гына күчеп йөри торган транспорт чаралары.

1 НЧЕ ТАРИХ. БАЛТАЛЫ АЮ

Мәгълүм булганча, театр – кием элгеченнән, ә Татарстан тарихына багышланган экспозиция исә аның районнары гербларыннан башлана. Аларда табигый байлыклар һәм әлеге җирлекнең тарихы чагыла. Кемдәдер бу – балык, кемдәдер – нефть. Ә менә, мәсәлән, Балтач районы гербында балталы аю сурәтләнгән. Нигә аю һәм ни өчен ул балта тоткан? Балтач – авылга нигез салучылардан берсенең исеме, ул исә, үз чиратында, «балта», «балтачы», «балта остасы» сүзеннән ясалган. Балтаны урман хуҗасы – аю тоткан. Тагын әле ул балта остасы да, төзүче дә. Ул йорт сала – бу Балтач балта осталарының традицияләренә һәм уңганлыгына ишарә булып тора.

2 НЧЕ ТАРИХ. АЛЬБИНА ШАҺИМОРАТОВА КҮЛМӘГЕ

Музейда экспонатларның ничек табылуына бәйле тарихлар күп саклана. Мәсәлән, дөньякүләм танылган опера җырчысы Альбина Шаһиморатованың концерт күлмәге бар – ул аны музейга үзе бүләк иткән. Аннан күрмәкче, башка артистлар да үзләренең атаклы концерт һәм театр костюмнарын, ниндидер реквизитларын рәхәтләнеп музейга бүләк итә башлаган. «Әкият» Татар дәүләт курчак театрының иң беренче курчакларыннан берсе дә биредә шул рәвешле пәйда булган.

3 НЧЕ ТАРИХ. ГАРМУНЧЫНЫҢ СӨЙГӘН КЫЗЛАРЫ

«Асия», «Мәликә», «Мәрьям», «Фәхерниса»... – һәр кечкенә гармунның үз исеме бар. Әлеге гүзәл кызларның исемнәрен виртуоз гармунчы Фәйзулла Туишев үз гармуннарына кушып мәңгеләштергән. Һәркайсы белән ниндидер шәхси романтик тарих бәйле икән аны. Иҗат кешесенең мондый тарихлары күпме булырга мөмкин? Кем белсен?! Һәрхәлдә, Фәйзулла тупланмасында төрле зурлыктагы 17 гармун бар, иң кечкенәсе – шырпы кабы кадәр генә. Алар барысы да матур тавышлы, моңлы, тыңлаучан. Мөгаен, үзләренә исемнәре кушылган кызлар кебектер.

4 НЧЕ ТАРИХ. МИЛЛИОН СУМЛЫК ХӘРБИ ЙӨК МАШИНАСЫ

Бу йөк машинасы безгә Ленинград яныннан кайтарылды. Аның хуҗасы гомере буе эзләнү эшләре белән шөгыльләнгән, Ленинград һәм Волхов фронтлары территорияләрендәге сазлыклардан сугышта һәлак булган солдатларыбызның җәсәдләрен эзләгән. Ул вафат булгач, хатыны бер ярдәмсез, бөтенләй акчасыз калган. Шушы йөк машинасын миллион сумга сатып алучыны табарга һәм Казанга алып кайтырга кирәк иде. Мин Президентыбызга яздым, ул, озак уйлап тормыйча, акча бирде.
Бөтен нәрсә акчага бәйле заманда яшибез бит, гомерен изге эшкә багышлаган кешенең гаиләсенә ярдәм итеп, республикабыз дөрес эшләде. Музей исә тагын бер кыйммәтле экспонатка баеды: машинаның кузовы табылган предметлар – корал, значоклар, орденнар, медальоннар белән тулы иде...

5 НЧЕ ТАРИХ. БУ КОММУНАЛЬ ФАТИР...

Чын коммуналь фатир үрнәгендә торгызылган фатир экспозициядә аеруча популяр. Чын коммуналкалардагы предметлар белән җиһазландырылган фатирның әле коридоры да бар. «Коммуналка бүлмәләрендә тәртип һәм чисталык булса, – дип сөйли Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы, – коридорга велосипедтан чаңгыга кадәр бөтен нәрсә чыгарып өелгән, һәм әлеге коридордан берәр нәрсәне бәреп аудармыйча үтү бик кыен булган».

ИҢ ЯҢА

МУЗЕЙЛАР АРТЫК БУЛМЫЙ

Автор: Руфия Фазылова

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгына килеп кергәч тә, бер урамга юлыгасың. Бизәкле капкалы, тәрәзәле матур йортлар тезелеп киткән. Ерактан караганда биредә кеше яши кебек. Һәм бары якынрак килгәч кенә, элмә такталардан укып, бу йортларның музей икәнен абайлап аласың.

ТАТАР ЧӘЕ БЕЛӘН СЫЙЛАНАСЫҢ КИЛСӘ...

Сәяхәтне иң беренче йорттан башладык – бу самоварлар музее. Дөрес, аның рәсми исеме бар – «Болгарча чәй эчү музее». Урамнан кергәндә үк ишек алдында үсеп утыручы төрле үләннәргә күз төште. Аларны матурлык өчен генә түгел, ә чәй пешерү өчен кулланалар икән.

– Атнага бер көн музей ишек алдында мастер-класс үткәрәбез, болгар чәе пешерәбез, – диде Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгының гыйльми сәркатибе Гөлнара Бирюкова. – Моның өчен ишек алдында үскән барлык шифалы үләннәрне, шул исәптән карлыган, җиләк яфракларын алабыз. Килгән кунаклар мондый чәйне үзләре ясап, мактый-мактый эчеп, шаккатып китәләр. (Сүз уңаеннан, андый шифалы чәйне безгә дә эчү бәхете тәтеде. – Авт.).

Йорт эченә уздык. Бер ак әбинең сөйкемле йорты кебек ул. Шуңа дамы музей дип әйтсәң дә килми. Нигезнең тарихы белән кызыксынам: XVIII гасыр азакларында салынган агач йорт икән. Бер яклы гына ул. Биредә гади крестьян гаиләсе яшәгән. Йортларны хуҗаларыннан сатып алганнар да менә шундый музей-йортлар ясаганнар.

Самоварлар дидем бит, аларның биредә 68 төре бар. Беренче карашка бер-берсенә охшаш булсалар да, һәркайсы үзенчәлекле. Борыннары белән булса да аерыла.

– Самоварлар XIX гасырның икенче яртысыннан алып, XX гасырның 70 нче елларында эшләнгән, – диде Гөлнара Бирюкова. –Аларның күбесе Тула шәһәрендә ясалган. Арада Баташев, Воронцов, Тейле, Шемарин кебек атаклы самовар ясау осталарының эшләре дә бар.

Музей самоварлары арасында төрле «язмышлылары» бар. Кемдер иске йортын сүткәндә әбисеннән калган кадерле ядкәрен музейга китереп биргән. Кайсыдыр самоварлар махсус сатып алынган. Һәркайсының кыскача тарихы язып куелган.

– Безнең җирлектә татарлар, руслар, чувашлар гомергә дус булып яшәгән, – диде Гөлнара ханым. – Яши-яши алар бер-берсенең көнкүрешләрен дә кабатлаган. Самовардан чәй эчү шундыйлардан. Кадерле кунак килсә, әби-бабаларыбыз самоварын куеп җибәргән. Чыра ягып, чәй кайнаткан. Шөкер, бу гадәт бүген дә исән. Халыкта самовар музее белән кызыксыну шуңа да зурдыр.

АБДУЛЛА АЛИШ – ЯКТАШЫҢ БЕЛӘН ГОРУРЛАНУ

Икенче агач бизәкле капка – Абдулла Алиш музее. Язучының туган авылы Көектә Абдулла Алишның музее бар. Бөек Болгарда да атаклы якташлары исемен мәңгеләштерергә теләгәннәр. Хәер, Абдулла Алишның тормышы Болгар белән дә бәйле. Булачак язучы биредә Спас педагогия техникумы каршында оештырылган рус мәктәбендә укыган.

Музей, мәйданы белән зур булмаса да, язучының бөтен тормыш юлы, иҗатын колачлаган. Ни кызганыч, Алишның шәхси әйберләре юк диярлек. Алай да музейда XX йөз башы мохитен тудырырга тырышканнар. Шул чорга караган ир-ат, хатын-кыз киемнәре, көнкүреш кирәк-яраклары, басу машинасы һ.б. Алиш әсәрләренең кульязмалары (күчерелмәләре), фронттан язган хатлары...

Фото: Александр Ефремов

Әлбәттә, узган елгы белән чагыштырганда, быел килүчеләр бик аз булды. Чагыштыру өчен бер сан – сентябрь башына узган ел 530 мең турист килеп киткән иде, быел – 134 мең генә. Нәрсәдер әйтеп тору артык... Быел күбрәк үзебезнең республикадан, гаиләләр белән киләләр. Башка төбәк туристлары белән чагыштырганда, безнекеләр Абдулла Алишның кем икәнен бик яхшы белә. Алай гына да түгел, өйдә язучының әкиятләрен укыйлар икән. Балалар белән аралаша башлагач, шуңа инандык. Бергәләп Алиш әкиятләрен сөйләдек. Мондый туристлар белән очрашу безнең өчен икеләтә күңелле!

...Әйе, аңлашыла, Болгарга халык меңләп килә. Алишның Спас районындагы рәсми музеен Болгарда булдыру әйбәттер дә. Тик татар халкына бөек ул биргән Көек авылында да Абдулла Алиш музее саклансын иде. (Ул бүген Мәдәният йорты каршындагы музей буларак эшли). Ә Болгарның яңа музейларына күп кызыксынучан туристлар, озын гомер телик!

– Музейны мәктәп укучылары ярата, – диде Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгының гыйльми сәркатибе Гөлнара Бирюкова. – Алар өчен биредә төрле чаралар уздырыла. Шулай ук туристларда да кызыксыну зур.

Туристлар дигәннән, бер кызык нәтиҗә – Татарстаннан булмаганнарның күбесе Абдулла Алишны бик белми. Ә менә җәлилчеләр дигәч, Икенче бөтендөнья сугышында әсир төшеп, Берлиндагы Плетцензее төрмәсендә һәлак булучы унбер батырның берсе дигәч, кызыксыну бермә-бер арта икән. Соңыннан Абдулла Алишның китапларын кайдан алып булуын да сорыйлар...

Берничә ел элек Абдулла Алишның туган авылындагы музеенда булырга туры килде. Дөресен әйтим, атаклы язучының музеен мескен хәлдә күреп, көрсенгән идем. Ул чактагы район башлыгы Камил Нугаев, Абдулла Алишка яңа музей булдырырга ният бар, дигән иде. Әлеге ният Болгар белән бәйле булган икән.

– Көеккә бөтен кеше кереп тормый, шуңа күрә Абдулла Алишның дәүләт статусындагы музеен биредә ясарга уйладылар, – диде музей җитәкчесе Люция Сәгыйрова. – Чагыштырмача яшь музей әле без, 2019 елның июнь башында – Болгар җыены көнне ачылдык.

КИТАП К

КИЧӘГЕ БЕЛӘН БҮГЕНГЕ АРАСЫ

Автор: Луиза Янсуар

Һәрчак көтелмәгән темага алынган һәм аны без уйлап та карамаган ноктадан сурәтли белгән Барнс – монысына укучы инде ияләшкән. Яңа романы – янә бер кат шуның дәлиле. Әмма бу сезонның көтеп алынган яңалыгы минем өчен нон-фикшн жанрында булды. Ул да булса танылган, культ дәрәҗәсендә исәпләнгән журналист Джон Херсиның үз заманында «бомбадай» шартлаган күренекле әсәре. Аның рус телендә тулы канлы рәвештә беренче басылуы.



Ә ШУНДА БЕЗ БУЛСАК?!

Джон Херси. Хиросима.
Individuum, 2020.
Инглиз теленнән Михаил Казиник һәм Никита Смирнов тәрҗемәсе.

Китапның тулыландырылган басмасы китап платформаларында шушы көннәрдә генә пәйда булды. Джон Херси үз заманында Хиросима фаҗигасен үз күзләре белән күрүчеләрне беренче теркәүче була. Ул бу хатирәләрне гади кешеләр аңларлык телдә, барлык детальләре һәм фактологик төгәенлеге белән бергә, киң массаларга тәкъдим итә. Галимнәр һәм куркынычсызлык саклау хезмәтләре инде үзләренең җансыз, салкын отчетларын тиешле өстәлләргә кертеп салган, алар буенча дискуссияләр узган, билгеле. Ә менә тере кешеләр белән чынлыкта нәрсә булган соң? Бөтен дөнья җавап көтә… Иң беренче чиратта, Америка халкы.

Джон Херси мәкаләсен The New Yorker журналының август номеры өчен әзерли башлый. Аны шартлаудан соң калган җөй эзләре беренче карашка бераз йомыла төшкән шәһәрдән алынган репортаж буларак, басманың «бомбасы» рәвешендә, берничә санга сузып бирергә ниятлиләр. Бу вакытта инде эпицентрдагы радиация нормада исәпләнә, шәһәр яңадан торгызыла башлый. Шунысы гына бар: агачлар белән куаклар котырып үсә, ә кешеләр никтер һаман үлә дә, үлә.

Ахыр чиктә, Херсиның язмасына тулы бер номерны багышлыйлар – 1946 елның әлеге дә баягы атаклы август санын. Китап рәвешендә басылып чыккан репортаж исә 3 миллион нөсхәдәге тираж белән дөнья күрә һәм күз ачып йомганчы таралып бетә.

Альберт Эйнштейн коллегаларына таратыр өчен меӊ номер сатып алырга тели, әмма, ни кызганыч, бу нияте тормышка ашмый – журнал таралып беткән була. Күчермәләрен бастырып, таратырга туры килә.

Бу басма XX йөз Америка журналистикасының иң шәп үрнәге булып исәпләнә. Хәзер аны журналистика тарихы курсында өйрәнәләр, аның буенча диссертацияләр, фәнни монографияләр язалар. Джон Херсиның үзен милли геройга тиңлиләр.

1946 елның 31 августында басылып чыккан журналның тышлыгы җете-якты төсләрдән тора: парк, пляж, кешеләр кызынып ята, атларда һәм сәпиттә җилдерәләр, балык тоталар, бииләр, көлешәләр… Алга таба берничә полосада афиша бара: сезонда актуаль булачак спектакль, фильмнар, концертлар. Ә менә аннан соң – нонсенс, ягъни куркыныч-җитди «Хиросима» мәкаләсенә кереш. Хәрби репортер Джон

Фото: www.livelib.ru, ru.bookmate.com/books, wallhere.com сайтларыннан алынды.

ИШТӘСЕ

Херси материалына тулы бер журнал багышлау – мондый очрак журнал тарихында нибары бер генә мәртәбә була һәм башка кабатланмый.

Херси Япониягә 1946 елның язында килеп төшә, анда 3 атнасын уздыра. Бомбардировкадан соң исән калган кешеләрдән бик күп интервьюлар ала ул. Шулай ук – экспертлардан, чиновниклардан, медицина хезмәткәрләреннән дә. Әмма, ахыр чиктә, төп игътибарын сайлап алган 6 кеше язмышына юнәлтә. Бу кешеләр белән Херсины җирле рухани-иезуит таныштыра. Соңрак Херси болай ди: «Мин биналар белән ни булганы турында язарга теләмәдем, мин кешеләр белән ни булганы турында сөйләргә теләдем».

«Хиросима»ның тексты, югарыда әйткәнебезчә, атом бомбасы төшеп ярылган көнне Хиросимада исән калган 6 кешенең язмышына нигезләнә. Херси кинематографларча җентекләп укучысын шартлау ноктасына әзерли, диспозицияне булдыра. Әлеге алымны соңрак чыннан да «модернистларча кинематографлык» дип атыйлар, Херсины исә 60–70 нче еллардагы «яңа дулкын» вәкилләренә кадәр журналистикага яңалык кертүче буларак бәялиләр. Ул булмаса, яңа төр журналистика да булмас иде, ягъни.

Инде текстның үзенә килик. Менә ничек башлап китә ул журналистик язмасын:

1. *ТОСИКО САСАКИ исемле туташ, Көнбатыш Азия тимер эшләнмәләр заводының кадрлар бүлеге хезмәткәре, күрше өстәл артында утырган туташ белән сөйләшер өчен аңарга таба борыла.*

2. *ТЕРУФУМИ САСАКИ исемле әфәнде, яшь хирург, Вассерман реакциясен ачыклау максаты белән тестка дип алынган канны илтер өчен хастаханә коридоры буйлап атлый.*

3. *ВИЛЬГЕЛЬМ КЛЯЙНЗОРГЕ исемле атакай, алман руханиe, Иезуитлар миссиясе йортында раскладушкада яткан хәлдә дини журнал укырга керешә.*

4. *ХАЦУЁ НАКАМУРА исемле ханым, тегүче әфәндeнең тол хатыны, кухня тәрәзәсе каршына басып, күршеләренең үз өен җимерүен күзәтә.*

5. *МАСАКАДЗУ ФУДЗИИ исемле әфәнде, табиб, шәхси хастаханә хуҗасы, террасага чыгып, газета укырга утыра.*

6. *КИЁСИ ТАНИМОТО исемле әфәнде, Хиросиманың методистлар чиркәве пасторы, Кои бистәсендәге бай йорт каршында тукталып, кечкенә арбасын бушатырга керешә.*

Йөз меңнән артык кеше атом бомбасы шартлаудан һәлак була. Бу алтау исән кала.



Херси каһарманнары ни күрә һәм нәрсә кичерә соң? Һәр алтысының да кичерешләре җентекләп, детальләп сурәтләнә. Әмма ул бирегә шунда ук экспертлар фикерен китереп кушмый, иң башта шушы гадәти кешеләрнең чиста рефлексия ноктасыннан якын килә. Анализга аннан соң урын калдыра.

Дулкын китереп бәргәннән соң, барысының да асты өскә килә, яктылык нурланышыннан кешеләр терелэй яна. Радиация дулкынының нәрсәгә китерәчәген, ул китереп органнан соң, әле беркем дә белми. Әйтүләренә караганда, тыштан караганда зыян күрмәүчеләр дә дистәләп, йөзәрләп берничә көннән, атнадан һәм айдан соң кырыла башлый. Эпицентрдан 800 метр радиус ераклыкта булган кешеләрнең 95%ы нәкъ менә шул нурланыштан һәлак була.

Шулай да, иң куркынычы – кешеләрнең яклаучысыз, караучысыз, бөтенләе белән язмыш кулына тапшырылган булуы, дигән фикер уздырыла китапта. Мәгълүмати блокада эчендә калган халык, атна-ун көннәр узгач та, берни дә аңламый: нәрсә булды бу? Кем аларны бомбага тотты? Нинди бомба бу? Ә шәһәрнең читендә нәрсә? Кем гаепле бу хәлләргә? Безгә алга таба ничек яшәргә?!

«Хиросима»ның соңгы өлешен Джон Херси 1985 елда язып тәмамлый. Һәм китапның бу өлеше, асылда, тагын да дәһшәтлерәк һәм аянычрак. Әйе, Херси әле мәкалә язганда ук сөякләренә кадәр янып, күзләре агып чыккан, хәрабәләр астында калып, акыра-бакыра җан биргән адәмнәрне сурәтләгән иде. Андагы детальләр канны өшетә. Тик исән калган алты каһарманы язмышы аша алга таба ситуациянең борылышларын ваемлау – менә монда инде чын хоррор башлана. Әйе, бу алтау (алар кебек башка кайберәүләр дә) яңадан тормышка әйләнеп кайта. Тик бу корбаннарны «хибакуся», ягъни «кагылырга ярамый торганнар» язмышы көтә. Хиросима белән Нагасаки шартлауларын кичкәннән соң исән калучыларны әнә шулай атап йөртәләр. 2014 елның 31 марты исәпләре буенча, исән калучылардан 192 719 кеше була. Аларның күбесе җитди авырулардан интегә. Ә 2013 елның 31 августы исәпләре буенча үлгәннәр саны 450 меңнән артып китә.

«Хибакуся» мөһере белән тамгаланучыларга 50 нче еллардан башлап Япония хөкүмәте пособие түли, аларга медицина өлкәсендә өстәмә ташламалар каралган. Әмма бу кешеләр үзләре дә, аларның балалары да көндәлек тормышта кагу-сугуны әлегә кадәр күрә: аларны эшкә алырга атлыгып тормыйлар, алар белән гаилә корырга теләмиләр, нәселләрен «бозык» дип саныйлар, үзләренә җирәнеп карыйлар. Күпчелеге тормышын алга таба җайга сала алмый – әнә шул хакта бәян итә безгә Херси. Бу – «атомнан соңгы» яшәү өчен көрәшкә корылган язмышлар һәм тулы бер илнең фаҗигасе.

Херси китабының буеннан-буена бер генә сантимент та юк. Бу бик анык һәм тигез тон белән язылган әсәр һәм шуның белән ул коточкыч та.

Табиб Хасаки эшен системага салып торырлык хәлдә түгел иде: ул янәшәдә кем бар, шуны дәваларга кереште. Әмма озакламый абайлап алды: коридордагы кешеләр саны кимеми, ә арта гына. Менә арада коточкыч янган урыннары булучылар күбәя башлады. Шунда гына ул кешеләрнең ташкын булып урамнан керүләрен аңлады. Алар шулкадәр күп иде ки, ул инде җиңелчә яралар алучыларга игътибар да итмәскә кереште. Бу авыр хәлдәгеләре кан югалтудан гына үлә күрмәсен берүк дип теләде. Тиздән авырулар белән хастаханә шыплап тулды: алар палата гына түгел, ә лаборатория идәннәрендә, баскычларда, вестибюльдә, керә торган ишек төпләрендә дә бер-берсенә сөялеп утыралар, яталар инде. Хастаханәгә илтә торган юлда да, ишегалдында да, урамнарда да, госпиталь кырыендагы кварталларның буеннан-буена да – авырулар, тоташ авырулар. Яралылар хәле бөтенләй авыр булганнарны җитәкләгән, җәрәхәттән танып булмаслык хәлгә килүчеләр, тоташ ит кисәгенә әверелүчеләр, бер-берләренә елышкан…

245 мең кеше яшәгән шәһәрдә 100 мең кешене бер дулкын харап итә, калган 100 меңе төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр ала. 10 меңләп кешене шәһәрнең иң яхшы госпиталенә китерәләр. Әмма ул госпиталь бу кадәр кешене сыйдыра алмый: анда нибары – 600 койка-урын. Хастаханәнең эчендә дә, тышында да кешеләр, табиб аларның янына килсен өчен, елый-ялавара, иңри: «Сансэй! Доктор!» – дигән тавышлар көне-төне колак яфракларын барабанлый. Доктор Сасаки кешеләрнең күплегеннән һәм күргән җәрәхәтләрнең котны алырдай булуыннан аңын җуярдай чиккә җитсә дә, соң көчләрен туплап, бер яралыдан икенчесенә ташлана. Һәм шулай – тәүлек буена…

«Хиросима» романы артык нык тәэсирләнә торган укучы өчен түгел, ди тәнкыйтьчеләр. «Хиросима» романы безнең һәрберебез өчен дә, минемчә. Ә шунда без булсак, нишләр идек, дигән сорауга җавап табылсынга.



ДӨРЕСЛЕКНЕ ҮЗЕГЕЗ ЭЗЛӘП ТАБЫГЫЗ!

Джулиан Барнс.
«Портрет мужчины в красном».
Азбука-Аттикус, 2020.
Елена Петрова тәрҗемәсе.

Букер һәм башка күпсанлы премия, бүләкләр иясе, «Британиянең беренче язучылары»ннан саналучы Джулиан Барнс бүгенге Британиянең иң үзенчәлекле һәм сюрпризларга бай прозаикларыннан да. Барнс тарихны ярата, бигрәк тә – чорларны кушып, укмаштырып уйнарга, берсеннән икенчесенә күчеп йөрергә, капма-каршы булган агымнарны, стильләрне берләштерергә.

Нечкә тоемлы стилизация, ачы ирония, затлы лиризм һәм аксөякләрчә цинизм – без аның бу сыйфатларын оста зәркәнче кебек иҗат ителгән романнарының һәркайсында күрәбез. Барнсның тагын бер фишкасы – гаҗәпләндерергә ярату.

Һәр яңа әсәре без бөтенләй көтмәгән өлкәдән була аның. Яңа гына олпат эпик әсәрдән соң, ул безгә: «Мәгез, аптырагыз!» – дигәндәй, ике йөрәкнең матавыклары турындагы лирик романын китереп тоттыра. Һәм без укыйбыз, алай гына да түгел, йотлыгып-йотлыгып бер сулышта йотабыз. Кайчакта, әйе, сукрана-сукрана, хәтта сүгенә-сүгенә, әмма – барыбер!

«Портрет мужчины в красном» әсәрен укырга керешкәч, иң беренче уй: нәрсә соң бу?! Роман дияр идең, юк, түгел, публицистика дисәң, күбрәк әдәби жанрга тартымлык сизелә, ә, ярар, аңладым, бу бит эссе икән… тик эссе гына да түгел! (Сүгенә торган урыннары менә шушы, гадәттә. Һәм, билгеле инде, язучы буларак осталыгы калкып ята торган өлешләре дә шулар!) Тарихилыкны, биография-байопик жанры элементларын, фәлсәфи темага уйланулар юнәлешен һәм дә инде публицистик рухны берләштергән әсәр турында Independent газетасында шаяру катыш җитдилек белән болай язып та чыкканнар иде: «Биредә Барнс бөтен мөмкин булган жанрларны берләштерә, аптырамагыз! Безнең алдыбызда – чор буйлап сәфәр чыгучыларга кулай булачак менә дигән юл күрсәткеч!»

Китап идеясе язучыга ничек килә соң? Монысы да – үзе бер тарих. Шулай бервакыт эстет Барнс Лондондагы Милли галереяда узган күргәзмәдә кызыл киемдәге ир-ат төшерелгән картинага тап була. Портрет үзе Лос-Анджелесның Hammer музеенда саклана. Аңарда француз тарихындагы билгеле булган реаль персонаж – Самуэль-Жан Поцци сурәтләнгән. Бу кеше турында без нәрсә беләбез? Юк, ул аксөяк-дворян да, үз чорының билгеле сәясәтчесе дә, фәлсәфәчесе, язучысы да булмый. Барнс иронияне нәкъ шунда күрә дә: Поцци без югарыда санап чыккан барлык типтагы затлы әфәнделәрнең дә өзлексез йомышы төшә һәм алар килеп баш ора торган затлардан: ул – гинеколог. Алай гына да түгел, үз чорының искиткеч кискен һәм ирекле карашлы затларыннан берсе. Бу кеше хакында пациенткаларын үзенә карата, алар белән романнар куерта дигән даны да таралган була. Имеш, хатын-кызлар аның өчен үлеп торган…

Ярый, шулай да булсын… Әлбәттә, укучыда бу әфәнденең чын кыяфәте ниндирәк икән соң дигән кызыксыну туа. Чөнки Барнс романы тышлыгындагы фрагментта без Поццины́ң йөзен күрмибез. Бу да – үзенә күрә бер әдәби уен, постмодерн паттернныры калдыгы. Мин сезгә тәкъдим иткән каһарман – ул Поцци да, Поцци түгел дә, ди безгә шул рәвешле Барнс, дөреслекне үзегез эзләп табыгыз, янәсе. Джон Сингер Сарджент исемле рәссам төшергән бу портрет – безнең өчен ачкыч кына, без аның ярдәмендә романга илтә торган ишекнең йозагын ачып җибәрәбез дә, билгесезлеккә кереп чумабыз.

Хуҗасыннан түгел, ә аның халатыннан башлау гадел булырмы икән? Әмма бу халат, дөресрәге аның сурәте, бүгенге көндә без аның хуҗасын таныр өчен үз хезмәтен үтәде ләбаса инде. Аңа карап, без халатның хуҗасын да танийбыз. Ул үзе моңа ниндирәк карашта булыр иде икән? Җиңел сулар идеме, күләрме, әллә кәефе үк төшәрме? Хәер, тотышы әсәрдә без аның холык-фигылен ничек тасвирлауга карап, юнәлеш алыр, дип фаразларга була.

Моңарчы бик күп башка күренекле рәссамнарга позировать иткән яшь әфәнденең тәс-кыяфәте әллә ни шат күренми. Аңлашыла да, менә дигән кояшлы җылы көндә аңа бит авыр, сезонга туры килми торган твид халаттан басып торырга туры килә. Хәер, рәссам әле болай да ди сыман: «Монда сез түгел, ә сезнең халатыгыз мөһим!» Һәм бу халатны бүген, чынлап та, аның хуҗасына караганда күпкә ешрак искә алалар. Сәнгать ул шундый: шәхси омтылышлар, гаиләң яки дәрәҗәң өчен булган горурлык, җәмгатьчелек тәртипләренә тугрылык саклау кебек сафсаталардан һәрвакыт өстен. Вакыт һәрчак сәнгать яклы.

Барнс үз омтылышында гаҗәеп ихлас: аның портреттагы бу затның язмышын беләсе килә, һәм ул мәгълүмат эзли, туплый башлый. Кайчандыр Монако принцессасы Алиса Поцци турында «коточкыч чибәр ир-ат» дип әйтеп калдырган була. Һәм аны чынлап та заманының иң чибәр кешеләреннән саныйлар. Шуның белән беррәттән, иң укымышлы һәм белемле кешеләреннән дә. «Гүзәл чор», ягъни «Прекрасная эпоха» буларак тарих дәреслекләренә кереп калган чорның күркәм һәм парадоксаль бер заты була ул. Бихисап затлы аксөяк ханымнарны вә әфәнделәрне дәвалау белән беррәттән, аларның теленә соклангыч сөяркә буларак та кереп кала, искиткеч китапханә туплый, Дарвинны тәрҗемә итә, Дрейфус ситуациясендә скандалга бара, заманының бөек актрисасы Сара Бернарның дусты һәм ул чордагы француз җәмгыятенең «каймагы» өчен менә



Музейда Поцци портреты.

дигән фикер алышучы, инкыйлаби рух кертүче була. Сүз уңаеннан, һөнәренә килсәк тә, ул чын мәгънәсендә революционер дип исәпләнә. Көннәрен дәүләт карамагындагы хастаханәдә авыр эштә уздырган бу каһарман кичләрен Парижның иң шәп салоннарында балкый, ханымнарны һуштан яздыра, ир-атларны көнләштерә һәм фикерләре белән урынына «утырта», йә кыздырып, кайнатып җибәрә.

Ни өчен бу герой, диясе килә. Ә аннан аңлыйбыз: нәкъ менә аның аша Барнс чорның бик тә күптөрле катламнарына үтә ала. Ул, гомумән, ракурслар төрлерәк булсын өчен, шулай итәргә ярата. Беренче тапкыр гына түгел, әйтик, «Флоберның попугае» әсәрен укыган затлар сүзнең ни турында барганын аңлый...

Әсәр чорның йөзе булган башка каһарманнар белән дә шыплап тулган. Кайчак безнең баш миебездәге нейрон бәйләнешләре боларны кабул итә дә алмыйча тора: тукта, ә бу геройны бу герой белән нәрсә бәйли ала соң, бернәрсә дә бит... Ләкин Барнс бәйли! Ул безне өске катламда ятмый торган ассоциацияләр лабиринты буйлап йөртә, пунктирлар ярдәмендә җиткерәсе килгән ноктага илтә. Нигездә, Барнс җиткерергә теләгән идея бик кызыклы: XIX гасыр азагы – XX йөз башы Европасын ул тулы бер комплекста, синтез-симбиозда күрә, безгә дә шулай тәкъдим итә. Декадентлык идеяләре чәчәк аткан, снобизм белән аңкыган, денди, эстетлар үзләрен Аллага тиңләгән чордагы шовинизмны һәм аннан котылу мөмкинлеген дә ваемларга омтыла түгелме икән Барнс бу чуар һәм бик тә бәхәсле әсәре аша?

Чорны энә күзе аша уздыру, хирургларча, ярып карау һәм безгә күрсәтү дә, аннан бүгенгегә күчеп, дәрес алу да ята бу идеянең нигезендә. Ә тагын да тирәнгәрәк үтеп кереп укысаң, Барнсның, чын гедонистларча, ләззәт кичерүен ваемлап аласың: үзенең табышларыннан, уенныннан, мистификация белән төгәл дөреслек чигендә торучы детальләреннән, әлеге «роман» дип аталган мистериядән, кыскасы.

Бүгенге британлыларның Европага булган мөнәсәбәте борчылырга урын калдыра... Хәзерге Англиядә башкаларны аңларга омтылу мәсьәләсе бик нык аксый, гәрчә безне башкалар ныграк аңласа да. Бу безнең халык дучар ителгән үзизоляциянең (сүз пандемия турында бармый! – авт.) күңелсез чагылышларыннан берсе.

Шулай да мин төшенкелеккә бирелергә ашыкмыйм. Элеккеге декадентлык, нарциссльк, невротизм чәчәк аткан «Гүзәл чор»га әйләнеп кайтып, шундагыларны күздән кичерәм дә, кәефем күтәрелә. Самюэль-Жан Поцци фигурасына бәйле рәвештә – бигрәк тә. Аның әти-әниләре Италиядән Франциягә күченеп килгән, әтисе икенче мәртәбә британкага өйләнгән. Поцци үзе, Джозеф Листерны эзләп табып, листеризм принципларын үзләштерергә омтыла, Дарвинны тәрҗемә итә, 1885 елда интеллектуаль һәм декоратив «табышлар» артыннан Лондонга килә. Аны акыл, фән, прогресс, милләтчелекне кабул итмәү, бар нәрсә белән дә кызыксыну, һәр нәрсәнең төбенә төшәргә омтылу башкалардан аерып тора. Һәр яңа көнне ул куаныч белән, нәрсәдер көтеп каршылый. Аның тормышында медицина, сәнгать, иҗат, сәяхәтләр, сөйләшү, фикер алышулар, сәясәт, мәхәббәт уеннары – барысы да бербөтенгә укмаша. Доктор Поцци, әлбәттә, гөнаһсыз зат түгел, һич кенә дә! Әмма бу герой миңа үзенең тынгысызлыгы һәм катлаулы, үзенчәлекле, кабатланмас дәверенең үзәгендә торуы, аның йөзенә әверелүе белән кадерле.

Китап бай фактик материаллар, документлар, хатлар һәм фотографияләр белән тулыландырылган. Бу аның кыйммәтен тагын да арттыра, баета. Асылда, Барнс безне чор буйлап айкап йөртә: Дрейфус эшенең дә эченә кереп кайнап чыгабыз, Гонкурларның көндәлекләрен дә язышабыз, Оскар Уайльд белән сәяхәт тә итәбез, хәтта Сара Бернар белән бергә операция өстәленә дә ятабыз... Каян шушындай үтәкүренмәлелек пәйда була соң? Ничек итеп без, үзебез дә сизмәстән, романның катнашучысына әвереләбез? Җавап гади, асылда: без аның төп каһарманы белән кул сузымы арасындагы янәшәлектә басып торабыз... шикелле тоела. Юк, без аның башына һәм йөрәгенә үтеп керәбез, бербөтенгә керешеп бетәбез.

Бу эффектны Барнс эффекты дип атарга да мөмкиндер.

P.S. Шулай итеп, без ике китап аша да Үткәнгә кайтып килдек.

Әмма аларны берләштерүче бер кызыл җеп бар: аларны иҗат иткән ике автор да киләчәк турында борчыла. Безне дә уйланырга чакыра.

Ә уйлап карасаң, кичәге белән бүгенге арасы ул кадәр үк ерак та түгел. Күз ачып йомган ара гына.

махсус проект

«ТАТАРСТАН» ЮБИЛЯРЛАРЫ

56

ЧЫГАРЫЛЫШ

Габделәхәт Хәкимов, ТР Әтнә районы башлыгы, РФнең һәм ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, сентябрьдә үзенең 70 яшьлеген билгеләп үтә.

Илшат Нуриев,
Арча муниципаль районы башлыгы

ХӨРМӘТ ҺӘМ ИХТИРАМ ЯУЛАГАН ШӘХЕС

– Хөрмәтле Габделәхәт Гыйлемханович! Сезне тормышыгыздагы истәлекле вакыйга – 70 яшьлек юбилеегыз белән якташларыгыз һәм шәхсән үз исемемнән ихлас күңелдән тәбрик итәм!

Сез зур тормыш юлы узган, колачын киң җәеп, җигелеп эшләгән, бай тәҗрибәле, зур хөрмәт һәм ихтирам яулаган шәхес!

Районыгызның республикабызда тоткан урыны, әтнәлеләрнең тормыш дәрәҗәсе Сезнең фидакарь хезмәтегез, таләпчәнлегегез, алдан күрә белү сәләтегез, төпле белемегез нәтиҗәсе. Авыл хуҗалыгында ирешкән күрсәткечләрегез аеруча зур хөрмәт һәм игътибарга лаек.

Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, ди бит халык, шуңа күрә без, күршеләрегез өчен, янәшәдә үрнәк алырлык, киңәшерлек профессионаллар булу үзе зур уңыш!

Габделәхәт Гыйлемханович, алга таба да башкарган эшләрегез уң, нәтиҗәләрегез сөенерлек булсын! Ныклы сәламәтлек, хәерле озын гомер теләп калабыз Сезгә!

Фото Арча муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76,
8-9272-483-384
e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

Казан вертолёт заводы
сентябрьдә үзенең 80 еллыгын билгеләп үтә.

КАЗАНСКИЙ ВЕРТОЛЕТНЫЙ ЗАВОД
ХОЛДИНГ ВЕРТОЛЕТЫ РОССИИ

Валерий Побежимов,
«ЭНИКС» АҖнең
генераль директоры

80 ЕЛЛЫК ОЧЫШ

– Хөрмәтле коллегалар!

Предприятиебез коллективы хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән завод җитәкчелеген һәм аның хезмәткәрләрен Казан вертолет заводы төзелүнең 80 еллыгы белән ихлас йөрәктән тәбрик итәм!

Италиянең легендар даһие Леонардо да Винчи әйткәнчә, «бер тапкыр очыш тәмен татып кара, һәм синең күзләрең мәңгелеккә күккә төбәлгән булыр, анда бер тапкыр булганнан соң, син инде аны сагынырга дучар». Бу гыйбарә тулысы белән завод коллективына – 80 елга сузылган очышны тәэмин иткән романтиклар, уйлап чыгаручылар, идеалистлар һәм хыялыйларга туры килә. Алар үзләренең тынгысыз холыклары, зирәк акыллары һәм ныклы куллары белән инженерлык фикерләү дөньясында гаҗәеп машиналар уйлап тапканнар. Чыннан да, «КВЗ» ГАҖ Россия авиатехникасының һәм илебез сәнәгате үсешенең ышанычлылык символына әверелде. Икенче бөтендөнья сугышында безнең илнең оборонага сәләтлелеге эшчеләрнең фидакарь хезмәте, иртә таңнан төнгә кадәр, бик еш кына тәүлек әйләнәсендә тырышып эшләве, галимнәр һәм конструкторларның ачышлары нәтиҗәсендә тәэмин ителде. Казан заводы коллективы Гитлер Германиясен тар-мар итүгә, дөньяда тынычлык урнаштыруга үзеннән зур өлеш кертте. Бүген исеме бөтен дөньяга билгеле вертолет җитештерүче завод илебезнең авиатөзелеш тармагында әйдәп баручы брендка әйләнде, ә Казанда эшләнгән вертолетлар бөтен дөньяда 50 миллион сәгатьлек очыш ясады. Оча торган машиналарның төрледән төрле модификацияләре дөньяның йөздән артык иленә озатылды.

Завод вертолет техникасы җитештерүнең тулы циклын гамәлгә ашыра: машина проектыннан һәм серияләп чыгарудан алып, сатканнан соң персоналны өйрәтүгә, ремонтлауга кадәр, ә ISO 9001 стандартларына ярашлы сертификация үткән җитештерү сыйфаты системасы биредә эшләнә һәм ремонтлана торган техниканы тиешле контрольдә тотуны тәэмин итә. КВЗ җитештерүне даими рәвештә модернизацияләү буенча актив сәясәт алып барган, сату базарын киңәйтүне һәм эшләп чыгара торган продукциясенең характеристикаларын замана таләпләрен исәпкә алып камилләштерүне даими игътибар үзәгендә тоткан, көндәшлеккә сәләтле предприятие булып кала. Югары ышанычлылык, куркынычсызлык һәм хезмәтләндерүдәге гадилек – Казан осталары куллары җитештергән вертолетларның төп сыйфатлары.

30 ел дәвамында авиация техникасы һәм хәрби техника (шул исәптән ике төрдәге билгеләнештәгесен дә) эшләү белән шөгыльләнүче, пилотсыз авиация комплексларын эшләү, җитештерү һәм аларны серияләп чыгару буенча оборона заказларын үтәүдә турыдан-туры катнашучы ышанычлы партнерыгыз буларак, Сезгә тыгыз хезмәттәшлек һәм чын мәгънәсендәге һөнәри осталык өчен рәхмәт әйтәсебез килә.

Хөрмәтле коллегалар! Шушы күркәм юбилей көнендә Сезгә Татарстанның һәм Россиянең авиасәнәгате иминлеге хакына башкарган җаваплы эшегездә яңа уңышлар һәм шатлыклы вакыйгалар, яңа сату базарлары һәм уңышлы проектлар телибез! Үзегезгә һәм гаиләләрегезгә бәхет, тынычлык, иминлек һәм ныклы сәламәтлек юлдаш булсын!

Акционерное общество
ЭНИКС

Реклама

Фото «ЭНИКС» АҖнән алынды

КНПП ВЕРТОЛЕТЫ-МИ

Дмитрий Коновалов,
генераль директор

ХӨРМӘТКӘ ЛАЕК ЭШЛӘР

– Кадерле дуслар, вертолет төзүче хезмәттәшләр!

Легендар Казан вертолет заводы коллективын чын күңелдән предприятиенең 80 еллыгы белән котлыйбыз! Әлеге истәлекле көнне завод саллы нәтиҗәләр белән каршылый, предприятиенең продукциясенә базарда ихтыяҗ зур, ә коллективны партнерлары хөрмәт итә. «Вертолеты-МИ» Казан фәнни-җитештерү предприятиесе (элек Мәскәү вертолет заводының 1 нче санлы филиалы) һәм «Казан вертолет заводы» Гавами акционерлык җәмгыятен озак елларга сузылган, хәтта туганлык җепләре бәйли. Менә инде 70 ел ике предприятие дә, иңне иңгә куеп, вертолет техникасы җитештерүдә катнаша. Ми-1 вертолетларын сериялэп чыгара башлау белән диярлек КВЗ белән янәшәсендә МВЗның филиалы оештырыла, ул үзендә конструкторлык, җитештерү һәм тикшеренү компетенцияләрен берләштерә. М.Л. Миль исемендәге Мәскәү вертолет заводы җитәкчелегендә һәм аның белән актив хезмәттәшлектә менә дигән нәтиҗәләргә китергән уртак эшчәнлек башланып китә. **МВЗ – КВЗ – 1нче Филиалның** иҗади дуслыгы нәтиҗәсе буларак, бер-бер артлы бөтен дөньяга танылачак Ми-4, Ми-8, Ми-14, Ми-17, Ми-172 вертолетларының модельләре һәм аларның бик күп модификацияләре барлыкка килә һәм сериялэп чыгарыла башлый.

Дөньякүләм дәрәҗәдәге вертолетлар «йолдызлыгы»н булдырудагы уңышлар – беренче чиратта квалификацияле эшчеләрне, талантлы инженерларны һәм галимнәрне җәлеп итү нәтиҗәсе ул. КВЗ һәм 1 нче Филиал хезмәткәрләре арасында һәрвакытта да фәннәр кандидатлары һәм докторлары, дәүләт премияләре һәм яңа техника эшләүдә уңышлары өчен бүләкләр лауреатлары бар һәм булачак. Совет чорында салган нигез ташлары хәзергәчә Казанның вертолет һәм Улан-Удэның авиация заводларын тотып тора. Ә сезнең алда Казан вертолет заводын вертолетлар төзү эшендә алга таба да уңышларга китерәчәк яңа бурычлар тора.

Хөрмәтле хезмәттәшләр! 80 еллык юбилеегызны бәйрәм иткән көннәрдә «Казан вертолет заводы» ГАҖнең атказанган коллективына алга таба да иҗади һәм җитештерүдә казанышларга ирешүен, заманча вертолет техникасын җитештереп, яңа базарлар яулавын һәм яңа рекордлар куюын телибез. «Вертолеты-МИ» предприятиесе коллективы бөтен дөньяга билгеле күршесе белән горурлана, киләчәгенә ышана һәм соңгы вакытта уртак проектлар нәтиҗәсендә шактый ныгыган хезмәттәшлеккә алга таба да исәп тота. Бәйрәм белән!

«Вертолеты-МИ» КФҖП коллективы

Реклама

Фотолар «Вертолеты-МИ» Казан фәнни-җитештерү предприятиесеннән алынды

Фото «Техприбор» ГАҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Камо Абрамян,
«Техприбор» ГАҖ
генераль директоры

КРЭТ
ТЕХПРИБОР

Сәнәгать флагманы

– Хөрмәтле коллегалар! Кадерле завод эшчеләре! Казан вертолет заводы төзелүенең 80 еллыгы уңаеннан иң җылы котлауларыбызны кабул итеп алыгыз! Шушы истәлекле көндә легендар предприятиенең тарихы илебез авиатөзелеш тармагының, Татарстан сәнәгатенең мөһим сәхифәсе булуын билгеләп үтәсем килә, ул үзенең нәрсәләргә сәләтле булуын Бөек Ватан сугышы фронтларында күрсәтте. Икенче бөтендөнья сугышы елларында оборона предприятиесе буларак барлыкка килгән завод шунда ук үзенең югары сәнәгать куәтен күрсәтә, 70 ел дәвамында вертолетлар җитештерү буенча дөнья күләмендә танылган алдынгы предприятиегә әйләнә. КВЗ бүгенге көнгә кадәр дөньяның 80нән артык иленә 10 меңнән артыграк вертолет эшләп сата. Сездә тупланган белемнәр һәм ачышлар, галимнәрнең һәм конструкторларның озак еллар дәвамындагы хезмәте илебез сәнәгатенең алтын фондына керде. Дөнья икътисадында була торган кризисларга карамастан, КВЗ Россиянең авиатөзелеш флагманы һәм данлыклы предприятие булып кала бирә. КВЗның күптәнге һәм ышанычлы партнерлары буларак, без хезмәттәшлегебезне һәм предприятие хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын югары бәялибез.

Хөрмәтле коллегалар! Чын күңелдән сезнең коллективка – ныклы сәламәтлек һәм иминлек, ә предприятиегә кыю планнар һәм күркәм казанышлар телим!

Реклама

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

Автор: Татьяна Вафина

ОЛЫ МӘТӘСКӘ: ЧӘЧӘКЛӘР ДӘ БИЗӘКЛӘР

Олы Мәтәскә авылыннан китәсе дә килми. Беркая да, беркайчан да. Биредә бөтен нәрсә Таиландтагы кебек чәчәк ата һәм хуш ис бөрки. Бары тик орхидеялар урынына – петунияләр, бәрхәт чәчәкләре, алтын шарлар, дәлия, гөләпләр, аерма шунда гына... Чәчәкләр кыяфәтләре белән океан артындагы ишләренә охшамаса да, бездәге үсемлекләр дөньясы да җетелеге ягыннан тайлыларныкыннан ким түгел. Төклетуралар гүли, кошлар сайрый, бала-чага тавышы яңгырап тора. Мәтәскә халкы, авылларының чәчәк атарга әвәслеген белеп (туфрагына коры ботак кадап куйсаң да – атачак), мәшәкатьләрдән бушап торган арада, чәчәкләрнең хуш исенә чумып, эскәмияләрдә утырырга ярата. Моның өчен һәр йорт каршында эскәмия эшләнгән. Башка авыллардагы кебек ашык-пошык кына кадаклап куйган өч такта түгел, сәнгать әсәренә тиң объект – еш кына яңгырдан саклар өчен түбәсе дә бар.

ОЛЫ МӘТӘСКӘ



Фото: Алсу Троицкая

Кече архитектура формаларын сөючеләр

Гомумән, Олы Мәтәскәдә кече архитектура формаларын яраталар дип аңладык, чөнки биредәге һәрбер йорт, һәрбер ишегалды тирәсе гүя авыл кешеләренең кул эшләреннән торган күргәзмә. Кемдер бакчаларга куя торган әзер фигуралар сатып ала да алар ярдәмендә чәчәк түтәлләреннән композицияләр иҗат итә, кемдер кул астындагы әйберләрдән аккошлар, ләкләкләр һәм башка канатлы дусларыбызны ясап куя... Сокланып туймаслык! Һәр җирдә чисталык-пөхтәлек.



Авыл кешеләренең
кул эшләре күргәзмәсе.

Матур күлмәген киеп, ирененә иннеген тидереп, Гөлнур Гыйманова үзе үстергән чәчәкләре янына басып фотога төште.

АК ХӘРЕФЛӘР ҺӘМ КЫЗЫЛ АЛМАЛАР

Беренче истәлекле урын еракан ук күренеп тора. Ак төстәге зур хәрефләр белән «Бөек Җиңүгә – 75 ел! Олы Мәтәскә» дигән язуны җирлек башлыгы Миңнәхмәт Вәлиуллин җитәкчелегендә авыл кешеләре үзләренең якташлары – җиңү яулаган яугирләр истәлегенә тау битенә язып куйганнар. Икенчесе – өр-яңа «Миләүшә» мәчете. Аны шушы авылда туып-үскән Миләүшә Сәлахетдинова үз акчасына төзеткән. Җәй кебек җете төсләрдән торган авылны әйләндереп алган күлләр һәм таулар янына мәктәпнең алма бакчасын да кертик – кып-кызыл алмалар һәм... ямь-яшел кәбестәләре белән. Алма быел Мәтәскәнең мәктәп укучыларын витаминлы бай уңышы белән сөендергән. Ел буена җитәчәк.



ЯРАТЫП ЭШЛӘНӘ ТОРГАН ЭШ

– Чисталык-пөхтәлек, чөнки бездә яхшы, эшчән халык яши, – дип сөйли җирле Мәдәният йорты директоры Гөлнур Гыймранова. – Эшкечелек юк – яшьләр дә эчми, олылар да.

Гөлнур Хаҗиәхмәтова, үзенең сүзләрен раслап, үз биләмәсендәге тәрәзә пыялаларын ялтыраганчы сөртә. Чәчәкләрне дә үзе үстерә икән. Мәдәният йорты янында алар гаҗәеп матур булып үсеп утыралар – күп кенә түгел, бик күп.

– Мин чәчәкләр үстерергә яратам, – дип елмая ул. – Яратып эшләнә торган эш.

Матур эш тә. Матур күлмәген киеп, ирененә иннеген тидереп, Гөлнур Гыймранова үзе үстергән чәчәкләре янына басып фотога төште. Ә аннан соң безне туган авылының иң күркәм урыннарын күрсәтергә алып китте.

Олы Мәтәскә авылының мәктәбе чәчәкләргә, алмага һәм кәбестәгә күмелеп утыра.

Тәмәке тартучыларга балалар бакчасына керү тыела.



Марат Сөнгатуллин һәм Наталья Карпова – үз төбәкләренең патриотлары.

ТЕЛӘЧЕ ТӨБӘГЕ ВАТАНПӘРВӘРЛӘРЕ

Мәктәп капкасы янында безне аның директоры Марат Мөхәррәм улы Сөнгатуллин каршы ала. Ул да – шушы мәктәп укытучылары кебек үк туган авылының ватанпәрвәре. Шушында туган һәм менә 31 ел инде шушында хезмәт тә итә. Әти-әнисенең эшен дәвам иттерә – география укыта.

Марат Мөхәррәмович Мәтәскә турында географик яктан гына мәгълүмат биреп калмыйча, мавыктыргыч тарихын да әдәби әсәр кебек итеп сөйли белә. Авыл укытучыларының һәркайсы кебек.

– Татарстанда Мәтәскә исемле биш авыл бар, – ди ул, бармакларын бөгә-бөгә санап. – Шуларның өчесе Теләче районында – Олы Мәтәскә, Югары Мәтәскә һәм Түбән Мәтәскә. Тагын берәр Югары һәм Түбән Мәтәскә авыллары Арча районында урнашкан. Алар үзара ничек бәйләнгәндер – белмим, әмма безнең авыл турында мондый тарих бар. Бирегә гаиләсе белән Мөтәси исемле кеше килеп утырган. Кешеләр бит чишмәсе булган урыннарда төпләнергә тырышкан. Биредә дә чишмә бар. Вакытлар узу белән, Мөтәси Мәтәскә булып киткән. Авыл тегүчеләре белән дан тоткан. Халык теккән, чабата үргән, шәл бәйләгән, киез ката баскан, күн иләгән, чаналар, арбалар ясаган, хәтта кирпеч тә суккан. Танылган совет язучысы Фатих Хөсни безнең авылда туып-үскән. «Зөләйха күзләрен ача» фильмын карадыгызмы? Фатих аганың да «Утызынчы ел» романы шул турыда. Бер дә аңардан калышмый торган әйбәт фильм төшерергә була.

– Мәктәп терриориясендәге спорт мәйданчыкларын күреп чыга аласыз, – дип, Теләче районының мәгариф бүлеге башлыгы Наталья Владимировна Карпова безне эчкә чакыра. Ул бирегә эш белән килгән икән. – Аларның мәктәп яны участогы искиткеч!

Мәктәп бакчасында үскән алмаларның тәмен татып, машинаның багажнигына майлы гөмбәләр төяп, фотоаппаратны чәчәкләр, ягъни аларның гаҗәеп сурәтләре белән тутырып, әлеге матур авыл белән хушлашабыз. Һәм кайтырга вәгъдә бирәбез – чөнки яңадан чакырып калдылар.

НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ:

Казаннан Мамадыш тракты буенча чыгабыз, Константиновка аша Теләче ягына юл тотабыз. Казаннан Олы Мәтәскәгә кадәр – 76 км.

НӘРСӘЛӘРНЕ КАРЫЙБЫЗ:

Күпне күргән сәяхәтчеләргә ышаныгыз: тауга менеп, Олы Мәтәскәгә шул тау башыннан күз салыгыз – искиткеч хозурлык, бигрәк тә мәктәпнең алма бакчасы матур күренә.

НӘРСӘ АЛЫП КАЙТЫРГА:

Әлбәттә, җирән гөмбә! Олы Мәтәскәнең даны еракларга таралган, монда алар бик күп икән! «Әлегә майлы гөмбәләр генә күп, – дип ышандыра безне Марат Мөхәррәмович. – Җирән гөмбәләргә иртәрәк. Икенче мәртәбә яңгыр явуы кирәк, аннан җылытып та җибәрсә – менә шунда инде җирән гөмбә китәчәк. Ничек беләбезме? Әгәр мәктәп чыршылары янында җирән гөмбәләр күренә икән, бу сигнал. Урманга гөмбәгә барырга була. Әлегә чыршы аслары буш, иртән генә тикшердем». Т

БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ ШУЛКАДӘР САГЫНГАНБЫЗ ИКӘН!

Быелгы 1 сентябрь Россия мәктәбе тарихында иң дулкынландыргыч көн иде. Бөтен дөнья мәктәпләре өчен дә шулай булды! Узган уку елы ахырында онлайн-укытуга күчкәч, укучылар, моңа кадәр онлайн-аралашуга күнеккән булсалар да, кинәт кенә мәктәптәге гадәти иртәнге күрешү, кичке саубуллашу, тәнәфесләрдә дуслар белән сөйләшү мизгелләре, мәктәп тәрәзәсеннән карап күнеккән күренешләр, туйдырып бетергән дәрескә чакыручы, көтеп алынган тәнәфескә дәшүче кыңгырау тавышы, мәктәп коржиклары һәм компотлары, тагын бик күп шундый көндәлек, ләкин бик мөһим, югалтып карамыйча, кадере аңлашылмаган нәрсәләрсез калды.

Һәм менә зарыгып көткән очрашу, яраткан мәктәбебез, кадерле укытучыларыбыз! Без шундый озак күрешми тордык! Без шундый сагынышканбыз! Елмаюлар, кочаклашулар, балаларның шатлыклы йөзләре, чәчәкләргә күмелгән бәхетле укытучылар…

Ә беренче сыйныф укучылары? Алар өчен барысы да башланып кына килә әле, барысы да тәүге тапкыр: мәктәп тә, парталар да, дәреслекләр дә, беренче укытучы да, 2020 елның 1 сентябреннән башлап гомерлеккә калачак дуслары да! Чын, реаль тормышларында булган шундый зур үзгәрешләрдән бераз югалып калган беренче сыйныф укучылары. Тормыш 7 яшьтә башлана гына әле! Без хәзер моны тәгаен беләбез!

Уңышлар, бишле билгеләре генә сезгә! ▪

Фото: Александр Ефремов

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА
БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

83 нче лицей, Казан ш., 2020 елның 1 сентябре.

Фото: Александр Ефремов

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

Казан ш., 1973 елның 1 сентябре.

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ